# ШУРА

№ 36
2022

# Рамазан
*кәрим*

2000999960567

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Рамазан – Коръән ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Коръән буенча яшәргә тырышам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Садака – ул нур! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Рамазан бәрәкәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Ураза гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . . . . . 42
Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . 44
Матурлык –котылуның бер юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Намазның файдалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Болгар бабаларыбызның Ислам динен кабул итүе . . . . . . . . . 57
Балага исем кушу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Динсез тормыш – авыр тормыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Калебне дәвалау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Тәкъдиргә иман китерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Зөлхиҗҗә – гыйбадәтләргә бай ай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Пәйгамбәребезнең соңгы хаҗы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88

ФӘТВАЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фәтвалары . . . . . . 96
Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы? . . . . . . . . 96
Балдан зәкят түләнәме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Гади оекбашка мәсех кылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә . . . . . . . . . . . . . 117

ӘҢГӘМӘ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин: «Халкыбызга чал тарихыбызны күрсәтергә тиешбез» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

ТАРИХ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Ислам диненең таралуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

МИРАС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Сәфәрдә ураза, сусау, чәй, су мәсьәләләрендә . . . . . . . . 155
Авыл мөгаллиме. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Әбү Хәнифә – бар заманның мөҗтәһиде. . . . . . . . . . . . . 162

УРАЗА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Рамазан ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

ТӘРБИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Әдәпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Муса һәм Хозыр галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . 186

НӘСЫЙХӘТ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет ителә торган нәрсә бүлеге. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Туган тел – Аллаһыдан әманәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201

**«ШУРА» дини альманах, №36**

*апрель–июнь 2022*
*Рамазан-зөлкагъдә 1443*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИРЛӘР:**
Лилия Хәләфетдинова
Айсылу Юлдашева

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 25.03.2022
Чыгу көне: 08.04.2022

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ❁ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ❁ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ❁ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ❁ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ❁ دَاعِينَا إِلَى اللهِ❁ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ❁ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ❁ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ❁ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ❁ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ❁ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ❁ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ❁ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ❁

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

________________________________❁

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً ۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ ۞ كَمَا

بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللَّهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وَهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَائِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусҙмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әммa бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыйҙү билләһи: ____________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

____________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалӛллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иӟәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйӟү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләӟиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ӟәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхз̧үл мән хәз̧әләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууз̧ү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и з̧ил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәз̧әккәрауун. Вәләз̧икруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[1] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

---

[1] 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:
___________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа ияртүчеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуүҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*8 нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Рамазан – Коръән ае

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итеп, безгә төрле нигъмәтләр, төрле ризыклар биргән, туры юлны, хәерле гамәлләр кылу юлын күрсәткән Аллаһы Тәгаләгә күңелебездәге барча хәмед вә сәналәр булса иде. Пәйгамбәрләрнең иң нурлысына, галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган Расүли Әкрам Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең түрләреннән чыккан салават вә шәрифәләребез булса иде.

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дигән: «Дөреслектә, бу калебләр – ул савыт, шулай булгач, аларны Коръән белән тутырыгыз һәм башка нәрсә белән тутырмагыз».

Коръән уку Аллаһыны зикер итүнең иң хәерле юлы булып санала. Коръән укыганда тәҗвид кагыйдәләрен, тиешле булган әдәп һәм әхлак тәртипләрен үтәү кирәк. Изге Китабыбызны һәрдаим: көнен, төнен, кичен, иртәләрен укып торсак та, артык булмас. Шулай ук Аллаһы сүзләрен кайда гына булсак та – өйдә дә, сәфәрдә дә укырга тиешбез. Коръән уку, аны өйрәнү һәм, боларга өстәп, Коръәнне башкаларга өйрәтү фазыйләтле гамәл. Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Сезнең иң хәерлегез – Коръәнне өйрәнүче һәм аны башкаларга өйрәтүче»[1], – дип әйткәнен риваять иткән.

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Сәхабәләребез, галимнәребез һәм имамнарыбыз Коръәнне укып чыгу вакытларын үзләре билгеләп куя торган булган. Кайберләре Коръәнне бер төндә укып чыкса, Изге Китапны намаздагы бер рәкәгать дәвамында укып чыгучылар да булган. Боларны истә тотып, без дә үзебезгә Аллаһы Китабын укуда билгеле бер план куярга тиеш. Мәсәлән, Рамазан аенда Коръәнне тулысынча укып чыгу, ягъни һәр көнне бер җөз укырга вакыт табу яхшы булыр. Әлбәттә, һәр кеше өчен бу план төрле була. Берәүләр өчен һәр көнне тулы җөз укып чыгу кыен, алар аның яртысын яки Коръәннең берничә битен генә укый алырга мөмкин. Әмма шуны аңларга кирәк: бу гамәлләр аз булса да, дәвамлы булырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы каршында иң сөекле гамәл, кечкенә генә булса да дәвамлы булганы»[1], – дигән.

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе: «Коръән югалганчы, аны еш укыгыз», – дип әйткән. Аннан: «Ә ул безнең калебләрдә һәм язылган төргәкләребездә булган килеш ничек югала ала?» – дип сораганнар. Ул: «Бер төн эчендә ул сезнең калебләрегездән алыныр һәм язылган төргәкләрегездән сөртелер», – дигән һәм әлеге аятьне укыган:

وَلَئِن شِئْنَا لَنَذْهَبَنَّ بِالَّذِي أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ

**«Әгәр теләгән булсак, сиңа вәхи иткән нәрсәне [тулысы белән] юк итәр идек».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:86

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһедән тапшырыла, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр кеше төннең башында Коръән укып тәмамласа, фәрештәләр иртәнге вакытка кадәр аңа изге теләк теләп торыр. Әгәр ул төннең азагында Коръән укып тәмамласа, фәрештәләр кичкә кадәр аңа изге теләк теләп торыр»[2].

1 Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әд-Дәрими хәдисләр җыентыгыннан.

Коръәнне тәҗвид белән укудан тыш, Аллаһы сүзләрен укыганда ихлас булырга тиешлегебезне онытмыйк. Коръәнне Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ризалыгы өчен генә укыйбыз һәм һәрбер кеше бу вакытта үзен Аллаһы Тәгаләнең әңгәмәдәше икәнен истә тотарга тиеш.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне билгеле: «Кешенең Коръәнне яттан (китапсыз) укуы – ул мең әҗер-савап, ә ятлаганын китаптан укыганда әҗер-савап ике меңгә кадәр арта»[1]. Димәк, яттан белгән Коръәнне кулга тотып уку күпкә фазыйләтлерәк, чөнки бу вакытта без Аллаһының сүзләренә тагы да зуррак игътибар күрсәтәбез, аятьләр турында фикерлибез. Әлбәттә, яттан уку да бик фазыйләтле гамәл. Гомумән, Коръәнне яттан өйрәнү олуг нигъмәт. Коръән уку турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Коръәнне укыгыз, чөнки Кыямәт көнендә ул укучыларына шәфәгатьче булыр»[2]. Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе Расүлебезнең болай дип әйткәнен тапшырган: «Аллаһы һәм Аның Расүле аны яратуына куанган кеше мосхаф буенча Коръән укысын». Рамазан аенда Коръәни Кәрим белән мөнәсәбәтләребезне тагы да яхшыртырга тиешбез. Коръәнне үзебезнең дустыбыз итәргә, аның хөкемнәрен, нәсыйхәтләрен тагы да яхшырак итеп өйрәнергә тырышыйк, чөнки бу – Галәмнәрне Яратучының сүзләре. Коръән – ул беренче чиратта безнең өчен кулланма, ягъни җитәкчелек. Раббыбыз болай дип әйтә:

ذَٰلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ ۛ فِيهِ ۛ هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ ﴿٢﴾

**«Ул – [пәйгамбәрләр галәйһимуссәлам хәбәр иткән] үзендә бер шик тә булмаган, мөттәкыйләр [Аллаһы рәхмәтен югалтудан куркучы тәкъвалар] өчен юл күрсәтә торган Китап».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:2

1 Имамнар Әт-Табәрани, Бәйһакый.

2 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Коръәни Кәримдә ике дөнья бәхете бар. Аны укып, без күңелләребезгә тынычлык табабыз, һидаятькә ирешәбез, әҗер-савапларга ия булабыз һәм ихлас йөрәктән, Раббыбыз ризалыгы өчен дип кенә укыган вакытта Аллаһының рәхмәте белән, Кыямәт көнендә дәрәҗәләргә ия булырбыз. Коръән белән мөнәсәбәтләребез ныграк булган саен, Раббыбыз белән мөнәсәбәтләребез дә ныграк булыр, ихласлыгыбыз артыр. Шуңа күрә Коръән укыганда ихлас булуыбыз, аны Аллаһы ризалыгы өчен генә укуыбыз мөһим. Әбү Сәгъд Әл-Ходри Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен тапшырган: «Коръәнне өйрәнегез һәм, аның аркылы кешеләр дөньялыктагы нәрсәләрне сорый башлаганчы, Аллаһыдан җәннәт сорагыз. Дөреслектә, Коръәнне өч кеше өйрәнә: аның белән мактанучы кеше, аның аркылы ризыкланучы кеше һәм аны Аллаһы ризалыгы өчен укучы кеше».

Коръән укыганда безнең беренчел максат – ул Аллаһы сүзләрен тормышыбызда юл күрсәтә, һидаятькә ирештерә торган мөһим төшенчә итеп кабул итү. Коръәнне укып кына калмыйча, аның белән гамәл кылырга, аның бөеклеген танырга кирәк. Раббыбыз Коръәни Кәрим белән вәгазьләнеп, аның нәсыйхәтләрен кабул итүчене акыл ияләре дип атый:

وَمَا يَذَّكَّرُ إِلَّا أُولُو الْأَلْبَابِ

**«Акыл ияләреннән башкалар [Коръәни Кәримдәге үгетләрне] искә алмас».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:7

Ә инде Коръәни Кәримне инкяр итеп, аннан йөз чөерүчеләр хакында Раббыбыз болай дип әйтә:

وَمَن يَكْفُرْ بِهِ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ

**«Кем дә кем [Китапны үзгәртеп яки хөкемнәрен кире кагып] аны инкяр итсә, шулар – [үзләрен матди һәм рухи зарарга дучар итеп] югалтучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:121

Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә укыган Коръәннәребез бәрәкәтендә Үзенең киң рәхмәте белән ике дөнья бәхетенә ирешүләребезне насыйп итсә иде. Коръәни Кәрим безнең ике дөньяда да тугры юлдашыбыз, ярдәмчебез булса иде. Аллаһы Тәгалә укыган Коръән аятьләре белән гамәл кылып, аның хөкемнәрен үтәп киләчәк буыннарга да үрнәк булырлык итеп яшәүләребезне насыйп әйләсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*15 нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Коръән буенча яшәргә тырышам

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Коръәни Кәримне иңдереп, мөселманнарга бик зур бүләк насыйп итте. Коръән – ул Ислам диненең нигезе һәм мөселманнарга бар эшләрдә дә (дини мәсләктә, гыйбадәттә, әдәп-әхлакта) идарә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

كِتَابٌ أَنزَلْنَاهُ إِلَيْكَ مُبَارَكٌ لِّيَدَّبَّرُوا آيَاتِهِ وَلِيَتَذَكَّرَ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٢٩﴾

**«[Коръәни Кәрим] Мөбарәк бер Китап ки, аны алар аның аятьләрен уйласыннар һәм [нәфесләренең бозык теләкләреннән арынган] аек акылга ия булганнар үгетләнсен дип сиңа иңдердек».**

«Сад», 38:29

Коръән аятьләре турында фикерләү, һичшиксез, аларның дөреслегенә ышануга һәм бу аятьләрне тормышта куллануга китерә. Моңа, әлбәттә, Коръәндәге боерыкларны үтәү, андагы тыелган гамәлләрдән ерагаю аша ирешеп була. Берәү Коръән буенча яшәсә, шул Ахирәт тормышында газаптан котылачак, чын бәхет татыячак һәм мәңгелеккә җәннәткә керәчәк. Аллаһы Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил булып тора:

إِنَّ هَٰذَا الْقُرْآنَ يَهْدِي لِلَّتِي هِيَ أَقْوَمُ وَيُبَشِّرُ الْمُؤْمِنِينَ الَّذِينَ يَعْمَلُونَ الصَّالِحَاتِ أَنَّ لَهُمْ أَجْرًا كَبِيرًا ﴿٩﴾

**«Һичшиксез, бу Коръән иң туры булган юлга илтә һәм изге гамәлләр кылган мөэминнәрне алар өчен [җәннәт кебек] зур бер әҗер булуы белән сөендерә».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:9

Пакь йөрәкле һәм чиста күңелле кешеләр Коръән аша дөрес юлны һәм Ахирәт газабыннан котылу юлын һәрвакыт таба алалар. Кем дә кем шуңа омтылса, аны Ахирәттә бөек куаныч көтә.

Мөселман кешесенә Коръән кануннары буенча яшәү авыр түгел. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә адәм баласына беркайчан да күтәрә алмаслык йөк бирми. Коръәндә булган васыятьне тормышка ашырырга теләгән кеше, мөмкинлеге булган кадәр түбәндәге гамәлләрне башкарырга тиеш:

1. Коръән укырга һәм ятларга

Әлбәттә, һәркөнне Коръән укыр һәм ятлар өчен буш вакыт кирәк. Ләкин кеше «минем вакыт юк» дип әйтә икән, ул шул сүзләре белән «Коръән уку минем өчен мөһим эш түгел» дип белдерә. Кеше шулай намаз, ураза кебек фарыз гамәлләр турында да әйтергә мөмкин, мондый сылтаулар – бик куркыныч эш! Ничек инде син, адәм баласы, үзеңне юктан бар итүче Раббыңа вакыт таба алмыйсың?!

Вакыт табарга тырыш, кардәшем! Көненә ярты сәгать булса да, Аллаһы Тәгалә Китабына вакыт тап! Коръәннән бер, ике, биш бит укы – күпме хәлдән килә– тик бу эшеңне калдырма. Ә кем инде бөтен Коръәнне яисә аның өлешен яттан белә икән, аңа шул ятлаганын кабатлап торырга кирәк, чөнки ул онытыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Гел Коръән укыгыз (ятлаганны кабатлагыз), Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, дөреслектә, ул җебеннән ычкынган дөядән тизрәк юк була (онытыла)»[1], – дип әйткән.

1 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан, № 5033.

2. Коръән аятьләре хакында фикерләргә

Югарыда без Коръәннең «Сад» сүрәсеннән бер аять китергән идек: **«Һичшиксез, бу Коръән иң туры булган юлга илтә һәм изге гамәлләр кылган мөэминнәрне алар өчен [җәннәт кебек] зур бер әҗер булуы белән сөендерә».**

Башкачарак әйтсәк, Коръән мәгънәләре хакында фикерләү һәм аның аятьләреннән нәсыйхәт алу – Коръән иңүнең бер хикмәте һәм тормыш алып баруның бер ысулы.

Әйе, Коръәнне уку – бик яхшы, ләкин аның әле тәрҗемәсен, тәфсирен укысак – тагын да яхшырак, аятьләрнең мәгънәләре хакында фикерләү күпкә тирәнрәк була. Тик тәрҗемә белемле, ышанычлы галим белән ясалган булырга тиеш. Коръәнне укыганда мәгънәсен дә укып барсаң, ул күпкә саваплырак.

Коръән хакында фикерләү Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте булып тора. Бу – сәхабәләр һәм табигыйннәр юлы – мөселман калебе һәм аның акылы өчен рухи азык. Риваятьләрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең намазда Коръәнне уйланып, фикерләп укыганлыгы хакында әйтелә. Хөзәйфә бине Әл-Йәмән радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән төнге намазны укыган һәм аннан болай дип хәбәр ителгән: «Ул тәсбих булган аятькә җитсә, тәсбих әйткән («Сүбехәәналлаһ»). Аллаһы Тәгаләгә дога кылу хакында булган аятькә җитсә, Аллаһы Тәгаләгә дога кылган. Аллаһы Тәгаләгә сыену хакында әйтелгән урыннарда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләгә сыену белән мөрәҗәгать иткән («Әгуузү билләәһ»)»[1].

3. Коръәндә булган боерыкларны һәм тыюларны үтәргә

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

---

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, № 772.

الَّذِينَ آتَيْنَاهُمُ الْكِتَابَ يَتْلُونَهُ حَقَّ تِلَاوَتِهِ أُولَٰئِكَ يُؤْمِنُونَ بِهِ ۗ وَمَن يَكْفُرْ بِهِ
فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ ﴿١٢١﴾

**«Кешеләр Без биргән [Тәүрат һәм Инҗил дигән] китапны хак уку белән укыйлар [сүзләрен үзгәртмиләр, мәгънәсенә төшенәләр]. Алар аңа ышаналар. Кем дә кем [Китапны үзгәртеп яки хөкемнәрен кире кагып] аны инкяр итсә, шулар – [үзләрен матди һәм рухи зарарга дучар итеп] югалтучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:121

Коръәнне тәфсир кылучы кайбер галимнәр «хак уку» дигән сүзне сәхабәләргә сылтаганнар. Ә Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе «хак уку» сүзләрен болай дип аңлаткан: «Алар хәләлне хәләл дип, харамны харам дип таныйлар һәм Коръән аятьләренең мәгънәләрен бозмыйлар».

Олуг табигыйн Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи бу сүзләрне болай дип тәфсир кылган: «Алар ачык мәгънәле аятьләргә буйсына һәм мүтәшәббихәт (ачык булмаган мәгънәле) аятьләргә ышана».

Башка сәхабә Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Аллаһы белән ант итәм, Коръәнне хак уку – ул хәләлне хәләлгә, харамны харамга санау».

Хәзерге вакытта мөселманнар арасында олуг хата бар: күбесе харамны – хәләл, ә хәләлне – харам дип саный. Бер яктан, кредит алырга рөхсәт иткән, ә башка яктан, мәсәлән, мәүлидне харам кылган кешеләр дә бар.

Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән: «Коръән – ул кешеләр аның белән гамәл кылсыннар өчен иңгән, ә сез аның укуын гына гамәл дип алгансыз», – ягъни сез Коръәнне укыйсыз гына, әмма андагы булган боерыкларны үтәмисез. Аллаһы Тәгалә андый кешедән разый булмый!

4. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үтәргә

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үтәү Коръән буенча яшәү белән нык бәйләнештә тора, моны Аллаһы Тәгалә Үзе әйтә: **«Кем аңа (Мөхәммәдкә) ышаныр, аны олылар, аңа булышыр һәм аңа иңдерелгән нур (Коръән) артыннан иярер – шул уңышка ирешәчәк».**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте буенча яшәүче кеше Коръән буенча да яшәгән дип санала, чөнки Коръән белән Сөннәт – алар икесе дә Аллаһы Тәгаләдән кешеләргә иңдерелгән һәм Кыямәт көненә кадәр үзенең әһәмиятен югалтмаячак вәхи.

Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабына ышанган, Аңа буйсынган кешеләргә Коръәннең күп аятендә Ахирәт газапларыннан котылу вәгъдә итә. Ә берәү тормышын тулаем рәвештә Коръән буенча төзесә, андый кешене нинди зур һәм бөек саваплар, бүләкләр, бәхет көтә! Бу, һичшиксез, бөек уңыш!

Ике бөек нәтиҗәне искә төшерик – ул гөнаһларның гафу ителүе һәм Кыямәт көнендә шәфәгать. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَآمَنُوا بِمَا نُزِّلَ عَلَىٰ مُحَمَّدٍ وَهُوَ الْحَقُّ
مِن رَّبِّهِمْ ۙ كَفَّرَ عَنْهُمْ سَيِّئَاتِهِمْ وَأَصْلَحَ بَالَهُمْ ﴿٢﴾

**«Иман китергән һәм изге гамәлләр кылган, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгәнгә ышанганнар, бу – Раббыларыннан [килгән] хак. Ул аларның начар эшләрен сөртте һәм [ике җиһанда да] хәлләрен төзәтте».**

«Мөхәммәд», 47:2

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кыямәт Көнендә Коръәнне һәм аның буенча яшәгән кешеләрне китерәчәкләр, ә иң алдан «Әл-Бәкара» белән «Әлү Гыймран» сүрәләре ба-

рачак, һәм кешеләрдән алар буенча яшәүчеләрне саклаячаклар»[1], – дип әйткән.

Кадерле дин кардәшләрем, Коръәни Кәримне уку, ятлау һәм аның турында уйлану, аның буенча яшәү әһәмиятен беркайчан да онытмагыз!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

1 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, №805.

*22 нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Садака – ул нур!

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһии әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итеп, безне шушы дөньяга җибәреп, изге гамәлләр кылып яшәргә кушучы Аллаһы Тәгаләгә мактаулар булсын! Шушы сынау дөньясына мөгаллим вә күркәм үрнәк иясе итеп җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребезне юллыйбыз.

Изгелек. Шушы сүзне ишетүгә җаннар җылынып, күңелдә сөенү хисләре уяна, елмаясы килә. Безнең динебез дә, милләтебезнең гореф-гадәтләре дә изгелеккә, юмарт булырга чакыра. «Изгелек җирдә ятмас», дип әйтелә татар халык мәкалендә. Ә инде динебезнең хөкемнәренә карасак, Аллаһы Тәгаләнең китабы Коръәни Кәримдә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтендә без бик күп изгелек кылуга өндәгән сүзләр күрербез. Изгелекне бик күп мәгънәдә аңлап була, бик күп төрле изгелекләр эшләп була. Динебездә иң хуш изгелекләрнең берсе – садака бирү. Хәтта туган авырлыкларны да динебез садака биреп шифаландыруны ассызыклый.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ٱلَّذِينَ يُنفِقُونَ أَمْوَٰلَهُم بِٱلَّيْلِ وَٱلنَّهَارِ سِرًّا وَعَلَانِيَةً فَلَهُمْ أَجْرُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ
وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ ﴿٢٧٤﴾

**«Төнлә һәм көндез, яшерен һәм ачыктан-ачык малларын сарыф иткән кешеләргә – Раббылары катында әҗерләре [әзерләп куелган]. Аларга бернинди дә курку булмас, [дөньяда калдырган нәрсәләре өчен] алар хәсрәт тә чикмәс».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:274

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Садака малны киметми»[1], – дип әйткән. Шушы хәдистән аңлашылганча, изге юлда үз малыңны сарыф итү малны арттыра гына. Авыр сынаулар килсә, садака биреп дога кылдырабыз, бу безнең милләттә генә түгел, ә мөселман җирлекләрендә киң таралган гадәт. Изге гамәл безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта, Аллаһының ачуын рәхмәткә алыштыра. Әлбәттә, бу авырлык килгән вакытта, бары садака гына биреп, намаз һәм башка гамәлгыйбадәтләрне калдыруны аңлатмый, ә киресенчә, өстәмә изгелекләр кылуны ассызыклый.

Садакалар төрле-төрле була: зәкят, фитыр, садакатуль-җәрия һәм башкалар. Зәкят садакасы – малларыбызның нисабы тулган очракта 1/40 өлешен, ягъни 2,5 % зәкят итеп өләшүдер. Фитыр садакасы – Ураза гаетенә кадәр гаиләнең һәр әгъзасы исеменнән садака бирүдер. Фитыр садакасының билгеле бер микъдары бар. Шулай ук гошер садакасы хакында да онытмаска кирәк. Гошер садакасы – яңгыр суы белән үскән уңыш булса, аның 1/10 өлеше, әгәр кеше үзе су сибеп үстерсә, бу очракта 1/20 өлешен бирү тиешле.

Шушы тиешле садакалардан кала, иң саваплысы – ул җәрия садакасы. Хәдистә әйтелгәнчә, «Өч төрле гамәлнең савабы мөселман шушы дөньядан киткәч тә туктамас: җәрия садакасы (әҗер-савабы өзлексез булган садака), үзеннән соң калдырган гыйлем (башкалар да куллана алган), Аллаһыга изге дога белән мөрәҗәгать итүче бала. Садаканы фәкать күңеле киң вә изгелеккә хирыс булган бәндә генә кыла ала, чөнки бүгенге

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

көндә изгелек эшләүне көчсезлеккә санышлар, әмма изгелекне кылу безне бик күп хәсрәтләрдән алып кала. Агач утырту, кошларга җимлекләр ясау, мәчетләр салдыру, чишмә һәм сулыкларны чиста тоту, кешеләргә җиңел булсын өчен юлны чистарту, күперләр салдыру бик саваплы гамәлләр. Гади сүз әйтеп кәрдәшеңне сөендерү, аның бурычларын түләү, мәшәкатьләрен хәл итү дә безне Аллаһы каршында олы дәрәҗәгә күтәрә. Гаиләгә яхшы мөнәсәбәттә булу, аны тәэмин итү дә иң күркәм садакадыр. Бу дөнья – Ахирәтнең бакчасы. Шушы бакчага нинди үсентеләр утыртылса, шул үсенте бирә торган җимешләр бирер. Әгәр без бакчабызга аллыгөлле чәчәкләр, татлы җимеш агачлары утыртсак, нинди уңышлар бирер алар? Әлбәттә, матур чәчәк, татлы җимешләр булачак. Әгәр инде ул бакчага чүп үләннәре чәчсәң, анда чүп үсәр. Тормышта да шулай: садакаларыбыз нур булып, бу дөньябызны да, Ахирәтебезне дә якты кыла.

Әмма риядан саклану да бик мөһим, чөнки рия, безнең изге гамәлләребезне яндыра. Бик күп еллар элек эшләгән изгелекләребез белән изгелек эшләнгән кешене кимсетәбез икән, бу ничә еллар буе торган изгелек тузан булып кала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Уң кулыгыз биргәнне сул кулыгыз белмәсен», – дип әйткән. Бу хәдистән аңлашылганча, садаканы ихласлылык белән бирүебез мөһим. Күңелләребезгә бер генә мизгелгә дә шушы садака белән мактану, калганнарны кимсетү, тәкәбберләнү уе керергә тиеш түгел. Бүген күп кешеләр садака бирәләр дә, шушы изгелек артыннан авырлык килгәч: «Мин изгелек кылдым, нигә Аллаһы миңа авырлык китерде икән?» – дип тәкъдирләренә ризасызлык күрсәтәләр.

Әмма шуны да онытмыйк, әгәр изгелек кылгач, авырлык килә икән, димәк, безне олырак хәсрәт көткән булырга мөмкин, ә Аллаһы Раббыбыз безнең шушы хәсрәтне җиңелрәк сынауга алыштырды. Без садаканы бу дөньяда җиңеллек теләп кенә бирсәк, Ахирәтебезгә нәрсә калыр? Шушы хакта уйлап караганыбыз бармы икән? Без –мөселманнар бу дөньядан

кала, әле Ахирәт барлыгына ышанабыз, гәмәлләрнең әҗерен бары Аллаһы каршына баскач кына алачагыбызга ышанабыз.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, шушы изге Рамазан аенда изге гамәлләребезне бигрәк тә арттырыйк. Садакаларыбызны мөмкин кадәр күбрәк биреп, мохтаҗларны сөендерик. Алар сөенгән вакытта, күңелләреннән чыккан сүзсез догадан да хәерлерәк дога булмас. Фитыр, зәкят садакаларын шушы айда бирергә тырышсак иде. Инде гает намазларына килгәндә, фитыр садакаларыбызны биреп, мохтаҗлар шушы бәйрәм рухын сизеп, киләсе елларда шушы айда аларда да күп гыйбадәт кылу теләге туса иде. Аллаһы Раббыбыз изгелек кылучыларны ярата. Аллаһының яратканнары арасында булырга тырышыйк, изгелекләр кылып, җир йөзендә сөенеч таратыйк. Аллаһы Тәгалә барчабыздан да разый булса иде. Әәмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*29 нчы апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буена 1443 ел*

# Рамазан бәрәкәте

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салаватшәрифләребез ирешсен. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Бүгенге вәгазебез Рамазан аеның бәрәкәте турында булыр, иншәАллаһ. Рамазан ае – рәхмәт ае. Рамазан ае – уңыш алу ае. Рамазан ае – изге Коръән ае. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үрнәген генә алсак та, Рамазан ае аның өчен башка айлардан үзенчәлекле һәм бик мөһим урын алып торган. Юмартлыгы, гыйбадәтен арттыруы һәм башка күркәм сыйфатлары изге Рамазан аенда аеруча чагылган.

Бу изге айның бәрәкәтен, рухын киләсе ел уразасына җитәрлек итеп ничек саклап калырга соң? Беренчедән, бу изге айга алдан ук әзерлек эшләрен башларга кирәк. Ураза ае җиткәнче барлык эшләреңне тәмамлап, барасы җирләреңә барып, тулысынча вак-төяк эшләрдән азат булырга кирәк, чөнки Рамазан ае вакытында күп вакытыңны дөнья эшләренә сарыф итсәң, ай үтеп китәр, ач торудан гына файдасы да булмас. Рамазан аенда үтәрмен дип планлаштырган гыйбадәтләреңне дә күтәрә алмассың. Икенчедән, Рамазан аенда гыйбадәт «арысланы» булырга кирәк. Югарыда искә алып үткәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яки сәхабәләребез үрнәгенә ияреп, вакытыбызның күп өлешен гыйбадәткә сарыф итәргә кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу

галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Рамазан ае җитеп тә, Аллаһының кичерүенә ирешмәгән затка кайгыдыр»[1], – дип әйткән.

Бу хәдистән кеше никадәр тырышырга тиеш икәнлеген аңлап була. Аннан соң, Рамазан ае – ул бит рәхмәт һәм мәгъфирәт ае. Шуңа күрә хәтта безгә авыр, җәза булып тоелган нәрсәләр дә асылда – Аллаһының рәхмәте. Мисал өчен: Рамазан уразасын сәбәпсез бер көн калдырган өчен алтмыш көн өстәмә ураза йөкләнә. Шарты – өзмичә, тоташ тоту. Бер яктан, нинди авырлык, катгый канун, кешегә уразасын калдырмасын өчен куркыту җәзасы кебек күренә. Ә асылда, аның икенче мәгънәсе бар. Рамазан аеның беренче көннәре кешегә авыррак бирелә, тән ияләнмәгәннән хәлсезлек тоела. Ләкин ахыргы ун көн бик җиңел генә үтә: Рамазан ае бетүе белән, җиңеллек башлангач кына тәмамланып куя. Алтмыш көнне тоткан кешенең шулай ук тәне ияләнә, җиңеллек килә. Тәне шуның кадәр ияләнә, хуҗасына буйсына башлый. Кеше тели икән – гыйбадәтен кыла. Тели икән башкасын эшли, нәфесе буйсына. Һәм кеше шуны аңлый – ошбу өстәмә алтмыш көнне Аллаһы Тәгалә җәза итеп түгел, ә Рамазан аеның нинди рәхмәт икәнлеген, файда вә хикмәт икәнлегенә төшенү өчен биргән. Кешедә калдырган көне өчен үкенү хисе туа, чөнки ул калдырган вакытлар, форсатлар кире кайтмый.

Менә шулай, хөрмәтле дин кардәшләрем! Рамазан аен бушка уздырмыйк. Быел ураза яз уртасына туры килә. Яз вакыты – хезмәт башыдыр. Рамазан аенда мөмкин булганча изге гамәлләр кылыйк. Зират җирлекләрен тәртипкә китерү, бакыйлыкка күчкән дин кардәшләребезнең каберлекләрен җыештыру, аларны искә алу, рухларына дога кылу, үзебезнең дә киләчәк йортыбыз булачагына инану, киләчәк буыннарга үрнәк күрсәтү кебек изге гамәлләрне искәртми мөмкин түгел. «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел», дип юкка әйтмәгәннәр. Бәрәкәтнең төп хикмәте булып – изге ният һәм тырышлык булып кала, хөрмәтле дин кардәшләрем.

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазебезне кабул кылсын, файдаланырга насыйп итсен. Гөнаһларыбызны кичерсен. Әәмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре*

*2 нче май вәгазе,*
*шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез ирешсен. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر الله أكبر ولله الحمد

Кадерле мөселман кардәшләребез! Менә Рамазан ае – юмартлык, ураза, тәравихлар, Коръән һәм изгелекләр һәм нәфес белән көрәшү ае бездән китә. Кемнәрдер олуг әҗер-савапка ия булды һәм Рамазан аеннан файда алды. Кемдер мөмкинлекне кулдан ычкындырды һәм бернәрсәсез калды.

Олуг көн, Рамазан ае тәмамлануын белдергән изге бәйрәм – Гыйд Әл-Фитр, ураза бәйрәме җитте. Бу – Рамазан аеның нәтиҗәләрен чыгару көне. Һәркем үзенә шундый сорау бирсен: «Мин үткән Рамазанга караганда яхшырак, әхлаклырак, камилрәк булдыммы?» Әгәр бу сорауларга, әйе, дип җавап бирә алабыз икән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәр белдерик, чөнки бары Аның рәхмәте белән генә без хәерле гамәлләр кылабыз. Әгәр яхшырак, камилрәк булмасаң, яңа баскычка, рухи дәрәҗәгә күтәрелмәсәң – нәтиҗә яса һәм тормышыңны, динебез таләпләренә һәм кагыйдәләренә туры китереп, үзгәртә башла. Бу фани тормыш һәркем өчен тәгәлләнәчәк һәм без гамәлләребез белән икәүдән-икәү генә калачакбыз.

Бүген Рамазанда уңышка ирешүчеләр куансын һәм аның чиксез нигъмәтләрен ала алмаган кешеләр өметләрен өзмәсен – әле соң түгел, исән булганда, кылмый калган гамәлләребезне башкара алабыз.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر الله أكبر ولله الحمد

Бүген нәтиҗәләр чыгарыла, рухи байлыклар һәм бүләкләр бүленә.

Ураза тотучылар, ризыктан һәм судан гына түгел, ә гөнаһлы сүзләрдән, бәхәсләрдән һәм талашлардан тыелып торучылар бүген Аллаһыга шөкер сүзләре әйтсен һәм шатлансын. Бары Аллаһы гына ураза тотуның әҗер-савапларын белә.

Имам Әл-Бохари Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшырган. Анда Аллаһы Тәгаләнең сүзләре хәбәр ителә:

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачкан вакытта, ә икенчесе – гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә, Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда».

Бу хәдисне шәрехләп, имам Ибне Раҗәб Әл-Хәнбәли болай дип яза: «Аллаһы Тәгаләне очратып, кеше ураза өчен бирелгән әҗер-савапка куаначак».

Гыйбадәт кылучылар, Рамазан аенда тәравихлар һәм башка нәфел намазларын укучылар куансын!

Ышанычлы хәдистә болай дип әйтелгән:

«Берәү Рамазан аенда Аллаһының әҗер-саваплар бирүенә ышанып һәм Аның ризалыгын өмет итеп ураза тотса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителер»[1].

Бүген Рамазан аенда Коръәни Кәримне укучылар, шулай ук аны мәчетләрдә тыңлаучылар шатлансын!

Һәм Кыямәт көнендә без уразаның һәм Коръәннең шәфәгатенә өметләнәбез. Безгә гомер буе кылган гамәлләребез – бөтен сүзләребез

---

1 Имам Әл-Бохари, имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

һәм эшләнгән эшләребез күрсәтелгәч, яхшы эшләребез аз булып чыгарга мөмкин. Шулвакыт безгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм шәфәгатьчеләрнең шәфәгатенә өметләнәсе генә кала. Һәм имам Әхмәд тапшырган ышанычлы хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Ураза һәм Коръән кол өчен (Аллаһыга) шәфәгать кылыр. Ураза: «Ий минем Раббым! Мин аны көндез ризыктан һәм судан мәхрүм иттем, минем шәфәгатемне кабул итсәң иде. Коръән: «Ий Минем Раббым! Мин төннәрен аны йокыдан мәхрүм иттем, минем шәфәгатемне кабул итсәң иде», – дип әйтер. Һәм аларның шәфәгатьләре кабул ителер».

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең уразабызның һәм Рамазанда укыган һәм тыңлаган Коръәнебезнең шәфәгатен кабул кылыр.

Һәм Аллаһының рәхмәте белән, Аның иман китергән коллары мәңгегә җәннәткә керер. Җәннәт нигъмәтләре сүз белән әйтеп бетерерлек түгел һәм чиксез. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә алар хакында болай ди:

فَلَا تَعْلَمُ نَفْسٌ مَا أُخْفِيَ لَهُمْ مِنْ قُرَّةِ أَعْيُنٍ

**«[Дөньяда] Кылган [хәерле] эшләре өчен, күзләргә куаныч [китерүгә сәбәп] булачак нәрсәләрнең алар өчен яшерелгәнен һичкем [хәтта иң олуг фәрештәләр дә, пәйгамбәрләр дә] белми».**

«Әс-Сәҗдә», 32:17

Ышанычлы кодси хәдистә Аллаһы Тәгаләнең болай дип әйткәне хәбәр ителә:

«Кодрәтле һәм Бөек Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән: «Мин Үземнең тәкъва колларыма күзләр күрмәгән, колаклар ишетмәгән һәм бер кеше дә (ул нигъмәтләрне) күз алдына китерә алмаган нигъмәтләр әзерләдем».

Болар барысы да изге гамәлләр кылган: вакытында һәм камил рәвештә намаз укыган, Рамазан аенда ураза тоткан, зәкят түләгән һәм мөмкинлеге булса, хаҗ кылган, ә шулай ук хәләл ризык тапкан һәм гаделсезлек кылмаган мөэминнәргә вәгъдә ителгән. Мондый кешеләргә чиктән тыш әҗер-савап вәгъдә ителгән, ә Аллаһы Үзенең вәгъдәсен бозмый. Һәм берәү дә җәннәтнең бу мәңгелек нигъмәтләрен күз алдына китерә алмый!

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

وَيُدْخِلُهُمُ الْجَنَّةَ عَرَّفَهَا لَهُمْ

**«Һәм аларны Үзе таныткан җәннәткә кертәчәк».**

«Мөхәммәд», 47:6

Имам Әл-Куртуби үзенең тәфсирендә болай дигән: «Һәм җәннәткә керүчеләргә: өйләрегезгә таралыгыз, дип әйтелер һәм алар, җомга намазыннан соң өйләренә таралучы кешеләргә караганда да яхшырак итеп, өйләренең кайда икәнлеген белер». Һәм болар шундый өйләр булыр: тасвирлап бетерә алмаслык зиннәт, матурлык һәм байлык сарайлары!

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر الله أكبر ولله الحمد

Хәзер күп кенә кардәшләребезне борчый һәм бездән еш сорала торган нәрсә хакында әйтик: Рамазан аенда туплаган рухи дөньябыз файдаларын ел дәвамында ни рәвешле югалтмаска һәм саклап калырга? Отышлы килешүдән алган табышны вакытлар үткән саен арттырып бармасак, аның кыйммәте югалган сыман, шулай ук Рамазаннан алган рухи халәт тә беркетеп куюга мохтаҗ. Без ирешелгәннәрдән чыгып, рухи камиллек юлыннан алга таба барыр өчен нәрсә эшли алабыз?

Беренчедән, Аллаһыга бурычларыбызны бирергә тиешле. Әгәр сез, уразаның көннәрен калдырдыгыз икән, булдыра алганча тиз арада аларны үтәргә тырышырга тиеш. Әгәр сезнең үткән елда калган укылмый калган намазларыгыз һәм уразаларыгыз бар икән, аларны үти башлар өчен

ныклы ният кылыгыз һәм, хәтта әгәр калдырылган уразаларыгыз һәм намазларыгыз күп булса да, көчегездән килгәнчә аларны үти башлагыз.

Шуннан соң шәүвәл аеның 6 көн уразасы хакындагы мөһим сөннәтне онытмыйк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Берәү Рамазан аенда ураза тотса, ә аннары шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, ул ел буе ураза тоткан кеше кебек булыр»[1].

Шәүвәл ае уразасын айның 2 нче көненнән үк тота башларга да һәм теләсәгез, рәттән тотмыйча, бу айның теләсә кайсы 6 көнендә тотарга да була.

Өченчедән, ел дәвамындагы нәфел уразалар хакында онытмагыз. Дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә, ай уртасындагы 3 көндәге уразалар яки нык кешеләр өчен Давыд галәйһиссәлам уразасын, ягъни көнаралаш ураза тоту.

Рамазан ифтарларының атмосферасын ел дәвамында саклап калырга мөмкин: мәсәлән, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ифтарларга җыелыгыз һәм сез Рамазанны һаман да яныгызда итеп тоярсыз.

Бигрәк тә төнге вакытларда өстәмә намазларны калдырмагыз. Әйе, Рамазан үтте, мәчетләрдә тәравих намазлары укылмый, әмма ел әйләнәсендә төнлә укыла торган сөннәт намазлар да бар. Бу, төнлә 2, 4 рәкәгать итеп укыла торган, кыйммәтен бәяләп бетереп булмый торган тәһәҗҗөд намазы. Рамазанда тәравихка килгән сыман, мәчеткә килүегезне дәвам итегез.

Аннары Коръән укуны туктатмагыз. Күпләр, кызганычка, даими рәвештә аны бары Рамазан аенда гына укый, аннары 11 ай Коръән киштәдә тузан җыеп ята. Үзегезгә көн саен укырга кыен булмаган берничә битне укуны билгеләгез һәм әкренләп, битләрнең санын арттырып барыгыз.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر الله أكبر ولله الحمد

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Иң мөһиме – даими рәвештә изге гамәлләр кылу, аз булса да, һәрдаим эшләү. Ислам диненең элеккеге галимнәренең берсе болай дигән:

«Мөэмин кеше гөнаһтан һәм Аллаһыга итагатьсезлек күрсәтүдән качкан һәр көндә бәйрәм бар. Һәм мөэмин Үзенең Раббысына итагать итеп үткәргән һәр көн – бәйрәм».

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең уразаларыбызны, намазларыбызны һәм укыган Коръәннәребезне – безнең гыйбадәтләребезне һәм изге гамәлләребезне кабул кылса иде. Безнең халәтләребезне һәм барлык мөселман өммәтенең халәтен хәерле кылса иде. Әәмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلَّا الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الأَئِمَّةِ رِضْوَانَ اللَّهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذَ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللّهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الراَحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү'миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа'имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа'имиинә әбүәәбән-нииraани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа'имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа'имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-Куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ҙүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гуҫмәәнәз-ҙиннүрайни вә Галийинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгууҙу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләҙиинәт-тәкау

вәлләẓиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-гаẓыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәẓẓикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-гаẓыйимү сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну'минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдүән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Ташлар белән кыйналып, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*6 нчы май вәгазе,*

*шәүвәл аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буена 1443*

# Матурлык –котылуның бер юлы

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, барлык мәхлүкатларны Тәрбия кылучы, Кыямәт көненең Хуҗасы булучы Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз, данлау-шанлауларыбыз булса һәм ирешсә иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе, хатәмәннәби, хак Расүле – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә йөрәкләребез түреннән чыккан салаватларыбыз һәм сәламнәребез булса иде.

Хөрмәтле җәмәгать, дин-мөбиндә булган кардәшләрем, сезгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең күркәм сәламнәрен ирештерәм. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

«Матурлык дөньяны коткарыр», – дип язган рус язучысы Ф.М. Достоевский. Әмма өстәп тагын әйтәсе килә, матурлык ул Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләнең ризалыгына ирешергә дә ярдәм итәр. Матурлыкны күрә, аны тудыра һәм саклый белгән кеше беркайчан да җинаять кылмас, кешене хөрмәт итә, хезмәтен бәяли белер.

Матурлык – ике төрле буладыр. Беренчесе – тышкы матурлык, ә икенчесе – эчке матурлык. Тышкы матурлык – ягымлылык, сөйкемлелек, үзенә нык җәлеп итә торган тышкы кыяфәт – чибәрлек. Аның табигый гүзәллегенә карап хозурланып та була.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Миңа илче җибәрсәгез, күркәм йөзлесен җибәрегез», – дип әйткән.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер хәдисендә: «Ирләрнең матурлыгы – телендәдер», – дип әйткән. Бу хәдис эчке матурлык белән тышкы матурлыкны бәйлидер кебек. Әбибабаларыбыз «Уйдагысы телендә», дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр бит. Кешеләрнең сүзгә осталыклары хәтта милләтләрнең исән калуларына хезмәт итә. Ләкин тышкы матурлык кайвакыт алдакчы да булырга мөмкин.

Эчке матурлык – кешенең холкындагы, эшчәнлегендәге уңай, хуплана торган сыйфат, кече күңеллелек, йомшаклык, кешенең эчке матурлыгы, җыеп әйтсәк, тәкъвалыгы, хәялыгы. Болар карар күзгә күренмәс тойгылар. Эчке һәм тышкы матурлыкны күңелгә рәхәтлек, ләззәт бирә торган нәрсәләрдән тора, дип әйтергә мөмкин булыр. Халык телендә шундый әйтем бар: «Киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар», ягъни иң әүвәл кешенең чибәрлегенә, киеменә игътибар бирәләр, яши-яши аның эчке матурлыгына әһәмият бирәләр һәм шуның белән хөкем чыгаралар. Бер караганда, бу ике матурлыкны бүлеп карау дөрес тә түгелдер, чөнки алар бер-берсенә шуның хәтле тыгыз бәйләнгән, чикне табу мөмкин булмас. Эчке матурлыксыз тышкы матурлык була алмас, эчке матурлык тышкы матурлыкны тудыра һәм киресенчә.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ بِذَاتِ الصُّدُورِ ﴿٢٣﴾

**«.... Һичшиксез, Аллаһы күкрәкләре ия булган нәрсәне [күңел түрләрендәге барлык серләрне, ниятләрне һәм ышануларны] белүче».**

«Локман», 31:23

Эчке матурлыкны тудыручы халәт – ул тәкъвалык, ягъни Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләдән куркып, гөнаһлы гамәлләр кылудан тыелу, андый гамәлләрдән бизү, үзеңдә булдырмау. Мондый бәндәнең калебе

җәберләү, нәфрәт, көнчелек һәм башка тискәре сыйфатлардан азат була. Әлхәмдүлилләһ!

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзенең Китабында болай дип әйтә:

إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең асыл нәселдән булуыбызга да, тышкы матурлыгыбызга да, гыйлемебезгә дә карамый, күкрәгебездәге калебкә игътибар бирә икән. «Раббысының хөкеменә тугры булучы, аңа хилафлык кылмаучы, Минем каршымда хөрмәтлегез,» – дип әйтә. Эчке матурлык, әдәплелек, хөрмәтлелек һәм башка уңай сыйфатларны фәкать тәкъвалык кына тудыра ала, тискәре сыйфатларны тудырмас. Бәндә һәрвакыт үзе өстендә эшләргә, үзен яхшы-хәерле кешеләр рәтенә кертергә омтылырга һәм шуңа ирешергә тырышырга тиеш.

Алга таба Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый яхшы – хәерле кешеләр хакындагы хәдисләрен карап үтәрбез.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм «сезләрдән иң яхшыларыгыз (матурларыгыз)» дип түбәндәгеләрне атаган:

1. «Коръәни Кәримне өйрәнеп башкаларга шуны өйрәткәннәр»[1].

2. «Күркәм холыкка ия булучылар, алар белән бергә яхшы яшәргә мөмкин булган кешеләр»[2].

3. «Бурычын вакытында кайтаручылар»[3], ягъни җиңел түләүчеләр.

1 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 5027; «Мең дә бер хәдис», 416.

2 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 6035; «Мең дә бер хәдис», 417.

3 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 2393; «Мең дә бер хәдис», 418.

4. «Мөселманнарның иң яхшысы – мөселманнар аның кулыннан һәм теленнән сәламәт булганнар»[1].

5. «Үзенең гаиләсенә яхшы мөгамәләдә булганнар»[2].

6. «Мохтаҗларны тукландыручы һәм сәламгә яхшы сәлам бирүчегез».

7. «Яхшы гамәлләр белән озын гомерле булганнар»[3].

8. «Кешеләрнең иң яхшысы – файдалы булганыгыз»[4].

9.«Үзенең дустына җылы мөгамәләдә булучы дус, Аллаһы каршында иң яхшы күрше, күршесенә күркәм сыйфатлар белән аралашучыгыз»[5].

10. «Калебе чиста, теле дөреслекне генә сөйләүчегез». Сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән болай дип сорадылар: «Теле хакыйкатьне сөйләүчене дигәнне аңлыйбыз, ә менә калебе чиста дигәне нәрсә аңлата?» Расүлебез салләллаһу галәйһи сәлләм аларның бу соравына болай дип җавап биргән: «Аллаһыдан куркучы, чиста-пакь, гөнаһсыз, җәбер-золымсыз, нәфрәтләнмәүче, көнләшмәүче-хөседсез йөрәккә (калебкә) ия булучыгыз».

Алда әйтелгәннәрне җыеп бер йомгакка тупласак, бәлки аның мәгънәсен Расүлебезнең хәдисләреннән табарбыз. Йә Раббым Аллаһы! Безләрне матурлык иясе булырга насыйп әйләсәң иде, изге гамәлләр кылып, Үзеңнең ризалыгыңа ирешеп ахыр урыннарыбыз җәннәт булса иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», - дип әйткән.

[1] «Мең дә бер хәдис», 424.

[2] Имам Ибне Хиббан хәдисләр җыентыгыннан, 4177; «Мең дә бер хәдис, 419.

[3] «Мең дә бер хәдис», 420.

[4] «Мең дә бер хәдис», 426; 894.

[5] «Әл-әдәб әл-мофрад» хәдисләр җыентыгыннан, 84.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Кәдим хәзрәт Мөбарәкшин,*

*Буа районы Килдураз авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*13 нче май вәгазе,*

*шәүвәл аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Намазның файдалары

Галәмнәрне юктан бар итеп, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы бөек кодрәт иясе, Җир вә күкләрнең Раббысы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә күңел түребездән чыккан сәламнәребез ирешсә иде. Бу дөньяга соңгы пәйгамбәр буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез, хәбибебез, остазыбыз Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә чиксез салаватларыбыз ирешсен.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الدِّينَ عِندَ اللَّهِ الْإِسْلَامُ... ﴿١٩﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә].**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

Ислам динен үзенә якын итеп һәм чын күңелдән ышанып, хак дин дип тапкан һәр мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына омтыла. Һәм ул кеше барлык гамәлен, эшен башкарганда, бүтән бертөрле ният белән дә башкармас, фәкать Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен генә башкарыр. Әлбәттә, Кыямәт көнендә һәрбер кеше үз гамәлләренең кем өчен башкарганын белер: Аллаһы ризалыгы өченме, йә булмаса кеше күрсен дипме? Ә Кыямәт көнендә беренче соралган нәрсә ул – намаз. Бу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә килә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу диннең башы – Ислам, аның терәге – намаз»[1], – дип әйткән. Шуңа күрә бу гыйбадәтебезне аеруча игътибарлы

[1] Имамнар Әт-Тирмизи, Ән-Нәсаи хәдисләр җыентыгыннан.

булып, һәм, әлбәттә, Аллаһы Тагаләнең ризалыгы өчен генә башкарырга кирәк.

Әхмәд бине Монтафыйк болай дип сөйләгән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гарәфәттә булганда мин аның янына килдем дә: «Мин синнән ике нәрсә сорыйм: мине нәрсә уттан коткарачак һәм җәннәткә керергә ярдәм итәчәк?» – дип сорадым. Ул болай диде: «Синең соравың кыска, ләкин син ирешү юлы озын булган бөек эш турында сорыйсың. Хәзер мин сиңа әйткән нәрсәләрне истә калдыр: Аллаһыга гыйбадәт кыл, фарыз намазларын укы, фарыз булган зәкят түлә, Рамазанда ураза тот, кешеләр үзеңә нинди мөнәсәбәттә булуларын теләсәң, син дә аларга шундый мөнәсәбәттә бул! Үзең өчен яратмаган нәрсәләрдән кешеләрне дә азат ит».

Бу хәдис аша Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм кайсы гамәлләр адәм баласын җәннәткә илтеп, ә кайсылары җәһәннәм газабыннан ерагайтуын аңлата. Без беләбез: намазсыз җәннәтле булып булмый.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янә бер хәдисендә әйтә: «Тәһарәт – намаз ачкычы, намаз – җәннәт ачкычы». Димәк, җәннәтле булырга теләгән һәркем намазларын үз вакытында башкарырга тиешле.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә безгә болай дип әйтә:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ ﴿٢﴾

**«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште [һәм өметләре гамәлгә ашты]. Кемнәр [Аллаһының хозурында булган кебек] намазларында [карарга тиешле урынга карап, бөтен әгъзаларын да тыныч тотып һәм күңелләре белән Раббыларына юнәлеп] түбәнчелеклеләр».**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Аллаһы Тәгалә мөэминнәрнең бәхет-сәгадәткә ирешүләре турында әйтте һәм аның юлларын күрсәтте. Ягъни намазларыбызны курку вә басынкы халәтебездә, буйсынып, бирелеп үтәү намаз кабул булуның бер шарты булып тора икән. Хошугълык белән уку – үзеңне Аллаһы Тагалә каршында басып торган кебек хис итү ул. Намаз укучының күңеле шушы хискә бәйле тынычлана төшә, бертөрле килешкән хәлгә керә, намаздагы һәр хәрәкәте өчен борчыла. Ул намаз укыган вакытта чит гамәлләр эшләми, тирә-якка карамый, чөнки Аллаһы Тәгәлә белән әңгәмә әдәбен сакларга тырыша.

Ә хәзер үзебезнең намазларыбыз турында уйлыйк әле. Без аларны Аллаһы кушканча үтибезме? Җиңел карап үтәлгән намаз яисә кемгәдер мактану, кеше күрсен өчен, мине мөселман, намаздагы кеше дип сөйләсеннәр өчен укылган намаз бәхет-сәгадәт чыганагы була алмый. Кайчакларда мөселманнар мәчеттә намаз укыгач, имам нинди сүрәләр укыды әле, дип баш вата башлыйлар. Бу хәтер начарлыктан түгел, бу – игътибарсызлыктан, намазда хошугълык җитмәүдән.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَّوْقُوتًا ﴿١٠٣﴾

**«Һичшиксез, намаз кешеләргә вакыты билгеләнеп фарыз кылынган».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:103

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый хәдисе бар: «Аллаһының барлык гамәлләр арасында иң яратканы – вакытында укылган намаздыр». Чыннан да, әгәр берәр кеше төрле сәбәпләр аркасында намазларын укый алмаган икән, йә булмаса, эшләү сәбәпле намазларын җыеп укырга мәҗбүр була икән – намазның «тәме» бозыла. Җитмәсә, намазның вакыты чыккач, ул намазның сөннәтен дә укымыйбыз. Бер-бер артлы укыган намаз белән һәр намазның вакытын аерым көтү – икесе ике

төрле күренештер. Моның турында да бераз булса да уйлансак иде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мәңге яшим дип дөнья көт, бүген үләм дип гыйбадәт кыл», – дип әйткән. Ягъни дөньялыкны кайгыртканда эшләгез, хезмәт итегез, тырышыгыз, гаиләгезне дә алып барыгыз, балалар да тәрбияләгез, йорт-җир, машина да булдырыгыз, бу дөньяга мәңге килгән сыман тормышыгызны алып барыгыз. Ә Ахирәтегезне кайгыртканда: намаз укыганда, ураза тотканда, хаҗ кылганда, зикерләр әйткәндә соңгы гамәл-гыйбадәтемне башкарган сыман бирелеп, Аллаһы Раббыбызның ризалыгы өчен дип башкару турында бу хәдис.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчеткә кергән саен бер кешенең һәрдаим намаз укып гыйбадәт кылуын күргән, һәм сәхабәләреннән бу кешенең кем булуын, гаиләсе, балалары булу-булмавын, аларны кем ашатуын, ни өчен аның һәрвакыт мәчеттә утыруы хакында сораган. Сәхабәләр: «Ул көн-төн гамәл гыйбадәттә, зикердә, бик тәкъва, динле кеше диләр. Гаиләсе, балалары бар. Аларны да, бу кардәшне дә бертуган абыйсы ризыкландыра, тәрбияли диләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аның менә шушы абыйсы җәннәтле булыр», – дип әйткән. Шуңа күрә һәркем дөньясын кайгыртып Ахирәтен онытмасын, ә Ахирәтен кайгыртканнан соң дөньялыгын алып барырга да тырышсын.

«Биш вакыт намаз турында Коръәндә әйтелгәнме?» – дип соралгач, Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Әйе!» дип, шушы ике аятьне («Әр-Рум» сүрәсенең 17-18 нче аятьләрен) укыган һәм: «Бу аятьләр биш вакыт намазны да, аларның вакытларын да аңлатты»,[1] – дип әйткән.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдисшәрифтә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кем дә кем «Рум» сүрәсенең шушы өч аятен иртән укыса, ул көнне кыла алмаган

1 Әбү Давыд, Әдәб: 110, № 5076, 2/740.

бөтен хәерләрнең савабына ирешкән булыр. Кичен бу аятьне укыган кеше исә ул төнне кулдан ычкындырганнарына ирешкән булыр».

فَسُبْحَانَ اللَّهِ حِينَ تُمْسُونَ وَحِينَ تُصْبِحُونَ ﴿١٧﴾ وَلَهُ الْحَمْدُ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَعَشِيًّا وَحِينَ تُظْهِرُونَ ﴿١٨﴾ يُخْرِجُ الْحَيَّ مِنَ الْمَيِّتِ وَيُخْرِجُ الْمَيِّتَ مِنَ الْحَيِّ وَيُحْيِي الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا ۚ وَكَذَٰلِكَ تُخْرَجُونَ ﴿١٩﴾

> **«Кичкә кергән чагыгызда [ахшам-ястү намазларын укып] һәм таңга кергән чагыгызда [иртәнге намазны укып, төн һәм көн нигъмәтенә шөкер өчен] Аллаһы – пакь [дип мактагыз]. Күкләрдә һәм җирдә булган барча мактау – Аңа гына, көннең ахырында да [икенде намазын], өйләгә кергәч тә [өйлә намазын укыгыз]. Ул [Аллаһы Тәгалә мәни һәм орлык кебек үзлегеннән үрчемәгән] үледән [җанлы һәм үсемлек кебек үрчегән] терене чыгара, тередән исә үлене чыгара, үлеменнән соң туфракны да Ул җанландыра. Сез дә шулай [каберләрегездән] чыгарылачаксыз».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:17-19

Әбү Габдрахман Габдулла бине Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе сөйләгән: «Мин Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дигәнен ишеттем: «Ислам биш теräккә нигезләнә: «Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аның Расүле» дип шәһадәт бирү, намаз уку, зәкят түләү, хаҗ кылу, Рамазанда ураза тоту»[1].

Аллаһы Тәгалә кылган гамәлләребезне кабул әйләп, киләчәктә дә көн вә төннәребезне изгелектә, игелектә үткәреп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатенә, Раббыбызның

[1] Имамнар Әт-Тирмизи, Ән-Нәсаи хәдисләр җыентыгыннан.

мәгъфирәтенә ирешергә, ике дөньяда да бәхет-сәгадәтле булырга насыйп булсын. Әәмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мансур (Ансар) хәзрәт Мифтяхов,*
*«Әл-Мәрҗани» мәчете имамы*

*20 нче май вәгазе,*

*шәүвәл аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Болгар бабаларыбызның Ислам динен кабул итүе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әмма бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә, салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһының рәхмәте белән без шушы көннәрдә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итәбез. 1100 ел безнең бабаларыбыз Ислам динендә. Багдад хәлифәтенең илчелеге Болгар дәүләтенә килеп, Ислам дине бу җирлектә рәсми рәвештә кабул ителә. Әлбәттә, җәмәгать, уйлый башласаң, аның фазыйләтләре, дәрәҗәләре, татар халкына китерә торган файдалары шактый: беренчедән, күз алдыбызга китерик, без төрле кабиләләргә бүленгән, үзара сугышкан. Хәзәр каганаты үз файдасына тырышкан, аларга түләгән X нчы гасырны искә алыйк. Шул вакытта без берләшеп, Бөек Болгар дәүләтенә әйләнәбез, әлхәмдүлилләһ. Шушы безнең идеологик ислам була. Җәмәгать, хәзерге дәверне карасак, без таралдык: кемдер үзен мишәр дип әйтә, кемдер себер татарлары ди, кемдер башка милләт. Хәзер берләшик: кайда гына торсак та, без бөтенебез бер халык – татарлар. Кемдер, әйдәгез болгар халкы итеп язылыйк ди. Әмма без ничек аталсак та, без татарлар, бердәм булыйк.

Икенчедән, безгә юллар ачыла, мөмкинлекләр бирелә. Халкыбыз гыйлемгә омтыла, югары уку йортларына барып укый алабыз. Шушы ислам

дәүләтендә булган гыйлемне ала алабыз. Бездә, аннан соң, тарихтан карасак, Болгар галимнәре, шәһәрләре, тарихчылары чыга, әлхәмдүлилләһ. Җәмәгать, без шушы юбилейдан зур дәрес алыйк, дус, тату, гыйлемле һәм бердәм булыйк!

Аллаһының рәхмәте, Болгар җирлегенә дин килү белән, аңа кадәр дә безнең әби-бабайларыбыз бик гыйлемле булганнар. Әгәр дә алар укымышлы, тырыш сәүдәгәрләр булмасалар, аларның язуы да, тарихы да булмас иде. Дин килү белән, шәригать ягыннан карасак та, география, астрономия, тарих, кебек дөньяви фәннәр алга киткән. Аларның китаплары хәтта бүгенге көндә дә саклана. Шулай ук шигърият ягыннан «Кыйссаи Йосыф»ны һәм башка китапларны карасак, аларның гыйлеме күренә. Безгә дә Аллаһы Тәгалә динле булып, үз милләтен, телен белеп, шушы вазифаны алып барырга Аллаһы Тәгалә насыйп итсә иде.

Әлбәттә, Болгар ханлыгын бетерсәләр дә, Раббыбызның ярдәме белән, безнең тамырлар, безнең тарих бетмәгән. Хәзер безне татар халкы дип йөртәләр. Безнең башкала Болгар түгел, Аллаһының рәхмәте белән – Казан. Тарихтан хәтерлибез, беләбез, патша заманында булса да, нинди данлыклы гаиләләрне карасаң да, бөтен гаилә үз тамырларын шушы татар халкыннан ала. Мәсәлән, шул ук Г.Р. Державинның да, тарихчылар әйтүе буенча, М.Ю. Лермонтовның да, Н.М. Карамзинның да, И.С. Тургенев, А.И. Купринның да тамырлары бездән килә, безнең каннарыбыз аларда да ага.

Болгар ханлыгыннан башлап, хәзерге дәвергә кадәр, Аллаһы Тәгалә безне төрлечә сыный. Раббыбыз рәхмәте белән динебез безне саклый, аның ярдәмендә без гореф-гадәтләребезне югалтмадык, милләтебезне, туган телләребезне сакладык. Әлхәмдүлилләһ, без меңләгән еллык тарихыбызны югалтмадык, бабаларыбыз дин байрагын алып барган, укымышлы булган, без дә шулай ук намазлы, изге гамәлле булыйк.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Мөэмин-мөселман бу дөньяда ике канатлы кош сы-

ман булырга тиеш. Бер канаты – бу дөнья: дөньяви гыйлем булса, икенчесе – Ахирәт: дини гыйлем, намаз, ураза», – дип әйткән. Хәдистән аңлашылганча, безгә дөньяви гыйлем алырга кирәк, балаларыбыз институтларда, академияләрдә укысыннар, төрле һөнәрләр өйрәнсеннәр, кул белән дә эшли белсеннәр. Шул ук вакытта, кош икенче канатсыз оча алмаган кебек, балаларыбыз да икенче канатсыз – динсез, әдәп, әхлаксыз яши алмаслар. Бабаларыбыздан калган гыйлемнәрне балаларыбызга тапшырыйк, алар мәчетләргә йөрсеннәр, мәдрәсәләрдә гыйлем алсыннар, төрле-төрле телләр өйрәнсеннәр, үз туган телен дә белсеннәр. Коръәнне ятласыннар, әби-бабаларыбыз язган китапларның төп нөсхәләрен укый белсеннәр иде. Ничәмә ничә еллар дәвамында булган тарих язылган иске имляне уку сәләтен дә Аллаһы Тәгалә җиңеллек белән насыйп итсен.

Раббыбыз безгә, адәм балаларына, шушы эшләребездә тырышлык, тәвәккәллек, сабырлык бирсен. Дәвамлы булып, милләтебезне, телебезне, саклап калыйк, киләчәк буыннарга да тапшырыйк!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*
*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*27 нче май вәгазе,*
*шәүвәл аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Балага исем кушу

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Бала туды, гаиләгә куаныч, йортка ямь өстәлде. Бала – ул Аллаһыдан булган могҗиза, сер, әманәт ителгән вазифа. Шатлыклар белән бергә, яңа туган сабый әти-әнигә, әби-бабайга өстәмә күңелле мәшәкатьләр дә алып килә. Бала туу турында тизрәк туганнарга, дусларга хәбәр итәргә кирәк. Яңа туган баланың әти-әнисен котлау тиешле. Шәригатебездә бала тугач котлап дога кылу бар.[1]

بَارَكَ اللهُ لَكَ فِى الْمَوْهُبِ لَكَ وَشَكَرْتَ الْوَاهِبَ وَبَلَغَ اشُدَّهُ وَ رُزِقْتَ بِرَّهُ

«Бәәракәллааһү ләкә фил мәүһүби ләкә вә шәкәртәл вәәһибә вә бәләга әшүддәһү вә рузикътә бирраһү».

«Биргән бүләк белән Аллаһы Тәгалә сине шөкер-имин итсен. Син Бүләкләүчегә рәхмәтеңне ирештерерсең, балаңның үсеп җитүен һәм сиңа мәрхәмәтле булуын күрергә насыйп кылсын».

Бу котлаулар, хәерле теләкләр әти-әнине шатландыра. Туганнар, кардәшләр арасында дуслык ныгый, бер-береңә хөрмәт арта. Бүләкләр бирү дә күркәм гамәлләрдән санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер-берегезгә бүләкләр бирегез, ул бер-береңне сөю хисен арттыра», – дип әйткән.

---

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Бала тууын ишеткәч, туганнар килә. Балага исем кушканчы, йортка Коръән уку саваплы һәм кирәкле гамәл. Беренчедән, Коръән укылган йортка бәрәкәт иңә, гаилә ныгый, йортка фәрештәләр керә, шәйтаннар кача. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йортка Коръән уку өч нәрсәдән саклый: көферлектән, фетнәдән, сихердән. Коръән укылса, сез үзегезне кальга эчендә саклануда дип уйлагыз», – дип әйткән.

Икенчедән, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ... ﴿١٥٢﴾

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын...».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

Йортта бала туу зур шатлык булганлыктан, без шөкер йөзеннән Коръән укырга тиешбез. Коръән укыр алдыннан, бала тәрбияләү юнәлешендә вәгазьләп узу хәерле булыр, чөнки баланың әти-әниләре яшьләр күп нәрсәне белеп бетермәскә мөмкиннәр.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Һичбер ата үзенең баласына яхшы тәрбия бирү һәм әдәп өйрәтүдән артык бүләк бирмәде»[1].

Бала җир йөзенә хокуклары белән килә, шул хокукларны аңлату зарур. Хокуклар белән бергә әти-әнисенә, җәмгыятькә вазифа да алып килә. Вәгазьнең нигезендә бала тәрбиясе булырга тиеш.

Коръән укып, дога кылганнан соң, балага исем кушу йоласын башкарабыз. Динебездә бала хакы дигән зур төшенчә яши. Бала тугач та ата-ананың иң төп бурычы – аңа хәерле исем кушу, чөнки исемнең балага эчке тәэсире бара. Шул исем белән дәшкән саен бала аның җисемен дә үзенә кабул итә. Моны бер мисал белән аңлатып була. Коръән аятьләренең шифалы булуын беләбез, хәтта аның мәгънәсен аңламаган кешегә дә берәр дога, йә аять укып өшкереп җибәрсәң, һичшиксез, шифасы була, димәк,

1 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

тәэсире бар дигән сүз. Шуңа күрә балаларыбызга мәгънәсе ягыннан да, яңгырашы ягыннан да хәерле, матур исем кушсак, нур өстенә нур булыр. Баланы шул исем белән Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аны мәхшәр мәйданына дәшеп чыгарачак.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнендә үз исемнәрегез белән, аталарыгызның исемнәре белән чакырылачаксыз, шуның өчен балаларыгызга гүзәл исемнәр кушыгыз!» – дип әйткән. Начар мәгънәле һәм ярамаган исем балага начар йогынты ясый, аның ямьсез холыклы булуына, авыруларга тиз бирешүенә сәбәп була. Иң гүзәл исемнәр Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары белән бәйле исемнәр санала, шулай ук пәйгамбәрләрнең исемнәре хәерле булыр.

Матур эчтәлекле, тыйнак исемнәр һәрвакыт кешеләр күңеленә хуш килә. Үсеп җиткәч, начар мәгънәле исемнәр аркасында балаларыбыз уңайсыз хәлдә калмасын өчен, ата-ана бу мәсьәләгә бик җитди карарга тиеш.

Балага исем кушу вакыйгасы бәйрәмчә башкарылырга тиеш дип әйттек. Баланы юындырып, пакь киемнәрен киендереп, аякларын кыйбла тарафына юнәлтеп, мендәр өстенә салабыз. Исем кушучы кеше баланың әтисе булса хәерле. Ләкин бүгенге әтиләр ул җаваплы вазифаны үтәргә әзер булмаганлыктан, исем кушу дин белгеченә, мәхәллә имамына тапшырыла. Имам геселле, тәһарәтле булырга тиеш. Балага исем кушучы кыйблага карап, баш очына аяк өсте торып, азан әйтеп, аннан соң иелеп, баланың уң колагына әкрен генә Фәлән улы Фәлән булдың, яки Фәлән кызы Фәлән булдың дип өч мәртәбә әйтә. Шуннан соң камәт төшерелә. Камәттән соң, иелеп, баланың сул колагына әкрен генә Фәлән улы Фәлән булдың, яки Фәлән кызы Фәлән булдың дип өч мәртәбә әйтә. Шуннан соң утырып Коръән сүрәләре укыла, дога кылына, теләкләр теләнә.

«Аллааһүммәҗгалһү бәррауү вә әмбитһү фил исләәми нәбәәтән хәсәнәү вә лиҗгалһү мәсгүүҙәң фид-дүнйәә вәл әәхыйраһ».

«Йә, Раббым, ошбу баланы изге бала кыл, вә аны күркәм үсү илә Ислам дине белән үстер вә дәхи аны дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле вә сәгадәтле кыл».

Сабый баланың колагына азан белән камәт укуның мәгънәсе һәм сере шунда: яңа туган баланың бу дөньяда ишеткән беренче сүзләре, Аллаһыны һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне олылау һәм мактау сүзләре, Аллаһыны яратырга, Аңа хезмәт итәргә, Аңа гыйбадәт кылырга, игелек-изгелеккә чакырган сүзләр булачак. Азан сүзләре шәйтанны бала яныннан куа, шәйтан коткысыннан саклый. Баланың бу дөньяда ялгыз түгеллеген, аны яратучы Аллаһы барын, адашмас өчен дини юл барын белдерә, аның күңелен тынычландыра.

Сабый туганнан соң җиденче көнендә чәчен алалар. Аны үлчәп, чәч авырлыгы күләмендә ярлыларга садака бирү күркәм гадәтләрдән санала.

Хәнәфи мәзһәбе буенча бала тугач, гакыйкә корбаны чалу мөбах (саваплы) гамәл. Башка мәзһәбләрдә – сөннәт. Гакыйкә корбанын чалуны бала туганнан алып, балигълык яшенә җиткәнче башкарырга мөмкин.

Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, гакыйкә – сабый баланың туганда булган чәче мәгънәсендә килә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм гакыйкә турында болай дип әйткән: «Бала сәлим, ягъни сәламәт булсын дисәгез, кыз бала туган очракта – бер, ир бала туса, ике сарык чалыгыз». Шул вакытта Аллаһы Тәгалә аны кабул итеп, шушы балаларга сәламәтлекләрен, уңышларын бирәчәк, иншәАллаһ.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сөннәтле гамәл һәм иң хәерле, саваплысы – гакыйкә корбанын бала туганның җиденче көнендә чалу», – дип әйткән. Гакыйкә корбаны – ул сөннәт, ягъни ихтыяри гамәл. Ул мөмкинлеккә карап чалына. Мөмкинлеге булган кеше чалдыра, мөмкинлеге булмаса, гөнаһы юк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бала туганның җиденче көнендә гакыйкә корбаны чала алмасагыз, 14 нче, 21 нче көннәрендә чалу да саваплы», – дип әйткән. Шуңа күрә

балагызга ике, өч, дүрт биш яшь булса да, мөмкинлегегез булса, гакыйкә корбаны чалыгыз, һәм Аллаһы Тәгалә кабуллардан кылсын. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Хәсән белән Хөсәен тугач, алар исеменнән Аллаһы ризалыгы өчен җиденче көнне гакыйкә корбаны чалган.

Вәгазем ахырында, бала тугач, аны яраткан һәм аның өчен газиз булган, баласы өчен теләгән әниләр догасын җиткерәм: «Йә Раббым! Рәхмәтең белән миңа бала бирдең, миңа балаларыма яхшы тәрбия бирерлек әни булуны насыйп ит. Калебемне балаларыма карата шәфкать, мәрхәмәт, сөю белән тутыр. Миңа балаларымны изге гамәлләр кылырлык, Синең каршыңда булган гыйбадәтләрен, бурычларын үтәрлек, күңел, рух, сәламәтлекләрен саф хәлдә саклап калырга ярдәм ит. Йә Раббым! Рәхмәтең белән балаларыма Исламга юл ач, ныклы, камил иман, тәүфыйк бир. Йә Раббым, газиз балаларыбызны тәрбияләргә безгә ярдәм ит.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Радик хәзрәт Кәримов,*

*Арча районы Кышкар авылы мәчете имам-хатыйбы*

*3 нче июнь вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Динсез тормыш – авыр тормыш

Барча мактауларыбыз шушы галәмнәрне юктан бар кылган, һәм шушы галәмнәрне тәрбия кылып торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез булса иде. Бәндәләрнең иң хөрмәтлесе шушы галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифәләребез барып ирешсә иде. Аллаһы Тәгалә тел ачкычлары биреп, хәерле вәгазьләр сөйләргә, тыңлаган кешеләргә дә, сөйләгән кешеләргә дә шушы вәгазьләр белән вәгазьләнергә насыйп итсә иде. Ике җомга арасында дөньядан үткән мөселман кардәшләребезгә укыган Коръәннәребезнең әҗер-саваплары барып ирешсә иде. Туры юлны таба алмый йөргән кешеләргә Аллаһы Раббыбыз туры юлны табарга ярдәм итсә иде. Авырып, Аллаһыдан шифа сораган кешеләрнең догалары кабул булып, Аллаһы Тәгалә аларга хәерле шифаларын насыйп әйләсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَنْ أَعْرَضَ عَن ذِكْرِي فَإِنَّ لَهُ مَعِيشَةً ضَنكًا وَنَحْشُرُهُ يَوْمَ الْقِيَامَةِ أَعْمَىٰ
﴿١٢٤﴾ قَالَ رَبِّ لِمَ حَشَرْتَنِي أَعْمَىٰ وَقَدْ كُنتُ بَصِيرًا ﴿١٢٥﴾ قَالَ
كَذَٰلِكَ أَتَتْكَ آيَاتُنَا فَنَسِيتَهَا ۖ وَكَذَٰلِكَ الْيَوْمَ تُنسَىٰ ﴿١٢٦﴾

**«Кем дә кем Минем зикеремнән йөз чөерсә, аны [дөньяда да, кабердә дә] авыр тормыш көтә. Кыямәт көнендә исә [Аллаһы Тәгаләгә бирәсе җаваплардан хәбәрсез һәм] сукыр рәвештә [хозурыбызга] җыячакбыз. [Шулвакыт] Ул: «Ий, Раббым! Ни өчен мине сукыр итеп терелттең? Мин бит [дөньяда чакта] күрә ала**

**торган идем?» – дип әйтер. Ул [Аллаһы Тәгалә] әйтер: «Шулай, Безнең [ап-ачык] аятьләребез сиңа килгән иде, син исә аларны кире каккан идең. Бүген син дә шулай [сукырлык һәм газап эчендә] кире кагылачаксың».**

«Та Һа», 20:124-126

Күргәнебезчә, ишеткәнебезчә безгә Ислам дине килде, Коръән килде, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм килде. Әгәр дә без Исламнан, Коръәннән, пәйгамбәрләребездән йөз чөерсәк, аларны кабул итмәсәк, Аллаһы юлыннан һәм пәйгамбәрләребез юлыннан бармасак, безне бу дөньяда ук бәхетсез, газаплы тормыш көтәчәк. Безнең тормыш тынычсыз булыр һәм күңелләребез, күкрәкләребез кысылып, адашу да булыр. Тыштан бәхетле күренеп, теләгән киемен киеп, теләгән җирендә яшәп, теләгән ризыгын ашап яшәсә дә, ләкин аның йөрәгендә ышану, инану булмаса, аның күңеле икеләнү, шикләнү һәм адашу белән тулган булыр.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре риваять ителә: «Иманлы кеше үзенең каберендә ямь-яшел бакчаларда булыр. Аның кабере (35 метрга кадәр) киңәер, һәм туган ай кебек балкып торыр. «Аның тормышы бәхетсез һәм газаплы булачак» дигән аятьне ни сәбәпле иңгәнен беләсезме? «Бәхетсез тормыш» сүзләре нәрсәне аңлатканын беләсезме? Алар: «Аллаһы һәм Аның Расүле яхшырак белә», – дип әйттеләр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы бу аятьне имансызның кабердәге газабы турында иңдерде. Аллаһы аңа 99 аждаһа җибәрер. Ул 99 аждаһаның һәрберсендә 7 баш. Кыямәт көне җиткәнчегә кадәр алар кабердәге кешене йолкырлар, чагарлар, яларлар һәм өреп газаплап торырлар»[1], – дип әйткән.

Динне кирәк тапмаган кешегә, имансыз кешегә бу дөньяда ук бәхетсез һәм авыр тормыш булыр. Ә иң аянычлысы, хәсрәтлесе – кабердәге

1 Ибне Әби Хәтим хәдисләр җыентыгыннан.

тормыш газаплы булыр. Адәм баласы тәкәбберләнеп, миңа дин кирәкми, динсез дә яшәп була бит дип, тормышны җиңелгә санап йөрмәсен. Кыямәт көнендә кубарылганда да сукыр булып кубарылып, җәһәннәмдә онытылып калырга мөмкин. Күпме кеше Аллаһы Тәгаләне танып, Ислам диненә килеп үзләрен коткарып калды. Ә күпме кеше әле дә адашып йөри. Иман тәме бер күңелгә кергәч, адашу да булмас, начар юлда йөргән кеше дә кире үз юлына әйләнеп кайтмаячак.

Ислам динендә булган, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылып яшәгән, Пәйгамбәребез юлыннан барган мөселман кешесе бу дөньяда да бәхетле тормыш кичерер, һәм кабердә дә, Ахирәттә дә уңышка ирешер. Шуңа күрә динсез яшәргә ярамый. Сынаулар, авырлыклар килгәндә дә, без иманыбызда, динебездә нык булырга тиеш. Диндә нык булмаган, икеләнгәнкешеләр турында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمِنَ النَّاسِ مَن يَعْبُدُ اللَّهَ عَلَىٰ حَرْفٍ ۖ فَإِنْ أَصَابَهُ خَيْرٌ اطْمَأَنَّ بِهِ ۖ وَإِنْ أَصَابَتْهُ فِتْنَةٌ انقَلَبَ عَلَىٰ وَجْهِهِ خَسِرَ الدُّنْيَا وَالْآخِرَةَ ۚ ذَٰلِكَ هُوَ الْخُسْرَانُ الْمُبِينُ ﴿١١﴾

**«Кешеләр арасында шундые бар, [ныклык күрсәтмичә] бер читтә [булып] Аллаһыга гыйбадәт кыла [әмма уеннан кире кайтып, гыйбадәтеннән туктарга мөмкин]. Әгәр аңа хәерле нәрсә килсә, шуның белән тынычланыр. Әмма [җаны, малы һәм гаиләсе мәсьәләсендә] аңа [мәшәкать тудырган] бер сынау кагылса, [имансызлык] ягына кабат кайта. Ул дөньяны да, Ахирәтне дә югалта. Менә бу – [һәркем аңларлык] ап-ачык бер зарар».**

«Әл-Хаҗ», 22:11

Тәфсир галиме Ибне Кәсир шушы аятьне аңлатып болай дип әйтә: «Кеше дингә кырыйдан гына керер, аның кырыенда гына йөрер. Әгәр ул

шушы диндә үзенә ошаган берәр әйбер тапса, ул диндә калыр. Әгәр ул шушы диндә үзенә ошаган әйбер тапмаса, ул аны ташлар». Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Кеше Мәдинә шәһәренә килгәч аның хатыны ир бала тапса, ә аты тайласа, ул: «Бу яхшы дин», – дип әйтер. Әгәр аның хатыны бала тапмаса, ә аты колынламаса, ул: «Бу начар дин», – дип әйтер».

Ибне Әби Хәтим Ибне Габбас радыяллаһу ганһе сүзләрен тапшыра: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бәдәвиләр Ислам динен кабул итәргә килде. Үз илләренә, туган җирләренә кайтканнан соң, ул ел яңгырлы һәм игеннәр мул уңышлы булса, алар: «Безнең дин – яхшы дин», –дип әйттеләр һәм Ислам динендә калдылар. Әгәр инде ел коры килсә, ачлык булса, маллары үрчемәсә, алар: «Безнең динебездә бернинди яхшылык та, изгелек тә юк», – дип әйттеләр. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән: **«Эшләрендә уңыш килсә, бик нык шатланалар, кыенлыклар килсә, чырайлары үзгәрә, йөз чөерәләр. Андыйлар дөньясын да, Ахирәтен дә югалталар. Менә шушы булыр ап-ачык мәхрүм калу».**

Дин кардәшләрем, без дә шушы аятьтәге кебек булмыйк. Рәхәт вакытта Аллаһыны мактап, авырлык килгәч Аллаһыга, дингә тел-теш тидермик, алайса ачы хәсрәттә һәм зур югалтуда калырбыз. Юкка гына пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм догаларының берсендә болай дип әйтмәгәндер: «Әй, йөрәкләрнең халәтен үзгәртүче, минем йөрәгемне Үзеңнең динеңдә беркет».

Йөрәкләребездә ислам нуры, иман нуры булса, күңелләребез дә тыныч булыр. Безгә кадәр яшәгән тугры бәндәләр бер-берсенә әйтә торган булган: «Әгәр дөнья ләззәтләренә чумып яшәүче патша балалары безнең күңелебездә күпме шатлык, җан тынычлыгы, чын бәхет турында белсәләр, шушы җан ләззәтләрен бездән тартып алыр өчен кулларына кылыч тотып безнең белән сугышырлар иде».

Мөхтәрәм дин кардәшләрем. Без Аллаһыга якынайсак, Аллаһы безгә якынаер. Без Аллаһыны яратсак, Аллаһы да безне яратыр. Шушы вәгазьләр белән вәгазьләнергә һәммәбезгә насыйп булса иде. Аллаһы Раббыбыз акылларыбызга камиллек бирсен, хәерле гомерләр, хәерле сәламәтлекләр насыйп итсен. Шушында матур итеп җыелып утырган шикелле җәннәт бакчаларында да очрашырга насыйп итсә иде. Әәмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Йосыпов,*
*Арча районы Шушмабаш авылы имамы*

*10 июнь вәгазе,*
*зөлкагъдә аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Калебне дәвалау

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әлхәмдү лилләәһи раббил гааләмиин.

Галәмнәрнең бердәнбер Раббысы булган, Аннан башка илаһ булмаган Затка, барлык мәхлүкъларның Яратучысына, җирләрнең һәм күкләрнең Хуҗасына хәмде-сәналәребез булсын.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә Коръәни Кәримдә калебнең берничә халәте барлыгы хакында хәбәр итә: итагатьле калеб, курка торган калеб, гафләттәге калеб, мөһер сугылган калеб, Аллаһыны зикер кылудан ерак булган калеб, дөнья тормышын ярата торган калеб, үзенең хуҗасына начарлык кылырга әмер бирә торган һәм башка төрле калебләр бар. Коръәни Кәримдә:

ثُمَّ قَسَتْ قُلُوبُكُم مِّن بَعْدِ ذَٰلِكَ فَهِيَ كَالْحِجَارَةِ أَوْ أَشَدُّ قَسْوَةً

**«... күңелләрегез таш кебек катты яки тагы да катырак булды»,**
– дип әйтелгән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:74

Тышкы яктан без барыбыз да бертөрле күренергә мөмкинбез, әмма безнең калебләребез төрле. Болар хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلَٰكِن قَسَتْ قُلُوبُهُمْ وَزَيَّنَ لَهُمُ الشَّيْطَانُ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿٤٣﴾

**«...Ләкин бәгырьләре катты һәм алар кылган [начар] нәрсәне шәйтан аларга бизәде».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:43

Галимнәр бу дөньяда иң каты була алган әйберне атаган – ул иман китермәгән кешенең йөрәге. Кешенең калебе катыланса, аннан мәрхәмәт китә һәм кеше каты бәгырьлегә әйләнә. Шуңа да кеше үзенең калебенә игътибарлы булырга тиеш. Ә бер Аллаһыны таныган, Раббысын яраткан, яшәвенең нигезен бер илаһлыкка корган калеб – ул керсез, пакь булып санала.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Дөреслектә, кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул тәкъва булса, кешенең бөтен тәне тәкъва булыр. Әгәр ул бозылса, бөтен тән бозылыр. Һәм бу – йодрыктан да кечкенә булган йөрәк»[1].

Бер уйлап карасак, барлык гамәлләребез дә күңелдә башкарыла: күңел белән яратабыз, якын итәбез, мәрхәмәтлелек кылабыз яки башка гамәлләр эшлибез. Әгәр шул йөрәгебез бозылса, башка эш-гамәлләребез дә бозылачак. Әбү Һөрайра тапшырып, имам Мөслим риваять иткән хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ике-өч тапкыр күкрәгенә күрсәтеп: «Тәкъвалык монда», – дип әйткән. Бу кешенең барлык гамәлләре дә күңеленнән башлана дигән сүз.

Шунысын белеп торыйк: бу дөньяда була алган иң авыр җәза – ул калебнең катылыгы. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кеше дучар була алган иң зур җәза – ул калебнең катылануы. Бу кеше өчен иң зур җәза булып тора да инде», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Иң начар калебләр шулдыр: алардан Аллаһы Тәгалә мәрхәмәтлелекне алган һәм бу калебләр иң катылар». Расүлебез соралгач, бер хәдисендә: «Дөреслектә, тимер ту-

1 Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

тыккан кебек, калебләр дә тутыга», – дип әйткән. Аннан: «Йә, Аллаһының Расүле, ә аны нәрсә чистарта?» – дип сораганнар. Ул: «Үлемне еш искә алу һәм Коръән уку», – дип җавап биргән. Тагын бер хәдистә: «Җеназа намазында еш катнашу», – дип әйткән. Хәтта диннән ерак булган кешеләр дә, җеназаны күреп, үзгәрәләр, дөнья тормышы турында уйланалар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ләззәтләрне җимерә торган үлемне еш искә алыгыз»[1], – дигән. Шуңа күрә һәрбер мөселман кешесенә, калебен чистартыр өчен, айга бер тапкыр булса да зиратка бару мөстәхәб гамәл булып санала. Анда күмелгән төрле яшьтәге кешеләргә карап гыйбрәт алырга тиешбез, чөнки үлем кешенең яшен сорап тормый. Болар хакында уйлану, каберләрне зиярат кылу – иң зур вәгазьче.

Кызганычка, Коръән укыганда, калебләребез каты булганга күрә, без еламыйбыз. Аллаһы Тәгалә итагатьле хәлдәге калебнең халәте турында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ثُمَّ تَلِينُ جُلُودُهُمْ وَقُلُوبُهُمْ إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ ۚ

**«Шуннан соң [сөенеч һәм рәхмәт аятьләрен ишетүгә исә] тиреләре һәм күңелләре Аллаһының зикеренә йомшара».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:23

Калебләребез чистарган очракта без Коръән укылышын да, нәсыйхәтләрне дә бөтенләй башка төрле кабул итәбез, Аллаһыны искә төшерсәк, күзләребезгә яшь килә, Аның сүзләре, Коръәндәге аятьләр хакында уйлана башлыйбыз. Калебнең дәваланганын күрсәтә торган билгеләрнең берсе – ул күз яшьләре. Бер тәкъва иясеннән болар хакында соралгач, бердәнбер дәлил – ул Коръән укыганда, нәрсәне дә булса искә төшергәндә калеб чисталыгыннан, йомшаклыгыннан килгән күз яшьләре, дип әйткән. Ә гөнаһлар һәм гафиллек безне Аллаһыдан ерагайта. Пәйгамбәребез, гөнаһ кылган саен йөрәгебездә тап хасил була һәм гөнаһ кылуда даимчы-

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

лык күрсәтсәк, ул таплар арта һәм калебне тулысынча каплап ала, дигән.

Аллаһыны тыңлый, Аның каршындагы вазифаларын үти башлагач кешенең калебе чистара. Бу хакта Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

هُوَ الَّذِي أَنزَلَ السَّكِينَةَ فِي قُلُوبِ الْمُؤْمِنِينَ

**«...иман китерүчеләрнең күңелләренә тынычлык иңдергән Зат».**

«Әл-Фәтх / Җиңү», 48:4

Кешенең калебе катылануының тагын бер сәбәбе – дини вазифаларны үтәмәве – бу калебләрне гафиллеккә китерә. Имам Әт-Тирмизи китергән хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Хакыйкатьтә, Аллаһыдан иң ерак булучы кешеләр – ул калебләре каты булучылар». Аннан сәбәбен сораганнар. Пәйгамбәребез: «Алар харам ризыкны күп куллана һәм хәләлдә исраф кыла», – дип әйткән.

Расүлебез болай дип әйткән: «Аллаһы тыйганнан курык – иң хәерле гыйбадәт кылучы булырсың. Аллаһы сиңа биргәнгә риза бул – иң бай кеше булырсың. Азрак көл, хакыйкатьтә, күп көлү калебне үтерә».

Калебнең катылануына китергән өч сәбәп бар. Алар: харам куллану, Аллаһы биргәнгә канәгатьсезлек күрсәтү һәм күп көлү. Берәү дә Расүлебезнең кычкырып көлгәнен ишетмәгән: ул елмая торган булган.

Иң яманы – кешенең калебе катыланганын үзе сизмәве. Мәсәлән, Коръәннең берничә битен генә уку күп вакытны алмый, әмма без моңа вакыт тапмыйбыз. Шул ук вакытта без сәгатебезне бушка үткәрә, бер дә кирәкмәс эшләр белән мәшгуль була алабыз. Бу калебнең каты, гафил булуын белдерә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الَّذِينَ آمَنُوا وَتَطْمَئِنُّ قُلُوبُهُم بِذِكْرِ اللَّهِ ۗ أَلَا بِذِكْرِ اللَّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ ﴿٢٨﴾

**«Алар – иман китергән һәм күңелләре Аллаһыны зикер итү белән [бөтен буталчыклардан, шик-шөбһәләрдән котылып] тыныч-**

**ланган кешеләр. Күңелләр Аллаһыны зикер итү белән тынычланмыймы?»**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:28

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять иткән: кемдер Пәйгамбәребезгә йөрәгенең каты булуына зарланган. Расүлебез: «Ярлыларны ашат һәм ятимнәрнең башыннан сыйпа», – дип әйткән. Бу кешене йомшарта торган гамәл. Бу гамәл кешенең калебен шөкер итүгә, мәрхәмәтлеккә китерә, чөнки кеше кемнедер ашата, изгелек кыла ала икән – бу зур бәхет.

Галимнәрнең тагын бер киңәше – нәсыйхәтләр бирелә торган мәҗлесләрдә еш булу. Нәкъ менә шундый мәҗлесләрдә ихласлылык турында сөйләнә, булган кимчелекләребез искә алына.

Аллаһыны искә алу, харамнардан тыелу, ятимнәрнең башын сыйпау, кешеләрне ашату, галимнәр белән аралашу, җеназа намазларында катнашу, зиратларда булу – калебләрне төзекләндерә торган чаралар. Без болар хакында һәрвакытта да истә тотарга, һәрдаим калебләребезгә карата игътибарлы булырга тиешбез.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*17 июнь вәгазе,*

*зөлкагъдә аенең 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Тәкъдиргә иман китерү

Бөтен галәмне юктан бар итеп тәрбия кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңелләребез түреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифләребез ирешсә иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, тынычлык, авыру-сырхауларга хәерле шифалар, имансызлыкта, тәүфыйксызлыкта йөргән бәндәләргә юлны табарга ярдәм итсә иде, аларны иманга китереп, тәүфыйк-һидаять, истикамәтләр насыйп әйләсә иде.

Язмышка ышану иманның бер терәге, таләбе булып тора. Билгеле булганча, иманның алты нигезе бар: Аллаһыга һәм аның фәрештәләренә, Изге Китапка, пәйгамбәрләргә, Кыямәт көненә, үлгәннән соң терелүгә, тәкъдиргә ышану. Адәм баласы шушы нигезләрнең берсен дә инкяр итмичә, һәрберсенә иман китерергә, ягъни ышанырга тиеш. Гали радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләр әйткәнен риваять иткән: «Кеше дүрт әйбергә иман китермичә, мөэмин булмас. Ул: Аллаһыдан башка илаһ юк икәненә, минем хакыйкать белән килгән Пәйгамбәр икәнлегемә, үлемнән соң терелү барлыгына һәм яхшылык та, яманлык та Аллаһыдан булуына ышану»[1].

Аллаһы Тәгалә тәкъдир хакында әлеге аятьләрдә болай дип әйтә:

إِنَّا كُلَّ شَيْءٍ خَلَقْنَاهُ بِقَدَرٍ ﴿٤٩﴾

---

1 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

**«Һичшиксез, Без аны [Ләүхүл-Мәфхүздә язылган] бер тәкъдир белән яраттык»;**

«Әл-Камәр / Ай», 54:49

مَا أَصَابَ مِن مُّصِيبَةٍ فِي الْأَرْضِ وَلَا فِي أَنفُسِكُمْ إِلَّا فِي كِتَابٍ مِّن قَبْلِ أَن نَّبْرَأَهَا ۚ إِنَّ ذَٰلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرٌ ﴿٢٢﴾

**«Җирдә [кытлык, кыйммәтчелек кебек афәтләр] дә, үзегездә [авыру һәм фәкыйрьлек кебек] булган һәр бәла, Без аны барлыкка китергәнче үк, [Ләүхүл-Мәхфүз кебек] китапта [теркәлеп] язып куелган. Һичшиксез, бу Аллаһы өчен бик җиңел».**

«Әл-Хәдид / Тимер», 57:22

Кеше язмыш хакында бәхәсләшергә ярата. Әмма болай эшләргә ярамый. Бу хакта хәдисләрдә дә әйтелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тәкъдир турында бәхәсләшмәгез, ул Аллаһы Тәгаләнең бөек гыйлеме. Тәкъдир – ул Аллаһы Тәгаләнең сере, аны фәрештә дә, адәм дә, җен дә белми», – дигән. Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тәкъдир – ул тирән диңгез кебек, кем аңа керә, ул адаша», – дигән.

Язмыш белән элек-электән кызыксынганнар. Пәйгамбәребез заманында да сәхабәләрнең тәкъдир турында бәхәсләшкән чаклары булган. Берсендә моны ишетеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ачуы килгән һәм: «Сезгә кадәр булган кавемнәр тәкъдир турында бәхәсләшеп адаштылар», – дигән.

Язмыш, тәкъдир, болар шулкадәр нечкә, зур гыйлем, чыннан да, диңгез сыман. Раббыбыз кечкенә генә бер тамчысы хакында хәбәр биргән икән, калганы хакында кызыксынырга кушмаган. Безнең акыл аны аңламый. Ләкин Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне язган, әмма шул ук вакытта

адәм баласына ихтыяри көчне дә биргән. Ул да тәкъдиргә керә. Раббыбыз Коръәни Кәримне, хәдисләрне безгә рәхмәт йөзеннән, без дөрес юлны тапсын өчен биргән.

Тәкъдир турында бер хикәят укыдым. Бер галим Гомәр бине Әл-Хаттаб вакытында булган вакыйганы искә төшергән. Шам илләрендә ваба (чума) чире таралган булган. Бер сәхабә: «Әйдәгез, шул илгә керәбез. Аллаһының тәкъдире бу, нәрсә булса шул булыр», – дип әйткән. Тик Гомәр бине Әл-Хаттаб бер хәдисне искә төшергән: «Берәр җирдә ваба чире икәнен ишетсәгез, анда кермәгез. Анда булсагыз, аннан чыкмагыз». Әлеге сүзләр авыру таралмасын өчен бу хәдисне үтәүнең мөһимлеген күрсәтә. Шунда сәхабә: «Син әллә Аллаһының тәкъдиреннән качасыңмы?» – дигәч, Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әйе, Аллаһы тәкъдиреннән Аның тәкъдиренә качам», – дип җавап биргән. Кешенең ниндидер бер хәлдә калып дөрес юлны сайлавы, кирәкле юнәлешне табуы шулай ук тәкъдир. Бер тәкъдирдән икенчесенә бару – акыл белән эш итү дип атала.

Әмма шундый очраклар бар: кайбер кеше гөнаһны тәкъдиргә сылтый. Мәсәлән, кешенең дөрес яшәмәве язмышына язылмаган. Әмма, болай килеп чыгарга мөмкин булганы Аллаһыга мәгълүм. Тик Раббыбыз болай булуын теләми. Ул золымны, харам нәрсәләрне яратмый. Шуңа адәм баласына ихтыяри көч бирелә, нәрсә эшлисен ул үзе сайлый. Ул һидаять юлында иман китереп тә яши ала бит. Барысы да Аллаһының тәкъдире белән. Әйтик, ил җитәкчелеге бер-ике көнгә генә эшен ташласа, илдә башбаштаклык башлана. Аллаһының тәкъдире дә шулай, Аның кодрәте бу, тәкъдир язылмаса галәмнәрдә тәртипсезлек күзәтелер иде.

Кайбер кеше начар гамәлләр дә тәкъдирдә язылган бит дип әйтә. Аллаһы барысын да Ишетүче, Күрүче, Белүче. Ул һәркемгә җәннәткә керү мөмкинлеге бирә. Золым кылучыларны күреп, уйлана башлыйсың. Һәр кешенең дә тәүбәгә килеп, Аллаһы каршында гафу үтенү мөмкинлеге бар. Коръәни Кәримдә:

إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٧٠﴾

**«Тик [көферлектән] тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның [тәүбәләре сәбәпле сөртелгән] начарлыкларын Аллаһы күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак. Аллаһы Гафу итүче, Рәхимле»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:70

Аллаһы Тәгалә Ләүхүл-Мәхфүз китабы белән каләмне яратты. Хәдисләрдә: «Ул китапның буе җир һәм күк арасы, иңе мәгъриб белән мәшрикъ арасы», – диелә. Аллаһы каләмгә «Яз!» дип әмер иткәч, каләм: «Нәрсә языйм?»– дип сораган. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип язарга кушкан. Шуннан соң каләм яза башлаган. Аллаһы Тәгалә аңа: «Һәр җанлы, җансыз нәрсәләрнең тәкъдирен яз», – дип әйткән. Хәдисләрдә Пәйгамбәребезнең, Мигъраҗ кичәсендә каләмнең язган тавышын ишеттем, дигән хәбәрләре бар. Ул бүген дә яза диелә. Ягъни Ләүхүл-Мәхфүз китабы Кыямәт көненә чаклы көн саен язылып барачак.

Ләүхүл-Мәхфүз хакында әйткәндә кешегә билгеләнгән ризык, гомер озынлыгы турында да искә алырга кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гомеренең озын, ризыгының киң булуын теләүче кеше туганлык җепләрен сакласын», – дигән. Шулай ук әти-әниләргә итагать итәргә тиешбез, аларның хәер-фатихасы Аллаһының да ризалыгы булып санала. Бу да гомеребезнең озынлыгына тәэсир итә. Ләүхүл-Мәхфүз китабында кешенең гомер озынлыгы язылa. Фәрештәләр бала карында чакта ук дүрт ай да ун көн булгач, килеп дүрт кәлимәне язалар: баланың ризыгы, гомере, кыласы гамәлләре, бәхетле яки бәхетсез булуы. Менә шул фәрештәләр язган гомерне кеше игелекле гамәлләре белән озынайта ала.

Тик кеше язмышлар китабында язган вакыттан да озаграк яши алмас, диелә.

Еш кына хәзрәтләрдән клиник үлем хакында да сорыйлар. Кеше йокларга яткан урыннан да уянмаска мөмкин. Җәмәгать, әгәр кешенең үлеме җиткән көн, ул яткан йокысыннан кабат уянмый, Ахирәткә күчә. Шуңа да без көн саен йоклаганда үләбез дип әйтәбез. Бу хакта Коръән аятендә дә әйтелә:

اللَّهُ يَتَوَفَّى الْأَنفُسَ حِينَ مَوْتِهَا وَالَّتِي لَمْ تَمُتْ فِي مَنَامِهَا ۖ فَيُمْسِكُ الَّتِي قَضَىٰ عَلَيْهَا الْمَوْتَ وَيُرْسِلُ الْأُخْرَىٰ إِلَىٰ أَجَلٍ مُّسَمًّى ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٤٢﴾

**«Аллаһы [әҗәле җиткән] җаннарны үлемнәре вакытында [тулысынча] ала, үлмәгәннәрне [үлемнәре җитмәгәннәрне] исә йокыларында [ала, үлем җиткәч, тулысынча; йокыда чакта исә өлешчә ул рухларның бәдәннәре белән бәйләнешен өзә]. Ул үлем карары биргәннәрне тота [һәм бәдәннәренә кире җибәрми]. Бүтәннәрен исә [үлемнәре] билгеләнгән вакытка кадәр [бәдәннәренә] җибәрә. [Аллаһы Тәгаләнең тиңсез эшләрендәге өстен хикмәтләрне] Фикерләгән кешеләр өчен монда билгеләр бар».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:42

Кеше йоклаганда сулый бит, дияләр. Җавабы бер: бу вакытта җан белән баш мие арасында элемтә кала. Бу халәттә кешене мәет дип әйтеп булмый. Әгәр шул элемтә өзелсә сулыш та киселә, калеб тә тибүдән туктый. Клиник үлемгә килгәндә: ул вакытта кешенең җаны китми, ягъни Аллаһы хозурына юнәлми. Әйе, бакыйлыкка барып кайттым дип сөйләүчеләр бар. Аллаһы моны бер гыйбрәт, кисәтү өчен бирә. Кайбер кеше шундый хәлләрдән соң Ахирәт турында уйлана башлый, намазга баса, мәчеткә

йөри, динне өйрәнә, ягъни һидаять юлына килә.

Раббыбыз Үзенә итагатьле булып, кушканнарын үтәп яшәүне һәм гамәл-гыйбадәттә булып гомер итүләребезне насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*24 нче июнь вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Зөлхиҗҗә – гыйбадәтләргә бай ай

Барча мактаулар һәм дә сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак Расүле, безгә туры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде!

Аллаһы Тәгалә мөселманнарга елның һәр көнендә күп әҗер-саваплар алу мөмкинлеген бирде. Ләкин Аллаһы Тәгаләнең иң тугры коллары өчен махсус шәфкате, рәхмәте булган көннәр бар. Аллаһы өчен иң яраткан һәм иң кадерле көннәр – зөлхиҗҗә аеның беренче ун көннәре.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Аллаһы каршында бу ун көннән бөегрәк көннәр юк, һәм бу көннәрдә кылган изге гамәлләр Аллаһы Тәгалә өчен иң яраткан гамәлләр булып тора»[1], – дигән сүзләрен тапшырган.

Бу көннәр шулкадәр бөек ки, Аллаһы алар белән Коръәни Кәримдә ант итә:

وَالْفَجْرِ ﴿١﴾ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾ وَالشَّفْعِ وَالْوَتْرِ ﴿٣﴾ وَاللَّيْلِ إِذَا يَسْرِ ﴿٤﴾
هَلْ فِي ذَٰلِكَ قَسَمٌ لِّذِي حِجْرٍ ﴿٥﴾

**«[Иртән агарып килгән] Таң белән ант итәмен! [зөлхиҗҗәнең башындагы] Ун төн белән дә [ант итәмен]! Җөп һәм так белән**

---

1 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

**дә [ант итәмен]! Һәм үтеп барган төн белән [ант итәмен]! Акыл иясе булганнар өчен бу антлар җитәрлек түгелме?»**

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:1-5

Ибне Кәсир Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләреннән болай диде: «Ун көн – Корбан бәйрәме көннәре. Так санга туры килгән көннәр – Гарәфәттә басып тору көне, җөп санга туры килгән көннәр – корбан чалу көне».

Хафиз бине Хәҗәр бу ун көннең бөек булуның сәбәбен «Фәтх Әл-Бари» китабында болай дип аңлата: «Зөлхиҗҗәнең беренче ун көненең бөек булу сәбәбе – бу көннәрдә намаз, ураза, корбан, хаҗ кебек иң мөһим гыйбадәт төрләре берләшкән, һәм болар барысы башка берниндә көннәрдә бергә җыелмаган».

Зөлхиҗҗә – миллионлаган кеше хаҗ гыйбадәтен үтәр өчен, Исламның иң изге урыннарына җыела торган вакыт. Әлбәттә, Кәгъбә янында булу, Гарәфәт тавында басып тору яки Мина үзәнлеге буйлап йөрү бәхете һәркемгә бирелмәгән. Ләкин, чиксез кодрәт иясе Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең рәхмәте шулкадәр бөек һәм чиксез ки, хәтта бу мөбарәк урыннардан ерак булсак та, без үзебезнең догаларыбыз, гыйбадәт кылуыбыз һәм Раббыбызны яратуыбыз белән хаҗ кылучылар санына кушыла алабыз.

Хаҗда булмаган мөселманнарга бу кыйммәтле вакыттан файдалануның берничә ысулы бар.

Хаҗиларга кушылмаган мөселманнарга хаҗ рухын тояр өчен, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне барлык мөселманнарны берләштергән тәкъвалык атмосферасын тарату өчен шушы ун көн эчендә күбрәк изгелекләр кылырга өндәде. Чөнки бу ун көн эчендә кылынган һәрбер изгелекнең әҗере күпкә артык булачак.

Зөлхиҗҗә аеның тугызынчы көне бик мөһим көн – ул Гарәфә көне дип атала. Бу көнне Мәккәгә хаҗ кылырга килгән хаҗилар Гарәфәт үзәнлегенә җыела, һәм көне буе догада булып, Аллаһы Тәгаләгә

мөрәҗәгать итә, чөнки бу көнне дога һәм аеруча гөнаһларны кичерү догалары кабул ителә. Гарәфә көненең өстенлеге турында хәдисләрдә дә килә: «Аллаһы Тәгалә Үзенең колларын, Гарәфә көненә караганда, уттан азат иткән күбрәк көн юк ...»[1]. «Иң яхшы дога – Гарәфә көнендә кылган дога ...»[2].

Бу көннәр чиксез кодрәт иясе Аллаһы Тәгаләнең шәфкате һәм колларына бүләге, бүтән көннәрдә бирелмәгән әҗерләр алу мөмкинлеге. Бу көннәрдә гыйбадәтне арттыру өчен бөтен көчне куярга кирәк. Тәкъва кешеләр өч дистәне кадерләделәр: Рамазан аеның соңгы ун көнен, зөлхиҗҗәнең беренче ун көнен һәм мөхәррам аеның беренче ун көнен.

Бу айда Аллаһы Тәгалә исламның биш баганасының берсен – хаҗны мөмкинлеге булган һәркемгә кылырга әмер кылды. Хаҗ – бу мөбарәк көннәрдә үти алырлык иң күркәм гамәл булып тора. Чиксез кодрәт иясе Аның йортына барырга һәм гомрә кылырга рөхсәт биргән кешегә әҗере җәннәт булачак. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гомрә соңгы кылган гомрәдән соң җыелган гөнаһларны бетерә, һәм камил рәвештә кылган хаҗ өчен җәннәт кенә булачак»[3], – дип әйткән.

Бу көннәрдә ураза тоту шулай ук күркәм гамәлләрнең берсе булып санала. Гарәфә көнендә ураза тоту Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күп хәдисләре белән раслана, ул да бу көнне ураза тотты. Әбү Катәдә радыяллаһу ганһе сүзләреннән риваять ителә: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Гарәфә көнендә ураза тоту турында сорадылар, һәм ул болай дип әйтте: «Бу көнне ураза тоту үткән һәм киләчәк елларның гөнаһлары кичерелүгә сәбәп була»[4].

---

1 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

4 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, 1162.

Моннан тыш, зөлхиҗҗә аеның беренче тугыз көнендә, Корбан бәйрәменә кадәр, ураза тоту сөннәт булып тора. «Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм зөлхиҗҗә аеның тугыз көнен, Гашурә көнендә һәм ай саен өч көн ураза тотты»[1].

Зөлхиҗҗә аеның унынчы көне – исламдагы иң хөрмәтле ике бәйрәмнең берсе – Корбан бәйрәме.

Бу көннең өстенлеге турында хәдистә болай дип әйтелә: «Аллаһы алдында иң зур көн – Корбан гаете көне, аннары аннан соң килүче көн»[2].

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Зөлхиҗҗәнең унынчы көнендә (Корбан гаете көне) адәм балаларына корбан чалудан башка Аллаһы Тәгалә өчен иң яраткан һәм кадерле эш юк. Корбан итеп чалынган хайван Кыямәт көнендә үзенең мөгезләре, йоннары һәм тояклары белән пәйда булачак. Корбан, каны җиргә төшкәнче, Аллаһыга барып җитә. Шуңа күрә, ачык һәм саф калеб белән корбан чалыгыз»[3].

Без садака бирүнең фазыйләтләре турында яхшы беләбез. Садака безнең күзебездә аз булып күренсә дә, бу изге гамәлне даими рәвештә үтәвебез мөһим.

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ﴿٧﴾

**«Кем дә кем [дөньяда] зәррә авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны [Ахирәттә] күрәчәк».**

«Әз-Зәлзәлә / Җир тетрәү», 99:7

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Кардәшеңә елмаюың – садака». Хаҗ көннәрендә, бигрәк тә Корбан бәйрәме көннәрендә, хәернең иң яхшы төре – корбан

1 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имамнар Әхмәд, Әбү Давыд, Әл-Хәким хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан, 1493.

чалу һәм мохтаҗларга ит тарату.

Тәкбир, тәһлил һәм тәхмид сүзләрен бу көннәрдә күбрәк әйтү шулай ук бик фазыйләтле гамәлләрдән булып тора. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Аллаһы Тәгалә өчен иң яраткан, сөйкемле гамәлләр – ул зөлхиҗҗә аеның ун көнендә башкарылган гамәлләр. Бу көннәрдә тәкбир («Аллаһү әкбәр»), тәһлил («Ләә иләәһә илләллааһ») һәм тәхмид («Әлхәмдүлилләәһ») сүзләрен әйтегез»[1], – дигән сүзләрен тапшырган.

Имам Әл-Бохари риваять итә, Ибне Гомәр һәм Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһүмәләр зөлхиҗҗәнең ун көнендә базарга чыгып «Аллаһү әкбәр» дип әйтә торган булганнар, һәм алар артыннан кешеләр дә кабатлаган. Бу көннәрдә Мина җирлегендә Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе намаздан соң, йокларга ятар алдыннан, чатырында, очрашу вакытында һәм җәяү йөргәндә тәкбирләр әйтә торган булган.

Әлеге риваятьтә телеңне яхшылык өчен генә кулланырга киңәш ителә: зикер, яхшылыкка өндәү, гөнаһлы әйберләрне тыю, кешеләр белән татулашу һәм кешеләр белән яхшы аралашу. Иң мөһиме, телне бөтен яман нәрсәләрдән сакларга кирәк: гайбәт, ялган, башкаларны сүгү һәм мыскыллаудан. Телне начарлыктан, яманлыктан һәр көнне сакларга тиешбез, ләкин бу мөбарәк көннәрдә җаваплылык тагын да арта. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук бу ун көн эчендә түбәндәге сүзләрне күп итеп укырга өндәде: «Сүбехәәнәллааһи вәл хәмдүлилләәһи вә ләә иләәһә илләллааһү вәллааһү әкбәр».

Кеше кылган гөнаһлардан чын күңелдән тәүбә итәргә, аларны ташлауны ниятләргә һәм һәрнәрсәдә дә Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәргә тиеш. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гөнаһтан тәүбә кылган кеше, аны бөтенләй кылмаган шикелле»[2], – дип әйткән.

1 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан, 4250.

Яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелек һәрвакыт мөселманның билгесе булырга тиеш, аеруча Аллаһының рәхмәте аңа иң якын булган көннәрдә, ягъни зөлхиҗҗә аеның беренче ун көннәрендә.

Шулай ук, кешеләргә аларның мәшәкатьләре белән ярдәм итү дә бик дәрәҗәле эш булып санала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем үзенең дин кардәшенә ярдәм күрсәтеп торса, Аллаһы аңа да ярдәм итүдән туктамас»[1], – дип әйткән.

Кешеләргә ярдәм итүнең мөһимлеге турында башка хәдисләрдә болай дип әйтелә: «Кем бу дөньяда бәхетсезлеккә дучар булган мөселманга ярдәм итсә, Аллаһы Ахирәттә аның бәхетсезлеген бетерә»[2].

Мөселман өчен үзенең дин кардәшләре алдында аларның ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә ярдәм итәргә тырышу тиешле гамәл булып тора. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дин кардәшеңнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен йөрү сезнең һәрберегез өчен минем мәчетемдә игътикәф кылудан яхшырак, ягъни анда ике ел гыйбадәттә булудан да яхшырак»[3], – дип әйткән. Ә игътикәф, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетендә гыйбадәт кылу өчен, әйтеп бетергесез зур әҗер-саваплар бирелә.

Гомумән алганда, бу мөбарәк көннәрдә изге гамәлләр кылырга киңәш ителә, мәсәлән, Коръән уку, Коръән өйрәнү, истигъфар (тәүбә итү), ата-аналарга яхшылык эшләү, туганлык җепләрен саклау, кешеләрне татулаштыру, яхшылыкта ярдәм итү һәм тыелган нәрсәләрдән саклану, телне һәм җенес әгъзаларын пычраклыктан саклау, күршеләргә карата игелекле мөнәсәбәт, гаилә турында кайгырту, дин кардәшләргә булышу, еш кына салават уку, ятимнәр турында кайгырту, барлык мөселманнар өчен дога кылу.

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Әл-Хәким хәдисләр җыентыгыннан.

Раббыбыз зөлхиҗҗә аеның мөбарәк ун көнендә изге гамәлләребезне кабул кылып, аларны мизанда авыр кылса иде, гөнаһларыбызны кичереп, җәннәт әһелләреннән булуны насыйп әйләсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәт хәзрәт Фәйзуллин,*

*«Иман нуры» мәчетенең икенче имамы*

*1 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аенең 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Пәйгамбәребезнең соңгы хаҗы

Барча мактауларыбыз шушы галәмнәрне юктан бар кылган, һәм шушы галәмнәрне тәрбия кылып торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез булса иде. Бәндәләрнең иң хөрмәтлесе шушы галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифәләребез барып ирешсә иде. Аллаһы Тәгалә тел ачкычлары биреп, хәерле вәгазьләр сөйләргә, тыңлаган кешеләргә дә, сөйләгән кешеләргә дә шушы вәгазьләр белән вәгазьләнергә насыйп итсә иде. Ике җомга арасында дөньядан үткән мөселман кардәшләребезгә укыган Коръәннәребезнең әҗер-саваплары барып ирешсә иде. Туры юлны таба алмый йөргән кешеләргә Аллаһы Раббыбыз туры юлны табарга ярдәм итсә иде. Авырып, Аллаһыдан шифа сораган кешеләрнең догалары кабул булып, Аллаһы Тәгалә аларга хәерле шифалар насыйп әйләсә иде.

Кадерле җәмәгать! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ислам дине биш баганага нигезләнә: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга лаеклы Зат юк һәм Мөхәммәд Аның Расүле дип шаһитлык китерү, намаз уку, малдан зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту һәм мөмкинлеге булган кешегә Кәгъбәтулланы зиярат итеп, хаҗ кылу», – дигән. Бу нигезләр Ислам диненең генә түгел, ә һәр мөселманның терәге булып тора. Һәр мөселман бу терәкләргә ныклап ябышырга, аларны өйрәнергә һәм гамәлгә ашырырга тырышырга тиеш! Бу гыйбадәтләрнең кайберләрен без көн саен, кайберләрен елга, йә гомеребезгә бер тапкыр кылабыз. Фикһ китапларында без бу гыйбадәтләрне тән һәм мал гыйбадәтләренә дә бүлеп карарга күнеккән. Мәсәлән, намаз уку, ураза

тоту тәнебез белән кылынса, зәкят чыгару – мал гыйбадәте булып тора. Малыбыз белән дә, тәнебез белән дә кылына торган гыйбадәт – ул хаҗ.

Кадерле җәмәгать, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ничә тапкыр хаҗ кылган? Мәсәлән, намазны көн саен укыган, уразаны Рамазан саен тоткан, дип әйтеп була. Ә хаҗга килгәндә, ул ничек булган икән? Пәйгамбәребез Мөхәммәд бер тапкыр хаҗ кылган, һәм безгә дә хаҗ кылу рәвешен өйрәтеп калдырган. Чыннан да, хаҗ гыйбадәте нинди генә олуг булмасын, кеше үз гомерендә бер тапкыр хаҗ кылса, өстеннән фарызны төшергән була. Әйткәнебезчә, фарыз булса да, Пәйгамбәребез хәдисләрендә хаҗ турында әйткәндә: «Булдыра алганнар өчен» дип әйтә иде. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ أَوَّلَ بَيْتٍ وُضِعَ لِلنَّاسِ لَلَّذِي بِبَكَّةَ مُبَارَكًا وَهُدًى لِّلْعَالَمِينَ ﴿٩٦﴾ فِيهِ آيَاتٌ بَيِّنَاتٌ مَّقَامُ إِبْرَاهِيمَ ۖ وَمَن دَخَلَهُ كَانَ آمِنًا ۗ وَلِلَّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلًا ۚ وَمَن كَفَرَ فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ عَنِ الْعَالَمِينَ ﴿٩٧﴾

**«Һичшиксез, кешеләр [гыйбадәт кылсын] өчен корылган тәүге йорт – мөбарәк һәм [кыйблалары булу белән] галәмнәр өчен һидаять булган Мәккәдә [Кәгъбәдә]. Анда [беркемдә дә буталчык тудырмый торган] ап-ачык аятьләр [вә галәмәтләр] һәм Ибраһимның мәкамы бар. Кем дә кем анда керсә, [курыкканнарыннан] имин булыр. Юл үтеп аңа [җитәргә] көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен [Әл-Харам мәчете булган] Бәйткә хаҗ кылырга тиеш. Кем дә кем [хаҗның фарызлыгын инкяр итеп] кяфер булса, һичшиксез, Аллаһы – [һичнинди гыйбадәткә һәм һичкемгә ихтыяҗы булмаган] бөтен галәмнәрдән бай [Зат]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:96-97

«Гыйбадәте Исламия» китабында Әхмәдһади Максуди хәзрәтләре болай дип яза: «Ислам динендә балигъ һәм акылы булган мөэмин кешегә

фарыз булган олуг гыйбадәтләрнең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып, хаҗ гамәлен кылу.

Сәламәт булып, Мәккәи Мөкәррәмәгә барып кайтырлык мөмкинлеге һәм үзе кайтканчы өендә калган гаиләсенә җитәрлек малы булган бай кешегә генә хаҗ гыйбадәте фарыз. Ире яки мәхрам кардәше[1] белән бергә барса, бай һәм сәламәт хатыннарга да хаҗ фарыз була. Авыру, сукыр һәм фәкыйрь кешеләргә хаҗ гамәле фарыз түгел. Әгәр мондый кешеләр Мәккәи Мөкәррәмәгә ниндидер сәбәп белән барсалар яки Мәккә якларында тору сәбәпле хаҗ кылырга көчләре җитәрлек булса, аларга да хаҗ гамәле фарыз була. Хаҗ сәфәренә чыкканда, барыр юлларының урлаучы-талаучылардан, төрле йогышлы авырулардан имин булуы шарт. Әгәр юллар тынычсыз булса, хаҗ кылу фарыз түгел. Юллар тынычланганчы, бай кешеләр дә хаҗ сәфәрен кичектереп тора ала. Фарыз булганнан соң, гозерсез килеш хаҗ гамәлен кичектерергә ярамый». Кыска гына рәвештә хаҗның шәригатьтәге урынын карап киттек. Инде вәгазебезнең икенче өлешенә – Пәйгамбәребезнең хаҗ кылу рәвешенә тукталып үтик. Һиҗрәттән соң 9 ел дәвамында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер генә тапкыр да хаҗ кылмаган иде. Унынчы елында ул үзенең хаҗ кылачагы турында хәбәр итте. Моны ишеткәч, хаҗ кылырга дип, Мәдинәдә бик күп халык җыелды. Нинди зур бәхет бит ул Пәйгамбәребез белән хаҗ кылу! Зөлкагъдә ае тәмамланырга 4 көн калып барганда, Пәйгамбәребез хаҗ сәфәренә әзерләнә башлады: чәчләрен тәртипкә китерде, хушбуйлар сибенде, юлга чыкканчы корбан чалачак хайваннарын билгеләп куйды. Төшке вакыттан соң Пәйгамбәребез дөясенә атланып юлга кузгалды. Дөясенә атлангач, ул тирә-ягына карап алды: хаҗга баручылар уңда да, сулда да, артта да, алда да иделәр. Икенде намазына кадәр Пәйгамбәребез Зөлхөләйфә җирлегенә барып җитте һәм анда иртәнгегә кадәр торды. Шунда ук ул гомрәне, хаҗны вакытында кылып

[1] Мәхрам кардәш – өйләнешергә тыелган якын кардәш.

булачагын да хәбәр итте! Госел коенып, икенде намазын укыганнан соң, ул хаҗ һәм гомрәнең башлануын хәбәр итте һәм тәлбия әйтә башлады: «Аллаһүммә, ләббәйкә гуматән вә хәҗҗән!», ягъни «Аллаһы, мин гомрә һәм хаҗ кылып, Синең каршыңда торам». Аннан соң ул: «Ләббәйкәл-лааһүммә ләббәйкә, ләббәйкә ләә шәриикә ләкә ләббәйкә, иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлкә, ләә шәриикә ләк», ягъни: «Йә, Раббым, мин Синең каршыңда, мин Синең каршыңда, Синең һичбер тиңдәшең юк. Дөреслектә, барча мактау һәм нигъмәт Сиңа хас һәм хуҗалык та Сиңа хас. Синең бернинди тиңдәшең юк», – дип әйтә башлады.

Зөлхөләйфә җирлегеннән ихрам халәтендә чыгып китеп, Мәккәгә барып җиткәч, ул кулын һәм йөзен кара ташка куйды. Кәгъбә тирәли тәваф кылганнан соң, Ибраһим галәйһиссәлам мәкамына килеп: «Йә Раббым! Ибраһимның урынын гыйбадәт кыла торган урын итеп кыл», – дигән аятьне укыды. Аннан чыгып, Сафа һәм Мәрвә исемле кечкенә генә тау янына килеп:

إِنَّ الصَّفَا وَالْمَرْوَةَ مِن شَعَائِرِ اللَّهِ

**«Һичшиксез, [Мәккәдәге] Сафа һәм Мәрвә [калкулыклары] – Аллаһының [Ислам] билгеләреннән»,** – дигән аятьне укый.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:158

Шулай ук ул: «Аллаһы Тәгалә аятьтә беренче искә алган таудан башлыйк», – дип тә әйтеп куя. Һәм шуннан соң Пәйгамбәребез 7 тапкыр шушы тау арасында сәгый кыла. Бу гамәлләрдән соң корбанлыклары булмаганнарга ихрамнан чыгарга һәм тәрвия көнендә кабаттан ихрам хәленә керергә куша. Кемнәрнең корбанлыклары булмый, алар ихрам халәтендә кала. Пәйгамбәребез бу урында пәнҗешәмбегә кадәр тора, аннан соң Мина үзәнлегенә юнәлә. Төнне шунда үткәреп, иртәнге намаздан соң Гарәфәт тавына таба юнәләләр.

Гарәфә көнендә Пәйгамбәребез үзенең соңгы хотбәсен укый. Аның эчтәлеген барыбыз да беләбез. Шулай да, бер-ике өлешен карап үтик: «... Аллаһы Тәгалә туры юлга урнаштырган кешене беркем дә адаштыра алмас. Аллаһы Тәгалә адаштырган кешене беркем дә туры юлга китерә алмас. ... Әй кешеләр! Бу көннәрегез, бу аегыз һәм шәһәрегез (Мәккә) ничек мөкатдәс булса, сезнең җаннарыгыз, малларыгыз һәм намусларыгыз да шундый мөкатдәс һәм изгедер. ...Әй, кешеләр, кемдә кеше мал-мөлкәтеннән берәр әманәт булса, аны хуҗасына кайтарсын. ...Әй, кешеләр, шәйтан сезнең бу җирләрегездә яңадан тәэсир һәм хакимиятен кору өчен көчен мәңгегә югалтты. Ләкин сезгә харам кылган шушы олы гөнаһлардан тыш кечкенә саналган гөнаһларга үрелсәгез дә, аны мәмнүн итәрсез. Шуңа күрә динегезне саклап калдыру өчен болардан да тыелыгыз. ...Әй, кешеләр, хатын хакларын күзәтү һәм бу хосуста Аллаһыдан куркуыгызны үгетлимен. Сез хатыннарыгызны Аллаһының әманәте буларак алдыгыз, аларның намус һәм гыйффәтләрен Аллаһы исеме белән сүз биреп, үзегезгә хәләл иттегез. Сезнең хатыннарыгыз өстендә хакларыгыз, аларның да сезнең өстегездә хаклары бар. ...Әй, кешеләр, сүземне яхшы тыңлагыз һәм яхшы хәтерләгез. Мөселман мөселманның кардәшедер. Дин кардәшегездән булган хакларын хөрмәтләмәү берегезгә дә хәләл түгел. Үзе генә рөхсәт биреп, кичермәгән булса. Әй, кешеләр, сүземне яхшы тыңлагыз һәм яхшы хәтерләгез. Әй, кешеләр, сезгә шундый бер әманәт калдырамын ки, әгәр аңа бөтен көчегез белән тотынсагыз, һич адашмаячаксыз. Ул әманәт Аллаһы китабы Коръәни Кәрим һәм Аллаһы Расүленең сөннәтедер. Әй, кешеләр, сүземне яхшы тыңлагыз һәм яхшы хәтерләгез. Әй, кешеләр, Раббыгыз бер. Атагыз да бер. Барыгыз да Адәм балалары, Адәм туфрактан. Аллаһы янында иң кыйммәтлегез, Аңа иң күп хөрмәт күрсәткәнегездер. Шуңа күрә гарәпнең, гарәп булмаган бер кемсә өстендә бернинди өстенлеге юк. ...Әй кешеләр! Иртәгә сездән минем турында сорарлар, сез ни нәрсә дип әйтерсез? «Аллаһы илчеле-

ген башкардың, вазифаңны җиренә җиткердең, безгә васыять һәм үгеттә булдың», – дип шәһадәт итәрбез. Моңа, Пәйгамбәребез шәһадәт бармагын күккә күтәреп: «Аллаһым шаһит бул! Аллаһым шаһит бул! Аллаһым шаһит бул!» – дип боерды. Пәйгамбәребез хотбәсен тәмамлагач, Билал азан әйтте. Намаздан соң Пәйгамбәребез кояш баеганчы догада булды. Аннан соң Мөздәлифә үзәнлегенә юнәлде. Ахшам һәм ястү намазларын укыгач, иртәнгә кадәр шунда торды. Һәм иртән Минага юнәлде, һәр атканда тәкбир әйтеп, 7 тапкыр таш аттылар. Һәм шуннан соң корбан чалырга юнәлделәр. Корбан чалганнан соң, Пәйгамбәребез чәчен алдырды, һәм сәхабәләребез Пәйгамбәребезнең чәчен алу бәхетенә ирештеләр. Дөясенә атланып, Кәгъбәгә таба юнәлде. Анда ифәзәт тәвафы кылды һәм өйлә намазын укыды, шуннан соң аңа Зәм-зәм суын китерделәр. Моннан соң Пәйгамбәребез хаҗның калган гамәлләрен башкарып, кабаттан Мәдинә шәһәренә кайтып китте.

Кадерле җәмәгать, күреп торабыз, 1400 елдан артык вакыт үткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләр күпме юл үткәннәр. Күбесенең атланып йөрергә дөяләре дә булмаган. Бүгенге көндә, Аллаһыга шөкер, автобуслар, самолетлар бар. Эссе кояш астында тормас өчен палаткалар да, кояштан саклый торган җиһазлар да, кондиционерлар да ул вакытта булмаган. Әмма риваятьләрдә килгәнчә, Пәйгамбәребез белән бергә 114 меңгә якын кеше хаҗ кылган дип килә. Күпме кеше аның белән хаҗ кылу бәхетенә иреште, аның хаҗ кылу рәвешен өйрәнеп калды, хотбәсен тыңлады… Бер тапкыр кылабыз, тәнем зәгыйфь, малым әле аз дип гафиллектә яшәмик: хаҗ турында гыйлемнәребезне бүгеннән арттыра башлыйк. Берәр көнне хаҗ кылырга мөмкинлек чыккач, югалып калырга мөмкинбез. Кадерле җәмәгать, хаҗ – ул беренчедән, олуг гыйбадәт, икенчедән, ул мөмкинлек! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кабул булган хаҗның әҗере – җәннәт», – дип әйтте. Шулай ук хәдисләрдә Гарәфә көнне Раббыбызның бик күп мөслим-мөслимәләрне

ут газабыннан азат итүе турында әйтелә. Ул үзе дә Гарәфәдә өммәте өчен нинди зур дога кылды бит! Пәйгамбәребез беркайчан да үзе турында гына уйламады, ә, өммәтем, өммәтем диде. Бу хәдисләрдән хаҗның, чыннан да, зур мөмкинлек икәнен күреп була. Шуңа күрә, бер тапкыр гына кыласы да, бетте инде, дип уйларга ярамый. Аңа чын күңелдән әзерләнеп: «Башка бара алмаска мөмкинмен. Бу соңгы хаҗым булырга мөмкин, Раббым, кабул була торган хаҗлардан кыл», – дип догалар кылсак иде. Онытмыйк, кабул булган хаҗ безнең гөнаһларыбызның ярлыкануына сәбәп була, безгә җәннәт бүләк итә! Пәйгамбәребез: «Кем дә кем начар сүзләр сөйләшмичә, начар гамәлләр кылмыйча һәм Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә тулы буйсыну белән хаҗ кылса, ул әле генә туган сабый кебек гөнаһсыз булыр», – дип әйтә. Аллаһы Тәгалә һәр гыйбадәтләребезне бары тик Аның өчен генә, Аның ризалыгын алырга дип кылырга насыйп әйләсен, һәм безне шушы җомга намазларында җыйган кебек, югары җәннәтләрдә дә бергә җыйса иде. Әәмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәеншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

# Фәтвалар

# Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фәтвалары

*Фәтвалар чыгару Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора. Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә гаилә хокуклары, сәүдә-милек мөнәсәбәтләре, гыйбадәт кылу тәртипләре, хәләл, хәдис гыйлеменә кагылышлы, мөселманнар өчен мөһим һәм көнүзәк мәсьәләләр буенча бик күп дини карарлар чыгарылды. Фәтвалар өчен темалар Татарстан мөфтиятенең «Даруль ифта» мөселман call-үзәгенә килеп ирешкән, иң еш бирелә торган сораулар буенча һәм Татарстан мөселманнарының хәзерге вакытка актуаль булган проблемаларыннан чыгып формалаша. Сезнең игътибарыгызга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның берничә фәтвасын тәкъдим итәбез. Алга таба да бу сәхифә дәвам итәчәк.*

## Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы?

### Сорау: Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы?

Җавап: әлеге сорауга җавап биргәнче, төгәлрәк булу һәм аңлаешсызлыклардан котылу өчен, «көлү» төшенчәсе белән бәйле кайбер күренешләргә ачыклык кертергә кирәк.

Шартлы рәвештә, көлүне, намазга йогынты ясау күзлегеннән караганда, өч төргә бүләргә мөмкин:

1. Синең яныңда утырган күршең ишетә алырлык дәрәҗәдә кычкырып көлү.

2. Көлү тавышы янында утырган күршеңә ишетелми, көлгәнеңне бары үзең генә тоясың.

3. Көлүгә илтүче йөз, ирен, күз торышы үзгәрү, әмма, асылда, бу көлү түгел. Әлеге күренеш елмаю дип атала, бу очракта бернинди дә тавыш чыкмый.

Югарыдагы әйтелгән күренешләргә карата хөкемнәр:

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре намазда кычкырып көлү намазны да, тәһарәтне дә боза дигән бердәм фикердә тора. Намаз үтәлгән булып саналсын өчен, яңадан тәһарәт алырга һәм көлү сәбәпле бозылган намазны кабаттан укырга кирәк. Көлүнең икенче категориясе бары намазны гына боза, тәһарәт бозылмый. Намаз укыганда елмаю намазны да, тәһарәтне дә бозмый.

Дәлил (аргументация): беренче чиратта, оппонентлар файдасына дәлил сыйфатында кулланылырга мөмкин, әмма, хакыйкатьтә, хәнәфи мәзһәбе галимнәренең хаклылыгын раслаган хәдисне китерик:

وَقَالَ جَابِرُ بْنُ عَبْدِ اللَّهِ: «إِذَا ضَحِكَ فِي الصَّلاَةِ أَعَادَ الصَّلاَةَ وَلَمْ يُعِدِ الوُضُوءَ». (صحيح البخاري/ كتاب الوضوء/ باب من لا يرى الوضوء إلا من المخرجين ١/٤٦)

Җәбир бине Габдилләдән тапшырылган: «Кем дә булса намазда көлсә, намазын кабаттан укысын, әмма тәһарәтне кабат алуга ихтыяҗ юк» .

Хәдистә телгә алынган «көлү» («ضحك») сүзе гомуми мәгънәгә ия һәм ул нинди дә булса сыйфат белән бирелмәгән. Димәк, бу хәдистә янында утырган кеше ишетерлек дәрәҗәдә кычкырып көлү әйтелгән дип аңларга кирәкми. Хәнәфи мәзһәбе галимнәре дәлилләре җыелмасында әлеге факт биредә кеше бары үзенең көлгәнен генә ишетә алу турында әйтелә.

Ибне Хумам рахмәтуллаһи галәйһи «Фәтхүл Кадир» китабында болай дип әйткән:

حديث القهقهة روي مرسلا ومسندا. واعترف أهل الحديث بصحته مرسلا، ومدار المرسل على أبي العالية وإن رواه غيره كالحسن البصري وإبراهيم النخعي وغيرهما.

أَخْبَرَنَا أبو حنيفَة قَالَ حَدثنَا مَنْصُور بن زَاذَان عَن الْحسن الْبَصْرِيّ عَن النَّبِي صلى الله عَلَيْهِ وَسلم انه بَيْنَمَا هُوَ فِي الصَّلَاة اذا اقبل اعمى من قبل الْقبْلَة يُرِيد الصَّلَاة وَالْقَوْم فِي صَلَاة الْفجْر فَوَقع فِي زبية فاستضحك بعض الْقَوْم حَتَّى قهقه فَلَمَّا فرغ رَسُول الله صلى الله عَلَيْهِ وَسلم من الصَّلَاة قَالَ من كَانَ قهقه مِنْكُم فليعد الْوضُوء وَالصَّلَاة.

أَخْبَرَنَا ابو حنيفَة عَن حَمَّاد عَن ابراهيم النَّخعِيّ فِي الرجل قهقه فِي الصَّلَاة قَالَ يُعِيد الْوضُوء وَالصَّلَاة ويستغفر ربه فانه أشد الحَدِيث. (فتح القدير ١/٥١).

«Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне да бозуы хакында хәбәр иткән хәдисләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән берөзлексез иснәд (тапшыручылар чылбыры) белән дә, мөрсәл (табигыйн һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм арасында сәхабәне телгә алмыйча) чылбыры ярдәмендә дә килә. Хәдис фәне белән шөгыльләнүче галимнәр, табигыйн һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм арасында сәхабәне телгә алмыйча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән тапшырылган хәдис ышанычлы тапшыручыдан килсә, аны дөрес дип саныйлар. Әлеге темага мөрсәл хәдисне Әбел Галия, Хәсән Басри һәм Ибраһим Ән-Нахаи тапшыра».

Шулай ук Ибне Хумам рахмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән:

وأما روايته مسندا فعن عدة من الصحابة أبي موسى الأشعري وأبي هريرة وابن عمر وأنس وجابر وعمران بن الحصين. (فتح القدير ١/٥١).

«Бөрөзлексез иснәд (моснад) белән килгән хәдисләргә килгәндә, аларны берничә сәхабә тапшыра: Әбү Муса Әшгарый, Әбү Һөрайра, Ибне Гомәр, Әнәс, Җәбир һәм Гыймран бине Хөсәен радыяллаһу ганһүмнәр».

Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгының танылган «Үмдәтүл Кари» аңлатмасында болай дип әйтелә:

وَلنَا فِي هَذَا الْبَاب أحد عشر حَدِيثا عَن رَسُول الله صلى الله عَلَيْهِ وَسلم مِنْهَا أَرْبَعَة مُرْسلَة وَسَبْعَة مُسندَة (عمدة القاري ٣ج ٧١ص).

«Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне дә бозуы хакында дәлил сыйфатында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 11 хәдисе бар, аларның дүртесе мөрсәл (ул табигыйн һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм арасында сәхабәне телгә алмыйча тапшырыла), ә калган җидесе моснад булып тора (өзлексез чылбыр буенча тапшырылган хәдис)» .

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

أَخْبَرَنَا اسماعيل بن عَيَّاش قَالَ حَدثنِي عبد الْعَزِيز بن عبيد الله عَن نَافِع عَن ابْن عمر قَالَ: إِذا قهقه الرجل فِي صلَاته أعاد الْوضُوء وَالصَّلَاة. (الحجة على أهل المدينة ١/٢٠٤).

«Кайсыгыз да булса намазда кычкырып көлсә, тәһарәтен дә, намазын да яңартсын» .

Зәед бине Халид радыяллаһу ганһедән тапшырыла:

عَنِ ابْنِ سِيرِينَ , عَنْ مَعْبَدٍ الْجُهَنِيِّ , قَالَ: كَانَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يُصَلِّي الْغَدَاةَ فَجَاءَ رَجُلٌ أَعْمَى وَقَرِيبٌ مِنْ مُصَلَّى رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بِئْرٌ عَلَى رَأْسِهَا جُلَّةٌ , فَجَاءَ الْأَعْمَى يَمْشِي حَتَّى وَقَعَ فِيهَا , فَضَحِكَ بَعْضُ الْقَوْمِ وَهُمْ فِي الصَّلَاةِ , فَقَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بَعْدَمَا قَضَى الصَّلَاةَ: «مَنْ ضَحِكَ مِنْكُمْ فَلْيُعِدِ الْوُضُوءَ وَلْيُعِدِ الصَّلَاةَ» (سنن الدارقطني، ٦٢٣).

«Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән намаз укыган һәм шул вакытта бер сукыр кеше коега төшеп киткән. Бу күренештән берничә сәхабә көлгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазны төгәлләгәч, борылган һәм аларга болай дип әйткән: «Берәрегез көлгән булса, тәһарәтен яңартсын һәм намазын кабаттан укысын» .

Хәдистән аңлашылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларны ишеткән, димәк көлү тавышы ишетелгән. Һәм бу хәдисне бары шул мәгънәдә аңларга кирәк. Ә Җәбир радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдис аны бары тулыландыру гына булып тора.

Йомгак сыйфатында Имам Мөхәммәд бине Әл-Хәсән Әш-Шәйбани рахмәтуллаһи галәйһинең сүзләрен китерәсе киләә:

لَوْلَا مَا جَاءَ من الْآثَار كَانَ الْقيَاس على مَا قَالَ اهل الْمَدِينَة وَلَكِن لَا قِيَاس مَعَ اثر وَلَيْسَ يَنْبَغِي الا إن ينقاد للآثار. (الحجة على أهل المدينة ١/٢٠٤).

«Әгәр дә хәдисләр булмаса, кыяс (аналогия буенча фикер йөртү) нигезендә, барысы да мәлики мәзһәбе галимнәре әйткәнчә булыр иде (ягъни кеше намаз укыганда көлсә, тәһарәт бозылмас иде). Әмма кыяс мөмкин түгел, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән

килгән хәдисләр бар, һәм моңа охшаш барлык очракларда да (аерым алынган темага хәдис булганда), без бары хәдистә әйтелгәнне генә эшләргә тиешбез» .

*Ә Аллаһы яхшырак белүче.*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*ТР мөфтие*

# Балдан зәкят түләнәме?

## Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Балдан зәкят түләнәме?

Җавап: Вә галәйкүм әссәлам вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Имам Кудури рахмәтуллаһи галәйһи үзенең «Мохтасар Әл-Кудури» хезмәтендә болай дип яза:

و في العَسَلِ العُشْرُ إذا أُخِذَ مِنْ أَرْضِ العُشْرِ قَلَّ أَوْ كَثُرَ (مختصر القدوري/ باب زكاة الزروع و الثمار)

«Әгәр дә бал җыелган умарталыктан гошер түләнә торган җирдән алынган булса, бал күп яки аз булуга карамастан, аның уннан бер өлешен бирергә кирәк».

Югарыда әйтелгәннәрдән тагын шуны аңларга кирәк, уңыштан һәм җиләк-җимештән зәкят (гошер) түләр өчен, нисаб (зәкят чыгару өчен тиешле булган иң аз күләм) юк.

*Аллаһы иң яхшы белүче.*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

# Гади оекбашка мәсех кылу

## Сорау: Тәһарәт алганда гади оекбашка мәсех кылырга буламы? Мондый тәһарәт дөрес саналамы? Абруйлы мөселман галимнәре һәм дүрт мәзһәб имамнары моңа ничек карый?

Җавап: Абруйлы фикһ галимнәре һәм мөҗтәһидләр юка, су үткәргән, аякта өстәмә ныгытмаларсыз тормаган һәм аяк киемсез җитәрлек ара үтәргә мөмкин булмаган оекбашларны (носки) мәсех кылырга рөхсәт итми. Хәзерге мамыктан, йоннан, нейлоннан эшләнгән оекбашлар күннән ясалган оекка (читеккә) хас булган сыйфатларга ия түгел, шуңа күрә аларга мәсех кылырга ярамый. Мондый ысул белән тәһарәт алучының тәһарәте дә дөрес булмый. Бу карар Коръәни Кәрим аятьләре, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте һәм дүрт мәзһәб имамнары тарафыннан раслана. Шулай ук бу кешенең намазы да дөрес булмый.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا قُمْتُمْ إِلَى الصَّلاةِ فاغْسِلُوا وُجُوهَكُمْ وَأَيْدِيَكُمْ إِلَى الْمَرَافِقِ وَامْسَحُوا بِرُؤُوسِكُمْ وَأَرْجُلَكُمْ إِلَى الْكَعْبَينِ

**«Ий, иман китерүчеләр! Намазга басарга әзерләнгән чагыгызда [әгәр тәһарәтле түгелсез икән] йөзләрегезне һәм терсәкләрегезгә кадәр [аларны кертеп] кулларыгызны юыгыз, башларыгызны мәсех кылыгыз, аякларыгызны да тубыкларга кадәр [аларны кертеп юыгыз]».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:6

Бу аятьтән аякларны юу – тәһарәтле булуның мәҗбүри шартларының берсе булуы аңлашыла. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең күп кенә хәдисләрендә аякларны мәсех кылырга түгел, ә юарга

өндәгән. Мәсәлән, имам Әд-Дәракутный үзенең җыентыгында Әбү Рафидан һәм Әбү Давыд Рабгидан тапшырылган ике хәдис китерә:

عَنْ أَبِي رَافِعٍ قَالَ: رَأَيْتُ رَسُولَ اللهِ يَتَوَضَّأُ فَغَسَلَ رِجْلَيْهِ ثَلَاثًا

«Мин Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәһарәт алганын һәм өч тапкыр аякларын юганын күрдем».

عَنِ الرَّبِيعِ قَالَتْ: كَانَ رَسُولَ اللهِ يَأْتِينَا فَيَتَوَضَّأُ لِلصَّلَاةِ فَيَغْسِلُ رِجْلَيْهِ ثَلَاثاً ثَلَاثاً

«Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә килә иде һәм тәһарәт алганда аякларын өч тапкыр юа иде».

Имам Ибне Хәҗәр Әл-Гаскаләни үзенең «Фәтхүл Бари» китабында Гали һәм Ибне Габбас радыяллаһу гәнһүмәләр баштарак мәсех кылуны хуплауларын, әмма нәтиҗәдә әлеге фикердән баш тартуларын хәбәр итә.

Ышанычлы хәдисләрдә тәһарәт алганда аяк юу урынына күннән эшләнгән читеккә мәсех кылу мөмкин булуы хакында әйтелә. Мәсәлән, Ибне Әби Шәйбага Өбәйә бине Гамер аша китерелгән хәдистә (ул шулай ук имам Мәликнең «Мөвәтта» җыентыгында Урва радыяллаһу ганһе аша ирешкән хәдистә әйтелә:

عَنْ أُبَيْ بِنْ عَمَّارٍ أَنَّهُ قَالَ: يَا رَسُولَ اللهِ أَمْسَحُ عَلَي الْخُفَّيْنِ؟ قَالَ نَعَمْ

«Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән хуффка мәсех кылуга рөхсәт соравын һәм Расүлебезнең моны рөхсәт итүен әйтә».

عَنْ هِشَامٍ بِنْ عُرْوَةٌ أَنَّهُ رَأَي أَبَاهُ يَمْسَحُ عَلَي الْخُفَّيْنِ قَالَ: وَ كَانَ لَا يَزِيدُ إِذَا مَسَحَ عَلَي الْخُفَّيْنِ عَلَي اَنْ يَمْسَحَ ظُهُورُهُمَا وَلَا يَمْسَحَ بُطُونَهُمَا

«Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе Урва радыяллаһу ганһе хуффның өске өлешенә генә мәсех кылган, ә аскы

өлешенә тимәгән».

Читекләргә мәсех кылуга кагылышлы хәдисләр ышанычлы (сахих хәдисләр) булып санала һәм аларны тапшыручылар да күп. Имамыбыз Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи болай дип әйткән: «Читекләргә мәсех кылуны рөхсәт итмәгән идем, бу гамәл минем өчен көн яктылыгы кебек ачык булганчыга кадәр»[1].

Хафиз бине Хәҗәр рахмәтуллаһи галәйһи «Фәтхүл Бари» китабында китерә: «Күп хәдис белгечләре читеккә мәсех кылуның тәвәтүр (хәдисне тапшырулар санының күплеге) белән билгеләнүен белдерә». Кайберләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләреннән ишеткән хәдисләр саны сиксәнгә якын булуы хакында хәбәр итә. Унысы «гашарә-мүбашәра» (Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның җәннәткә эләгәчәкләрен үзләре исән вакытта әйткән сәхабәләр) аша килә.

Хафиз бине Габделбарр үзенең «Әт-Тәмхид» китабында хуффларга мәсех кылу хакындагы хәдисләрнең 40 сәхабә аша ирешүен хәбәр итә.

Хәсән Басри рахмәтуллаһи галәйһи әйткән булган: «Мин Бәдер сугышында катнашкан 70 сәхабәне күрдем. Алар читекләргә мәсех кылуның дөрес булуына ышаналар иде»[2].

Минем тарафтан югарыда китерелгән мөселман хокук белгечләренең фикерләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәһарәт вакытында читекләргә мәсех кылуы һәм башкаларга да моны рөхсәт итүе бернинди шик калдырмый. Тик шунысы мөһим – күннән эшләнгән читекләрдән кала башка төр оекбашларга мәсех кылу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтендә тәвәтүр тарафыннан билгеләнми.

1 Әл-Бәхер Әр-Раик.

2 «Тәлхисүл Хәбир» һәм «Бәдаигус Сәнаи».

Коръәни Кәрим – шәригатьнең төп һәм бәхәссез нигезе булып тора. Коръәни Кәримнең аятьләрен бер хәдис тә инкяр итә, мәгънәсен үзгәртә, чикли яисә киңәйтә алмый.

«Әхкамуль Коръән» тәфсирендә Имам Әбү Бәкер Әл-Җәссас рахмәтуллаһи галәйһи галимнәрнең моңа кагылышлы бердәм фикерен китерә. Әмма «мутәватир» дәрәҗәсенә җиткән хәдис булса, Коръәннең текстын аңлату мөмкин була. Шул сәбәпле Имам Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһи болай дип әйткән: «Бары тик тәватур яисә истифада дәрәҗәсенә җиткән Сөннәт белән генә Коръән әмерендә искәрмә була ала.[1] Мәсәлән, күн оекларны – читекләрне сөртү кебек (мәсах галәл хуффәйн).

Мәсьәләне тирән аңлау өчен, «хуфф» һәм «җәүрәб» төшенчәләренең дүрт сөнни мәзһәб буенча аңлатмаларын карап китәрбез, алар арасындагы аерманы билгеләрбез.

Хуфф – күннән эшләнгән, тубыкны һәм аякның шул өлешен каплый торган оек.

Хуффларны сөртү өчен берничә шарт булырга тиеш:

1. Хуфф эшләнгән күн чиста булырга тиеш. Хәнәфи һәм шәфигый галимнәре үләксәдән эшкәртелгәнгә кадәр эшләнгән хуффларны тыелган дисәләр, мәлики һәм хәнбәли галимнәре эшкәрткәннән соң да тыелган диләр, беренчеләре эшкәртү материалны чистарта, дип исәпләсәләр, икенчеләре – чистартмый, ди.

2. Хуффлар тубык сөягеннән алып, тубыкка кадәр араны капларга тиеш. Бу аяк өлешен капламаган хуффларны сөртү дөрес булмый.

3. Хуффлар ерак араларга йөрерлек дәрәҗәдә нык булырга тиеш. Дүрт мәзһәб имамнары да бу фикердә бердәм. Араның төгәл ераклыгы хакында төрле фикерләр бар.

Хәнәфи галимнәре фикеренчә, хуфф аякта бәйләүсез дә нык торырга тиеш. Шулай ук өч чакрымлык араны үтәрлек нык булырга тиеш. Шушы

[1] «Әхкәәмүл-Коръән лил-Җәссас».

шартларга туры килмәгән хуффларны сөртү дөрес булмый.

Мәлики факыйһларның фикеренчә, хуффларның ныклыгы көндәлек аяк киеменеке кебек булырга тиеш. Аякта тормаган хуффларны сөртү дөрес түгел.

Шәфигыйләрнең фикеренчә, хуффлар бер көн дәвамында өйдә һәм өч көн сәяхәттә йөрерлек нык булырга тиеш. Аларның күннән яисә киездән эшләнүе мөһим түгел.

Хәнбәли галимнәре фикеренчә, хуффлар күннән, яисә агачтан, яисә шуның кебек әйбердән ясалган булырга тиеш. Тик алар йөргәндә аяк киемен алмаштырырлык булырга тиеш. Алар шулай ук аяктан төшәргә тиеш түгел. Ләкин дин ияләре арасында рөхсәт ителгән ярыклар зурлыгы һәм хуфф ясалган материал мәсьәләсендә билгеле бер фикер каршылыклары бар.

Хәнәфи һәм мәлики галимнәре хуффлар тишексез булырга тиеш, дип саныйлар. Тишекләрнең зурлыгы турында да фикер каршылыклары бар. Хәнәфиләр фикеренчә, өч кечкенә аяк бармагы кадәрле тишек, мәликиләр исә тубыкның өчтән бер өлешеннән кечерәк тишеге булган хуффларны сөртүне рөхсәт итәләр. Шәфигый һәм хәнбәли дин әһелләре кечкенә тишек булса да, хуффларны сөртү тыелган диләр.

Мәлики факыйһлары фикеренчә, хуффларның күннән эшләнгән булуы катгый шартлы. Шуңа күрә мамыктан яисә нейлоннан ясалган оекларны сөртү тыелган. Искәрмә булып, тышы күннән тегелгән оеклар тора.

Әмма күп кенә мөселман хокук белгечләре фикеренчә, хуффларның күннән булуы шарт түгел, иң мөһиме – аякларга су үтмәскә тиеш.

Җәүрәб мәсьәләсен ачыклаганчы, гади оекларны сөртү практикасының таралуын аңлау өчен, тарихи экскурс ясау файдалы булыр, дип уйлыйм.

1913/1332 елда гарәп җирләрендә урнашкан берничә университет гади оекларны сөртү турында шәех Җәмаледдин Әл-Касыймига сорау биргәннәр. Бу уку йортлары студентлары кышкы салкында аякларны юуда билгеле бер кыенлыкларга дучар булалар. Шул сәбәпле күп студентлар намазны вакытында кылмыйча, кичектереп укыганнар яисә бөтенләй кылмаганнар. Моңа җавап итеп, Җәмаледдин шәех гади оекларны сөртүне рөхсәт итү очракларын ачыклаган фәнни хезмәт язган. Аның фәтвасы гади оекларны сөртүне тышкы яктан рөхсәт иткән берничә хәдискә нигезләнгән. Әлеге фәтва мондый гамәлнең киңәюенә сәбәпче булган. Алга таба да күп кенә тикшеренүчеләр шуның кебек карарлар чыгарганнар. Шулай итеп, гади оекларны сөртү тәҗрибәсе бер гасыр элек кенә диярлек кертелгән, һәм бу күп кенә мөселманнарның намазларын яраксыз иткән куркыныч яңалык булып тора.

Җәүрәбләр – ул мамык, нейлон, йон һәм башка шундый материалдан эшләнгән оеклар. Галимнәр җәүрәбкә мәсех кылуны ике шартның берсе булганда гына рөхсәт итәләр:

1. Җәүрәбләрнең тышкы ягы күн белән тегелгән булырга һәм шуның белән алар хуффларга охшаш булырга тиеш.

2. Тубыкның аскы өлешенә күн табан тегелгән булырга тиеш.

Имамнар Мөхәммәд Әш-Шәйбани, Әбү Йосыф һәм Әхмәд бине Хәнбәл рахимәһуллаһи ике мәҗбүри шарт үтәлгәндә оекбашларны (җәүрәбне) сөртү рөхсәт ителә дип саный:

1. Оекбаш тән күренмәслек калын булырга тиеш.

2. Җәүрәб киеп йөрерлек булырга һәм тыгызлыгына күрә басып торырга тиеш.

Әгәр оекбашлар югарыда санап үтелгән шартларга туры килсә, алар хуффка охшыйлар, шуңа күрә аларга мәсех кылу дөрес була. Күн оекларга – читекләргә мәсех кылу үз чиратында мүтәвәтир хәдисләр сәбәпле рөхсәт ителә. Күн булмаган оекка – җәүрәбләргә мәсех кылуны тышкы

мәгънә ягыннан рөхсәт иткән хәдисләрне тикшерик.

Калынлыгына, чыдамлыгына карамыйча җәүрәбләрне сөртергә рөхсәт итә торган кешеләр дүрт хәдискә (хәбәр әхәд) нигезләнә. Аларда Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җәүрәбләргә мәсех кылуы хакында әйтелә. Беренчедән, Коръәндә язылганнарны әхәд хәдисләргә карап, кире кагып булмый, ә мүтәвәтир хәдисләргә нигезләнеп, тәгаенләү рөхсәт ителә. Әйтик, җәүрәбкә мәсех кылу тәвәтүр дәрәҗәсендә түгел, шуңа галимнәр җәүрәбкә мәсех кылуны дөрес дип санамыйлар.

Икенчедән, мөселман хокукы һәм хәдис белгечләренең күбесе әлеге хәдисләрне зәгыйфь дип саныйлар.

Сөнни галимнәрнең әлеге хәдисләргә карата фикерләрен китергәнче, Габдрахман Мөбарәкфуриның «Төхвәтел Әхвәзи» китабыннан хәдисләрне китерәм:

1. Могыйра радыяллаһу ганһе хәдисе:

عَنْ مُغِيرَةَ قَالَ تَوَضَّأَ النَّبِيَ وَمَسَحَ عَلَي الْجَوْرَبَيْنِ وَالنَّعْلَيْنِ (رَوَاهُ التِّرمِذِي رقم: ٩٩)

«Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәһарәт алгач җәүрәбкә һәм сандалига мәсех кылды».

2. Әбү Муса радыяллаһу ганһе җиткергән хәдис:

عَنْ أَبِي مُوسَي أَنَّ رَسُولَ اللهِ تَوَضَّأَ وَمَسَحَ عَلَي الْجَوْرَبَيْنِ وَالنَّعْلَيْنِ (رَوَاهُ اِبْنُ مَاجَه رقم: ٥٦٠، وَالْبَيْهَقِي رقم: ١٣٥١)

«Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәһарәт алды, җәүрәбенә (носки) һәм сандалиларына мәсех кылды».

3. Билал радыяллаһу ганһе китергән хәдис:

عَنْ بِلَالٍ كَانَ رَسُولَ اللهِ يَمْسَحُ عَلَي الْخُفَّيْنِ وَالْجَوْرَبَيْنِ (رَوَاهُ الطَّبَرَانِ فِي

الْمُعْجَمِ الْكَبِيرِ رقم: ١٠٦٣)

«Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм җәүрәбенә (носки) һәм сандалиларына мәсех кыла иде».

4. Сәүбән радыяллаһу ганһе җиткергән хәдис:

عَنْ ثَوْبَان قَالَ بعَثَ رَسُولُ اللهِ سَرِيَةُ فَأَصَبَاهُمُ الْبَرْدُ فَلَمَّا قَدِمُوا عَلَي النَّبِيِّ شَكُوا إِلَيْهِ مَا أَصَابَهُمْ مِنَ الْبَرْدِ فَأَمَرَهُمْ أَنْ يَمْسَحُوا عَلَي الْعَصَائِبِ وَالتَّسَاخِينِ (رَوَاهُ أَبُو دَاوُدْ رقم: ١٤٦)

«Бервакыт Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләр төркемен хәрби походка җибәргән. Салкын булганга күрә, сәяхәт вакытында алар күп кенә кыенлыкларга тарыган. Нурлы Мәдинәгә кайткач, алар бу авырлыклар турында Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгәннәр. Шунда Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга мондый шартларда чалма һәм тәсәхиннәрен сөртергә, мәсех кылырга рөхсәт иткән».

Хәдисләрнең ышанычлылыгын тикшерик. Могыйра радыяллаһу ганһе тапшырган беренче хәдис Суфьян Саури, Габдрахман бине Мәһди, имам Әхмәд бине Хәнбәл, Ибне Мәдини һәм имам Мөслим кебек галимнәр тарафыннан бердәм рәвештә зәгыйфь дип таныла. Ә имам Әл-Бәйһакый бу хәдисне шелтәгә лаек (мункар) дип әйтә. Имам Әл-Мөслим фикеренчә, бу хәдисне тапшыручы булган Әбү Кайс һәм Хөзәел башка хәдисләргә каршы киләләр.

Әбү Муса радыяллаһу ганһе тапшырган хәдисне карыйк. Шәех Габдрахман Мөбарәкфури бу хәдисне тапшырган Гыйса бине Синанның мөхәддисләр тарафыннан хәдисләрнең текстларын кушуда гаепләгән булуы турында яза, шуңа күрә бу хәдис ышанычлы була алмый.

Имам Әхмәд, Ибне Мугыйн, Әбү Зурга, Ән-Насаи, Бәйһакый бу хәдисне тапшырган Гыйса бине Синанның ышанычсыз булуы турында әйтәләр. Имам Бәйһакый шулай ук тапшыручы булган Дәххак бине Габдрахманның бу хәдисне Әбү Мусадан ишетмәве турында әйтә.

Билал радыяллаһу ганһе тапшырган өченче хәдисне карыйк. Имам Зәйләгый бу хәдисне тапшыручылар чылбырында Язид бине Әби Зиядның булуы һәм аның ышынычсыз тапшыручы булуы турында яза. Хафиз бине Хәҗәр Язид бине Әби Зиядның картайгач хәтере начар булуы турында әйтә, шуңа өстәп, аның шигый булуын билгеле.

Сәүбән радыяллаһу ганһе тапшырган дүртенче хәдисне карыйк. Ибне Әби Хәтим имам Әхмәд бине Хәнбәл сүзләрен китерә: хәдисне тапшыручы булган Рәшид бине Сәгад Сәүбәннең үзеннән ишетмәгән, шуңа күрә бу хәдис (мункатыйгъ) – көчсез һәм дәлил була алмый. Кайбер кешеләр «тәсәхин» сүзен «оекбаш» дип тәрҗемә итеп, бу хәдисне дәлил буларак кулланмакчы була. Ләкин хәдистә нәкъ менә оекбаш күздә тотылган, дип әйтү дөрес түгел. Мәсәлән, Ибне Әсир «Ән-Нихая» китабында «тәсәхин» сүзен «оекбаш» дип тәрҗемә итә, ә шәех Хәмзә Әсфәхани аны баш киеменең бер төре итеп тәрҗемә итә.

Ә хәзер тәһарәт алганда гади оекбашларны сөрткән кешеләргә сорау бирәсем килә: ни сәбәпле алар шундый зәгыйфь хәдисләр аркасында Аллаһы Тәгаләнең Китабын калдыралар? Ни өчен алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яла ягудан һәм мөселманнар арасында фетнә чыгарудан курыкмыйлар? Кыямәт көнендә наданлыклары өчен ничек җавап бирерләр?

«Төхвәтел Әхвәзи» китабы авторы шәех Габдрахман Мөбарәкфури үз фикерен китерә:

وَالْحَاصِلُ عِنْدِي أَنَّهُ لَيْسَ فِي بَابِ الْمَسْحِ عَلَي الْجَوْرَبَيْنِ حَدِيثٌ صَحِيحٌ مَرْفُوعٌ خَالٍ عَنِ الْكَلَامِ

«Безгә оекбашны сөртү турында бер генә дә ышанычлы хәдис (мәрфугъ) килеп җитмәгән, дигән нәтиҗәгә килдем».

Алда китерелгән дүрт хәдис ышанычлы булган булсалар да, Коръәни Кәримдә ачык китерелгән күрсәтмәләрне аларга гына нигезләнеп чикләргә яки анықларга ярамас иде.

Намаз – диннең терәге. Тәһарәт – намазның ачкычы. Коръәни Кәрим тәһарәт алганда ачык һәм төгәл итеп аякларны юарга куша. Бу күрсәтмә мөселман кешесеннән тәһарәт алганда һәрвакыт аякларын юуны таләп итә. Ләкин хуффларга (күннән тегелгән оек, читек) мәсех кылу рөхсәт ителгән хәдисләр «тәвәтүр» категориясенә кергәнлектән, дүрт мәзһәб галимнәре дә, хуффларга мәсех кылу рөхсәт ителә дип исәпли. Күннән тегелмәгән оекбашларга мәсех кылуны рөхсәт иткән хәдисләр зәгыйфь һәм Коръәни Кәримгә каршы бара алмыйлар, шуңа күрә дини күрсәтмә дә була алмыйлар.

*Аллаһы Тәгаләгә яхшырак билгеле.*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

# Бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү

## Сорау: Хөрмәтле хәзрәт! Әссәләмү галәйкүм! Татарстанда булган казыйлар законлы көчкә ия түгел һәм аларга мөрәҗәгать итәргә ярамый, дип укыдым. Бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү өчен аларның чишелешен таба алган имамнар советына мөрәҗәгать итәргә кирәк икән. Шулаймы?

Җавап: بسم الله الرحمن الرحيم

Мәрхәмәтле Аллаһы исеме белән. Вә галәйкүм әссәлам вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Озак вакытлар мөселманнар яшәгән җирләрдә шәригать кануннары гамәлдә була һәм килеп туган бәхәсләрне шәригать судьялары (казыйлар) чишкән. Соңрак дөньяви хакимият кайбер территорияләрдә шәригать судларын бетерә. Мондый хәл, мәсәлән, мөселманнар яшәгән Испаниядә (Андалусия) һәм Британия империясе идарә иткән Һиндстанда барлыкка килә, аларда 1864 елда шәригать буенча хөкем итү тыела.

Россия – дөньяви дәүләт. Конституция тарафыннан һәр гражданга дин иреге гарантияләнә. Әгәр мөселманның хокуклары кысылган булса, ул үз хокукларын яклау һәм гаделлекне торгызу өчен дөньяви судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Әмма дөньяви суд, шәригать нигезендә, мөселманнар арасындагы бәхәсләрне хәл итә алмаган очраклар була. Әйтик, мөслимә, үзенең ислам кануннары буенча укылган никахын Гражданлык актларын теркәү бүлегендә (ЗАГСта) теркәмәгән булса, дөньяви судта никахын гамәлдән чыгара алмый, судта аның гаризасы кабул ителмәячәк. Мондый очракта аңа бары казыйга мөрәҗәгать итәргә генә кала. Килешүләр нигезендәге милек бәхәсләре белән бәйле низаглар шу-

лай ук ирекле рәвештә Третей искәрмәсе сыйфатында казыяттә каралырга мөмкин. Әлбәттә, казыятләрнең карарлары Россия Федерациясе законнарына каршы килми, ә киресенчә, бәхәсләрне судка кадәр җайга салу өчен файдалы социаль функциягә ия.

Мөселманнар яши торган урыннарда казыйлар булмаган очракта, хәнәфи мәзһәбендә дин тотучылар үзләренә гражданлык эшләрендә карар чыгарырлык казый сайлап куя, дип күзаллана.

Имам Ибне Габидин болай яза: «Хакимиятендә мөселманнар булмаган илләрдә җомга һәм бәйрәм намазларын үткәрергә рөхсәт ителә, ә мөселманнар сайлап алган кеше казый була… »[1].

Имам Кәмал бине Һомәм болай яза: «Хакимиятләрендә мөселманнар булмаган кайбер ислам җирлекләрендә, мәсәлән, безнең көннәрдәге Кордовта, үз артыннан ияртерлек солтан яки башка берәү булмаса, анда мөселманнар арасыннан берсен сайлап алырга һәм аны карарлар чыгарсын өчен, казый итеп билгеләргә кирәк»[2].

Шулай итеп, хәнәфи мәзһәбе буенча, әгәр җирлектә шәригать казые булмаса, мөселманнар аны үз араларыннан сайларга һәм аңа никахны өзү, әҗәтләрне билгеләү, шәригать буенча милек бәхәсләрен хәл итү, мөселманнарның мирасын бүлү кебек гражданлык мәсьәләләрендәге үзара бәхәсләрне хәл итү хокукын бирергә тиеш, дип күрәбез.

Мөселманнарның Диния нәзарәте – билгеле бер җирлектә яшәүче мөселманнарны берләштерүче иҗтимагый оешма. Бу оешманың бурычлары арасында дини эшчәнлекне тәртипкә салуга кагылышлылары да бар – алар мәчет һәм мәдрәсә эшләре, намазлар, ай календаре буенча айның башлану һәм тәмамлану вакытын билгеләү, мәгърифәтчелек эшчәнлеге һ.б. белән бәйлеләре дә бар. Бу оешма үзәкләштерелгән, ягъни мөселманнарны берләштерә торган статуска ия, шулай ук ул РФ Юстиция

[1] Радд Әл-Мохтар, 6/289.

[2] Фәтх Әл-Кадир, 5/461.

министрлыгында рәсми рәвештә теркәлгән, бу аңа дәүләт тарафыннан йөкләтелгән билгеле бер дини вәкаләтләр турында сөйли. Бу вәкаләтләр кысаларында Диния нәзарәтләре үз эшчәнлеген оештыра, махсус казыят органнарын раслый. Казыйлар мөселманнар арасында низагларны хәл итәргә сәләтле имамнар арасыннан сайлап алына һәм билгеләнә. Бу тәҗрибә дөньяви күпдинле дәүләт шартларында хәнәфи мәзһәбе нигезләмәләренә тулысынча туры килә һәм дәүләт-хокукый нормаларга һәм принципларга каршы килми.

*Аллаһы яхшырак белүче.*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

**Чыганаклар:**

1. Ибне Габидин. Радд Әл-Мохтар галә Әд-Дурр Әл-Мохтар. – Әр-Рияд: Дәр галям Әл-Кутуб, 2003. – Т. 6, 289 б.

2. Ибне Һомәм. Әл-Фәтх Әл-Кадир. – Каһирә: Әл-Мәтбәга Әл-Кубра Әл-Әмирийә (Булак), 1315. – Т.5, 461 б.

# Үрнәк затлар

# Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә

## Тууы

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Мәдинәдә, якынча 610 нчы елда дөньяга килгән.

## Нәселе

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең әтисе – Бәну Надир дип аталган яһүди кабиләсе башлыгы Хөйәй бине Әхтәб. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән килешүне бозганга күрә, Бәну Надир кабиләсе Мәдинә шәһәреннән куыла. Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең әтисе Хайбәргә күченеп килә һәм шунда төпләнә. Хайбәрдә дә Хөйәй бине Әхтәб Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә каршы төрле мәкерле эшләрен кыла: Корәешлеләр һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә каршы булган башка кабиләләр арасында бер-берсенә карата ачу тарата.

## Балачагы

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта Сафийә бинте Хөйәй әле яшь булган. Ләкин бик яшь булуына да карамастан, җәмгыятьтә барган вәзгыятьне аңларлык дәрәҗәдә булган. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән Расүл икәнлеген аңласалар да, яһүдиләр, шул исәптән, Сафийә бинте Хөйәйнең әтисе дә, Ислам диненә һәм Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә итагать күрсәтер урынына дошманлашып яшәүне кулайрак күргәннәр.

Ислам диненә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата булган дошманлык хисе әтисеннән Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәгә күчмәгән. Киресенчә, Аллаһы Тәгалә аны Ислам диненә әзерләгән.

## Яшьлеге

Балигълык яшенә җиткәч, Сафийә бинте Хөйәй гаскәри һәм шагыйрь Сәлләм бине Мишкамга кияүгә чыккан. Ләкин бу никах озын гомерле булмаган. Озак та үтми Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә бик бай һәм хөрмәтле булган яһүди Кинәнә бине Әл-ХакыйкӘн-Нударийга кияүгә чыккан. Кинәнәнең Хайбәрдә бик зур һәм ышанычлы ныгытмасы[1] булган. Мөселманнар аны бик авырлык белән алганнар.

## Хайбәр сугышы

Сафийә бинте Хөйәй һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарихы нәкъ менә Хайбәр сугышына бәйле башланган.

Бу сугышта Гарәп ярымутравы мәкерле яһүди кабиләләреннән азат ителгән. Хайбәр шәһәрчеге сигез көчле ныгытмадан торган. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның тарафдарларына шушы ныгытмаларны яулап алуда һәм җиңүдә Үз ярдәмен ирештергән. Яһүдиләрнең байлыкларын мөселманнар ганимәт малы итеп, ә хатыннарын әсирлеккә алганнар. Әсирлеккә төшкән хатын-кызлар арасында Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә дә булган.

---

1 Крепость (ред.).

## Аллаһының Расүле белән никахы

Хайбәрне яулап алган көнне Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Ислам динен кабул иткән. Бу вакыйга болай булган:

Әсирлеккә төшкән Сафийә бинте Хөйәйгә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сайлау мөмкинлеге биргән: ирекле булып, үз халкы янына кайтырга яки Ислам динен кабул итеп, аңа кияүгә чыгарга. Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу тәкъдименә болай дип җавап биргән: «Мин Аллаһы Тәгаләне һәм Аның Расүлен сайлыйм». Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны әсирлектән азат иткән. Йолым аның мәһәре булган.

Соңрак бу вакыйгага бәйле Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә болай дип әйткән: «Ий Аллаһының Расүле! Син миңа Ислам динен кабул итәргә тәкъдим ясаганчы ук мин Ислам динен яраттым. Син миңа күпаллалык һәм Ислам дине арасында сайлау хокукы бирдең, ә мин Аллаһы Тәгалә һәм Аның Расүлен сайладым. Бу минем өчен ирекле булып, үз халкыма кайтуга караганда кыйммәтрәк».

Бу никахның нәтиҗәсе буларак Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яһүдиләрнең аңа карата булган дошманлык мөнәсәбәтенә нокта куярга теләгән. Ләкин яһүдиләр бу никахтан соң да эзәрлекләүләреннән туктамаганнар, үзсүзлелекләре аларның гадәти халәтенә әйләнгән.

## Пәйгамбәребез белән тормышы

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә никахлашканнан соң, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Хайбәрдән Мәдинәгә күчкән. Ул Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күршесе – Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең өендә яши башлаган. Әнсарларның хатыннары Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең

матурлыгы турында күп ишеткән булганнар һәм моның дөресмеюкмы икәнен тикшерергә килгәннәр. Башка хатын-кызлар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм никаб белән битен каплаган Гайшә радыяллаһу ганһәне дә күргән. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның артыннан күзәтеп барган. Гайшә радыяллаһу ганһә Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе өеннән чыккач, аны куып торган да, аның күлмәгеннән тотып: «Аның хакында синең фикерең нинди?» – дип сораган. Гайшә җилкәсен тарткан да, көнчелектән ачуланып: «Минем фикеремчә, ул – яһүдә», – дип әйткән. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Алай дип әйтмә, ул бит хәзер мөслимә. Ул Ислам динен кабул итте һәм үзенең иманын иң күркәм рәвештә исбатлады», – дип әйткән. Гайшә радыяллаһу ганһә бер сүз дә әйтмичә Хәфса бинте Гомәр радыяллаһу ганһә янына барган һәм аңа барлык булган хәлләрне сөйләгән.

Әлеге хәлдән соң Сафия бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм йортына күчкән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыннары ике төркемгә бүленгәннәр: Гайшә, Хәфса һәм Сәүдә радыяллаһу ганһүннә бер якта булган. Ә башка хатыннары һәм кызы Фатыйма радыяллаһу ганһә икенче якта. Сафия бинте радыяллаһу ганһә бу ике якның берсен сайларга тиеш булган. Әлбәттә, бу бик җиңел эш булмаган, чөнки бер якта Пәйгамбәребезнең сөекле хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә, ә икенче якта яраткан кызы Фатыйма радыяллаһу ганһә торган.

Әлеге хәлдә Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәгә кешеләр белән уртак тел таба белү сәләте ярдәм иткән. Фатыйма радыяллаһу ганһә белән яхшы мөнәсәбәттә булу бик җиңел булган, чөнки ул хатын-кызларның мондый түбән эшләрендә катнашмаган.

Әмма Сафийә бинте Хөйәйнең тырышлыгы Гайшә һәм Хәфса радыяллаһу ганһүмәләргә карата яхшы нәтиҗә бирмәгән. Аларның

һөҗүмнәре Сафийәне бик рәнҗеткән. Ул хатыннар үзләренең саф гарәп, бигрәк тә Корәешле булулары белән горурланганнар.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә янына килгән дә, аның елаганын күргән. Ни өчен елаганын белгәч: «Сез ничек итеп миннән яхшырак була аласыз? Минем ирем – Мөхәммәд, әтием – Һарун, агам – Муса» дип нигә әйтмәдең?» – дигән. Шуннан соң Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә тынычланган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм билгеле инде Сафийәне бу өйдә кабул итмәгәннәрен аңлаган. Мөмкинлек булганда гел аны яклаган.

## Сафийә бинте Хөйәйнең дәрәҗәсе

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә күп дәрәҗәләргә ия булган. Тышкы матурлыгы белән беррәттән ул күркәм холкы, тәкъвалыгы, ярдәмчеллеге белән аерылып торган. Ә иң югары дәрәҗәсе – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән никахы.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең намуслылыгын һәм ихласлылыгын югары бәяләгән.

Риваятьләрдән күренгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм авырый башлагач, хатыннары аның янына җыелган. Шул вакытта Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Ий Аллаһының Расүле! Аллаһы белән ант итәм, мин синең урыныңда газапланырга теләр идем», – дип әйткән. Калган хатыннар бу хәлне күреп, Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәгә төртеп күрсәтеп, бер-берсенә күз кысышканнар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм моны күреп аларга болай дип әйткән: «Авызларыгызны

чайкагыз». Алар Пәйгамбәребездән: «Аллаһының Расүле, ни өчен?» – дип сораганнар. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы белән ант итәм, ул ихлас әйтә», – дип әйткән.

## Вафаты

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булганнан соң, Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Аллаһының Расүле үз тормышында нинди әһәмиятле урын алып торуын аңлаган.

Бервакыт Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең кәнизәге Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе янына килеп, Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең шимбә көнен хөрмәтләвен һәм яһүдиләр белән аралашуын хәбәр иткән. Гомәр хәлифә аннан бу турыда сорашырга боерган. Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә бу хәлгә ачыклык кертеп: «Шимбә мәсьәләсенә килгәндә, Аллаһы Тәгалә миңа аның урынына җомга көнен биргәннән башлап, мин аны яратмыйм. Ә яһүдиләргә килгәндә, алар белән мине кардәшлек мөнәсәбәтләре бәйли һәм шушы туганлык мөнәсәбәтләрен саклау – ул минем бурычым, шуңа күрә мин аларны саклыйм», – дип әйткән. Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә бу кәнизәк кыздан үзенә яла ягарга нәрсә мәҗбүр итүе турында сораштыргач, кәнизәк кыз: «Шәйтан», – дип җавап биргән. Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә аңа: «Бар кит, син азат», – дип әйткән.

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң шактый озак еллар яшәгән. Тәкъва һәм тугрылыклы хатын булганга, барлык гомерен Аллаһы Тәгаләгә итагать итү һәм гыйбадәткә багышлаган. Ул тугры хәлифәләр идарә иткән чорларда яшәп, бу чорларның зур үзгәрешләрен һәм авырлыкларын кичергән, мөселман өммәтенең күпчелек тарихи вакыйгаларында хәлиткеч роль уйнаган.

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Могавия идарә иткән чорда, һиҗри исәп буенча 50 нче еллар тирәсендә, 69 яшендә вафат булган.

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә мөэминнәрнең аналары һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызлары белән янәшә Бакыйгъ зиратында күмелгән. Аңа җеназа намазын күренекле сәхабәләр укыган.

*Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде*

# Әңгәмә

# Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин: «Халкыбызга чал тарихыбызны күрсәтергә тиешбез»



*2022 ел Рәсәебездә зур вакыйга, истәлекле дата – болгар бабаларыбызның Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүенә 1100 ел. Шулай ук быел тагы бер мөһим вакыйга – башкалабызның Казансу елгасы ярында Җәмигъ мәчетенең төзелә башлавы көтелә. Мәчеткә нигез салыну, Аллаһы боерса, нәкъ менә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү көннәрендә тормышка ашырылырга тиеш. Төзергә ниятләнгән мәчет хакында һәм истәлекле дата билгеләп үтүнең мөһимлеге турында Казан шәһәренең Совет районы мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин белән сөйләштек.*

**– Хәзрәт, әссәләмү галәйкүм. Быел Татарстаныбызда зур вакыйга – Болгар бабаларыбызның Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы билгеләп үтелә. Сезнеңчә, халкыбыз өчен бу чара, тарихыбызны искә төшерү нинди роль уйнаячак?**

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Әлбәттә, беренчедән, әлеге вакыйга халкыбызның үз тарихына игътибар бирүенә этәрер дип өметләнәм. Икенчедән, меңләгән, миллионлаган татар халкына динебезне, гореф-гадәтләребезне өйрәнә, аның белән кызыксына башлавына бер этәргеч булуына өмет баглыйм. Сүз дә юк, бу чараны

үткәргәндә без булдыра алганча халкыбызга үзебезнең чал тарихыбызны күрсәтергә, аның хакындагы мәгълүматны һәрбер кешегә дә җиткерер өчен тырышырга тиеш.

**– Бездән соң килгән буын Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең тарихын истә тотсын өчен без нәрсә эшли алабыз?**

– Безнең татар халкы Ислам динен кабул иткән урын турында, ул вакыйга хакында истә тотсын өчен, әле үз вакытында Тәлгать хәзрәт Таҗетдин тарафыннан торгызылып җибәрелгән шушы күркәм мәрасимне, күркәм йоланы дәвам итәргә кирәк. Анда бөтен милләтләр катнашканда, бу – татар халкының рәсми рәвештә Ислам дине кабул иткән урыны, дип тәкърарланырга тиеш, дип саныйм. Бу урын халыкның фәкать җыелышып, ашап-эчеп, ял итеп китү урыны түгел, ә бөтен Рәсәй җирлегендә, иң беренче булып Ислам динен кабул иткән халык менә монда яшәгән, нәкъ шушы урында Ислам динен кабул иткәннәр, дип фикерләнергә тиеш. Бу безнең тарихи урын, Ислам динен кабул иткән җир икәнлеген без онытмыйча һәр ел саен шушы изге гамәлне истә тотып, Болгар җирендә җыелышуыбызның бер дә зыяны булыр дип уйламыйм. Киресенчә, файдасы гына булыр дип саныйм.

**– Соңгы вакытта Казансу яр буенда мәчет төзелүнең планлаштырылуы хакында хәбәрләр ишетәбез. Ничек уйлыйсыз, Казанга, гомумән Татарстаныбызга мондый зур мәчет кирәкме?**

– Бу зур мәчетнең төзелүе – безнең милләт халкының соңгы 30-35 ел буе кылган догасының нәтиҗәсе ул. Иртәме соңмы ул төзеләчәк һәм милләтебезнең яңа тарихи һәйкәленә әвереләчәк дип инанам. Аның Казаныбызның мөкатдәс шәһәр икәнлегенең бер бәясе, бер дәлиле булып торуына ышанып яшим.

**– Башка мәчетләрдән үзгә итеп төзелергә ниятләнгән бу бина – яңа мәчет, сезнеңчә нинди булырга тиеш? (Динебез нормаларыннан читкә китмәсен өчен)**

– Әлбәттә, бу мәчет бөтен яктан да бик нәфис булырга тиеш. Аның төзелешендә архитектура ягыннан да, функциональ яктан, инженерия ягыннан да иң алдынгы алымнар кулланылырга тиеш. Сүз дә юк, бу вакытта шәригать таләпләреннән чыгу тиеш түгел һәм шул ук вакытта төзелеш безнең хәзерге фәнни һәм техник прогрессның соңгы иң алдынгы нәтиҗәләрен кулланып гамәлгә ашырылырга тиеш, дип саныйм.

**– Шул ук вакытта, сезнеңчә, әлеге мәчет нинди булмаска тиеш?**

– Бу мәчет, гомумән, ниндидер бер бәхәсләр урынына әйләнмәскә тиеш, ягъни бездә – дин әһелләрендә, мөселман кардәшләребездә мәчеткә кагылышлы бәхәс чыга калса да, шушы юлдан Аллаһы Тәгалә сакласын дип, дога кылырга һәм үзебезгә дә моннан сакланырга кирәк. Шушы мәчет бәхәсләрдән, гаугадан ерак булса иде. Бу мәчетнең татар халкының яңа һәм мәңгелеккә таба үрелгән бер милли маякларының берсе булып китүенә өметләнәм.

*Әңгәмәне Айсылу Юлдашева оештырды*

# «Нәрсә?<br>Кайда?<br>Кайчан?»

# Гыйнвар

## «Итил елгасында мөселманнар корылтае» Исламны кабул итүнең 1100 еллыгы чараларын ачып җибәрде

5 гыйнварда Болгарда тантаналы рәвештә Рәсәйкүләм мөселман җыены ачылды. Ул Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысаларында тәүге чара булды. Татарстан мөфтияте тарафыннан оештырылган форум Итил елгасында Рәсәй мөселманнары корылтае рәвешендә үтте. Анда катнашу өчен Татарстан, Мәскәү, Ленинград һәм Свердовск өлкәләре, Кузбасс, Башкортостан, Мари Иле республикаларыннан һәм башка төбәкләрдән дин кардәшләр җыелды. Дүрт көнлек форумның эшендә күренекле экспертлар, галимнәр, атаклы вәгазьчеләр эшләде. Остазлар фәнни-популяр лекцияләр, вәгазьләр, презентацияләр, мастер-класслар белән чыгыш ясады. Моннан тыш, программада квестлар, тренинглар, спорт чаралары каралган иде. Җыен премьералар мәйданчыгы да булды: биредә беренче тапкыр «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмының киңәйтелгән трейлеры һәм «Хозур ТВ» телеканалында татар теленә тәрҗемә ителгән «Билал» мультфильмы күрсәтелде, шулай ук «Туганбатыр» милли проекты тәкъдим ителде.

## Нәзарәт Коръәннең кульязма мосхафын язуга кереште

Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көнендә (12 нче гыйнварда), Казанның «Кол Шәриф» мәчетендә бөтен Рәсәйдән килгән мөфтиләр һәм дин әһелләренең хәер-фатихасы белән Диния нәзарәтенең яңа проектына старт бирелде – Коръәннең кульязма мосхафын язу тантаналы рәвештә башланып китте. Рәсми чара Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен

рәсми рәвештә кабул итүгә 1100 ел тулуга әзерлек һәм бәйрәм итү буенча республика оештыру комитеты утырышы кысаларында үткәрелде. Әлеге вакыйгага күпсанлы кунаклар – Оештыру комитеты утырышында катнашучылар, мөфтиләр, Рәсәйнең танылган мөселман дин әһелләре, хакимият органнары, фәнни җәмәгатьчелек һәм ММЧ вәкилләре катнашында узды. Аларның күз алдында каллиграф Изге Коръәннең беренче «Фатиха» сүрәсен язды. Бүгенге көндә эш дәвам итә. Проектның төп башкаручысы итеп, Казан каллиграфы Артур Писаренко сайланды. Ул Рәсәй ислам институты каршындагы «Ән-Намир Әл-Мүхаттат» гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгате үзәге директоры Рамил Насыйбулловның шәкерте. Әлеге эшкә консультант сыйфатында Дубайдан дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Дубайның Коръән әзерләү комиссиясе (DIHQA) башлыгы, хафизлыкның иң югары дәрәҗәсенә ия булган, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел дәвамчысы шәех Мәэмүн Әр-Рави җәлеп ителде. Моннан тыш, комиссиягә Рәсәйнең башка төбәкләреннән һәм чит илләрдән белгечләр керде.

## Казанда Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына әзерләнү һәм аны үткәрү буенча Республика оештыру комитетының киңәйтелгән утырышы узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көнендә (12 нче гыйнварда) Казанда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына әзерләнү һәм аны үткәрү буенча Республика оештыру комитетының киңәйтелгән утырышы узды. Утырышта Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, РФ Президенты Администрациясенең Эчке сәясәт идарәсе башлыгы урынба-

сары Анатолий Вылегжанин, РФ мәдәният министры урынбасары, федераль оештыру комитетының җаваплы секретаре Ольга Ярилова, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары вәкилләре, мөфтиләр, үзәкләштерелгән дини оешмалар җитәкчеләре катнашты. Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да чыгыш ясады һәм Нәзарәтнең 1100 еллык кысаларындагы башлангычлары хакында сөйләде. Шулай ук утырышта Татарстан мөфтие урынбасары, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү логотипы проектын тәкъдим итте.

## Нәзарәт мөселман яшьләренең кышкы форумын уздырды

Гыйнвар аенда Татарстан Диния нәзарәте Казанда һәм Болгарда мөселман яшьләренең кышкы форумын уздырды. Әлеге чара Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырыла торган күпсанлы чараларның берсе булып торды. Быелгы кышкы форум да, узган елгы кебек үк, ике мәйданчыкта һәм бер-бер артлы – егетләр һәм кызлар өчен аерым узды. Унөченче тапкыр оештырыла торган форумда 60 егет һәм 60 кыз катнашты. Әлеге җыеннар мөселман яшьләренең дини белемен арттыру, әхлагын камилләштерү, аларны рухи кыйммәтләргә, татар халкы традицияләренә карата игътибарын һәм хөрмәтен арттыру ниятеннән оештырылды. Ел саен уза торган әлеге форум яшьләргә белемнәрен ныгытырга гына түгел, берләшергә, танышырга, рухи яктан баерга һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

## Бөтендөнья Хиҗаб көненә «Хозур» нәшрияты «Хиҗаб» белешмәлеген әзерләде

Бөтендөнья Хиҗаб көненә багышлап Татарстан мөфтиятенең Голәмәләр шурасы һәм «Хозур» нәшрият йорты яңа басма – рус телендә «Хиҗаб» брошюра-белешмәлеген әзерләп бастырды. Әлеге басмада хатын-кызларга яулык киюнең фарыз булуы хакында Коръәннән, сөннәттән һәм фәнни хезмәтләрдән төп дәлилләр китерелгән, мөселман хатын-кызы киеменә кагылышлы төп терминология аңлатылып бирелгән. Китап фәнни-популяр телдә һәм массакүләм аудитория өчен атап язылган, ул дини һәм хокукый характердагы сорауларга җавап табарга ярдәм итә, хиҗабның төп мәгънәсен – хатын-кызны саклавын һәм аны тыйнак итеп күрсәтүен ачып бирә. «Хиҗаб» китабы мөслимәләрнең генә өстәл китабы түгел, ул һөнәри эшчәнлекләрендә хиҗаб мәсьәләләре белән очрашып торучы укытучылар, эшмәкәрләр, спортчылар, юристлар, судьялар һ.б. җәмәгатьчелекләр өчен дә файдалы булачак.

## Аксакаллар шурасы дәүләт алкоголь инспекциясен приниципиаль булырга һәм тарату нокталарын арттырмаска чакырды

Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы этил спиртын һәм алкоголь продукциясен җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча ТР Дәүләт инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтхановка мөрәҗәгать юллады. Хат агымдагы елның 25 гыйнварында узган ведомство киңәшмәсе нәтиҗәләре уңаеннан язылды – киңәшмәдә инспекция алдында авылларда хәмер сату буенча сәүдә нокталарын арттыру бурычы куела. Аксакаллар шурасы бу уңайдан үзенең канәгатьсезлеген белдерде һәм имамнарының эшчәнлеге авылларда исерткеч эчемлекләр сату урыннарын киметүгә

юнәлдерелгән, дип билгеләде. Моның өчен хәзрәтләр җирле хакимият, халык, эшмәкәрләр, авыл советлары белән сөйләшүләр алып бара. Имамнарның тырышлыгы белән Татарстандагы 16 муниципаль районга караган 30 дан артык авылның кибетләрендә исерткеч эчемлекләр бөтенләй сатылмый яисә изге Рамазан ае вакытында туктатыла. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең карары мөхтәсибәтләрнең халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, хәмер эчүдән баш тартырга чакыру һәм авылларда исерткеч эчемлекләрне сату нокталарын ябу буенча тырышлыкларын юкка чыгара. Аксакаллар игътибарны авылларда хәмер сату нокталарын арттыру бурычы татар-мөселман традицияләрен саклау мәсьәләләренә каршы куелуына юнәлтә һәм 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын каршыларга әзерлек баруын, әлеге зур тарихи дата Татарстанны Рәсәйнең мөселман үзәге итеп күрсәтүен искәртте. Шура ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесен әлеге мөһим мәсьәләдә принципиальлекне сакларга һәм Татарстан Республикасындагы татар авылларын хәмер сатудан сакларга чакырды.

# Февраль

## Рамазанга әзерләнү өчен Коръән курсларына йөздән артык казанлы язылды

Раҗәб аеның беренче көнендә, 2 нче февральдән, ягъни Рамазанга 2 ай кала, Казанда Коръән укырга өйрәтү дәресләре башланып китте. Әлеге курслар Рамазан-шәриф аена әзерләнү максатыннан Татарстан мөфтияте һәм КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге тарафыннан оештырылды. Коръән дәресләренә 16 яшьтән өлкәнрәк булган йөздән артык кеше язылды. Махсус оештырылган курслар 8 мәчеттә атнасына 2 тапкыр ике ай дәвамында гарәп алфавитын, тәҗвид һәм Коръән уку кагыйдәләрен өйрәнүне күздә тота.

Дәресләрне Коръән-хафизлар үзәге белгечләре алып бара. Курсларны уңышлы тәмамлаучыларга сертификат һәм бүләк итеп Коръән тапшырылачак. Әлеге чара Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында үткәрелә.

## «Гаилә» мәчетендә гаиләләр өчен ышаныч телефоны эшли башлады

Февраль башында Казанның «Гаилә» мәчетендә яңа проект – гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү буенча Рәсәйкүләм ышаныч телефоны эшли башлады. 8-800-222-05-62 федераль номерына шалтырату – сөйләшүнең дәвамлылыгына карамастан, һәрбер мобиль яки стационар телефоннан бушлай. Ышаныч телефоны консультанты белән аралашу аноним һәм конфиденциаль рәвештә алып барыла. Телефон Рәсәй территориясендә эшли, аңа илнең теләсә кайсы почмагыннан шалтыратырга мөмкин. Ышаныч телефоны буенча консультацияне «Гаилә» мәчете каршында эшли торган «Адәм белән Һава» исемле Гаилә төзү һәм аны саклау белгечләре бирә. Гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү хезмәте ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрдә кыенлыкларны чишәргә, балалар белән мөнәсәбәтләрне җайларга, кризис халәтеннән чыгу өчен шәхси һәм рухи ресурсларны эшкә җигәргә ярдәм итәчәк. Моннан тыш, «Гаилә» мәчетенең ышаныч телефоны эшчәнлеге кешеләрдә хисси яктан төшенлеккә бирелүне, үз-үзеңә кул салу, аерылышу очракларын булдырмый калуга, шулай ук җәмгыятьтә гаилә институтын ныгытуга һәм татар-мөселман традицияләрен саклап калуга юнәлдерелгән.

## Казанда Г.Барудиның тууына 165 ел тулу уңаеннан фәнни җыен узды

Раҗәб аеның 14 нче көнендә (15 нче февральдә), Казанда мәгърифәтче, педагог, татар дин галиме Галимҗан Барудиның 165 еллык юбилее алдыннан республикакүләм фәнни-гамәли конференция узды. Фәнни җыен «Татар дин галимнәренең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мирасын саклауга һәм өйрәнүгә керткән өлеше» исеме астында оештырылды. Чараны Татарстан Республикасының «Иман» мәдәният-мәгърифәт үзәге» төбәк хәйрия иҗтимагый оешмасы һәм РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе үткәрде. Конференция эшендә танылган галимнәр, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, иганәчеләр, татар дин гыйлеме һәм мөселман фикере үсеше тарихы белән кызыксынучылар, иганәчеләр, шулай ук Рәсәй ислам институты һәм Ислам динен кабул итүгә 1100 ел исемендәге Казан мөселман югары мәдрәсәсе шәкертләре катнашты. Галимҗан Баруди, Габденнасыйр Курсави, Гатаулла Баязитов, Шәйхелислам Хәмиди кебек татар дин әһелләренең хезмәтләре, аларның дини мирасны саклауга һәм өйрәнүгә керткән өлеше турында фәнни чыгышлар тыңлау белән беррәттән, катнашучылар татар галимнәренең басылып чыккан хезмәтләре, «Иман» мәдәният-мәгърифәт үзәге», «Иман» нәшрияты һәм Апанай мәдрәсәсенең киңкырлы эшчәнлеге белән таныша алды. Аларга шулай ук мәгърифәтче, педагог, татар дин галиме Галимҗан Барудиның «Әл-Әрбәгинәт әл-мутәсәлсилә» хезмәте хәзерге заман татар теленә тәрҗемә ителеп басылып чыккан китапны тәкъдим итте. Аны Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров төзеде.

## Мөфти Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр форумы президенты белән Халыкара Коръән бәйгесе уздыру турында сөйләште

Раҗәб аеның 20 нче көнендә (21 нче февральдә), Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Нәзарәттә Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр форумы президенты Таха Айхан җитәкчелегендәге делегацияне кабул итте. Мөфтияттә узган очрашуда Таха Айхан хәзрәтне якынлашып килә торган зур һәм мөһим чара – Казанда Халыкара Коръән укучылар бәйгесен уздыру проекты белән таныштырды. Җитәкчеләр конкурсны оештыру мәсьәләләре буенча сөйләште. Конкурсны Рамазан-шәриф ае башланыр алдыннан, 27-30 март көннәрендә уздыру күздә тотыла. Бәйге «Казан — Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы» чаралары һәм Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында уздырыла. Анда ислам дөньясының һәм гомумән мөселман халкы яшәгән барлык илләрдән дә яшь хафиз егетләр һәм кызлар катнаша ала. Катнашу өчен төп шартларның берсе – 18-30 яшьтә булу, Коръәнне тулысынча яттан белү.

## Ике ай эчендә Нәзарәтнең «Даруль-ифта» call-үзәге халыкның 760 соравы буенча фәтва чыгарды

דиния нәзарәтенең «Даруль-ифта» мөселман call-үзәге шәригать белгечләре 2022 елның 2 ае эчендә мөселманнардан килеп ирешкән 760 мөрәҗәгатькә җавап бирде. Нигездә халыкның сораулары намаз уку тәртипләре, ураза тоту, зәкят түләү, гомрә кылу, гакыйдә, талак, криптовалюта, инвестицияләр, банклар, хәләл финанс инструментлар һ.б. мәсьәләләргә кагылышлы булды. Сорауларга җаваплар call-үзәктә классик дини-илаһият хезмәтләре нигезендә Хәнәфи мәзһәбе кысаларында

әзерләнә һәм фәтвалар булып тора. Проблемалы сораулар буенча дини хөкемнәр телефон аша телдән, шулай ук язмача электрон почта һәм мессенджерлар аша җиткерелә. Фәтваларның кайберләре Нәзарәт сайтында «Файдалы мәгълүмат» бүлегендә бастырыла. Call-үзәккә мөрәҗәгатьләр Рәсәйнең төрле почмакларыннан – Татарстан, Башкортстан республикаларыннан, Чиләбе, Омск, Оренбург өлкәләреннән, Мәскәүдән, һ.б. төбәкләрдән килә. «Даруль-ифта» call-үзәге Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән 2019 елда булдырылды. Теләге булган һәркем эш көннәрендә сәгать 10.00нан 16.00га кадәр 8 800 222 7667 номерына шалтыратып, үзен борчыган сорауларга җавап алырга мөмкин.

## Казанда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәне нигезләгән Исхак хәзрәт Лотфуллинны искә алдылар

Раҗәб аеның 24 нче көнендә (25 нче февральдә), Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә «Татарны олы милләт иткән зыялылар – безнең хәтеребездә!» дип исемләнгән фәнни-гамәли чыгышлар бәйгесе үтте. Әлеге чара танылган милләтпәрвәр шәхес, Казанның Кабан арты мәчете имам-хатыйбы, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең җитәкчесе булып эшләгән Исхак хәзрәт Лотфуллинның тууына 80 ел тулу уңаеннан уздырылды. Узган гасырның 90 нчы елларында дини күтәрелешнең башында торган, күпләгән дини биналарны кайтаруда һәм шәкертләр тәрбияләүдә катнашкан, фидакарьлеге белән аерылып торган Исхак хәзрәт Лотфуллинны искә алу чарасына аның белән күп еллар бергә эшләгән хәзрәтләр, аның шәкертләре, гаиләсе җыелды.

## Darul-Kutub.com электрон китапханәсе фонды 35 иске китапка баеды

2022 елның гыйнвар аеннан башлап февраль ахырына кадәр Darul-Kutub.com электрон китапханәсенә 35 исемдәге иске китап цифрлаштырылып өстәлде. Әлеге хезмәтләр арасында 1918 елга кадәр татар мәдрәсәләрендә кулланылган дәреслекләр, уку әсбаплары булып файдаланылган кыйммәтле чыганаклар (Әхмәдһади Максудиның «Әд-Дурус әш-шифахия», «Русистан», Гатаулла Баязитовның «Шәраитуль-иман» һ.б.), Җәләлетдин Әс-Суютыйның зур классик 5 китабы, Ризаэддин Фәхреддиннең «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр»е, Галимҗан Барудиның «Хәтер дәфтәре», Габделхәбир хәзрәт Яруллинның «Хөтбәләр мәҗмугасы», шулай ук К.Хәмзин, М.Мәхмүтов, Г.Сәйфуллин редакциясендә басылган «Гарәп-татар-рус алынмалары сүзлеге» бар. Китаплар фикһ, гакыйдә, хәдис, тәфсир, гарәп теле, ислам нигезләре, тарих һ.б. фәннәр буенча мөһим басмалар булып тора. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, сайтта XX йөз башында нәшер ителгән вакытлы матбугат белән дә танышырга мөмкин, мисал өчен, быелның февралендә 163 биттән торган «Мөгаллим» журналы цифрлаштырылды һәм сайтта урын алды. Хәзерге вакытта Darul-Kutub.com электрон китапханәсенә йөкләнгән китаплар саны 1339га җитте (шуның 1247се – дини мираска караган хезмәтләр, 92се — хәзерге әдәбият). Хезмәтләр — татар, иске татар һәм гарәп телләрендә.

# Март

## Казан галимнәре Казанны мөселман дөньясында беренче басма Коръән басылган шәһәр дип тану турындагы башлангычны хуплады

1 мартта ТР Фәннәр Академиясенең Мәрҗани исемендәге Тарих институтында тарихчылар, ислам белгечләре һәм журналистлар катнашында «Коръәннең Казан басмалары: тарих һәм тикшеренүләр» дигән түгәрәк өстәл узды. Билгеле булганча, «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышының Җиддәдә узган соңгы пленар утырышы барышында Татарстан Президенты һәм Төркем җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов 1803 елны мөселманнар әзерләгән беренче басма Коръән нәшер ителү истәлекле елы итеп билгеләү, шулай ук Казанны «Мөселман дөньясында беренче басма Коръән басылган шәһәр» дип игълан итү тәкъдиме белән чыкты. Бу башлангычны тормышка ашыру юлында түгәрәк өстәл утырышы беренче фәнни вакыйга булды.

Фикер алышу барышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Казан шәһәрендә мосхафларны бастыру» хезмәтен мисал итеп китерде, аның авторы Ганим Каддури Хәмд ассызыклаганча, 1803 елда басылган Казан Коръән басмасы - ул мөселман дөньясында басылган һәм «Әр-Расм Әл-Усмани» стандартына туры килгән беренче басма. Хәзрәт, бу сүзләрне раслап, Казан һәм Санкт-Петербург басмаларына ясалган чагыштырма анализ ясады һәм бу анализның Санкт-Петербург типографиясендә булган оттисклар Казанга күчерелгәнен һәм «Казан басмасы» өчен файдаланылганын дәлилләмәвен исбатлады. «Беренче басма Коръән Казанда өр-яңадан әзерләнгән һәм беренче тапкыр «Әр-Расм Әл-Усмани» стандартына туры килгән булып чыга, – дип белдерде Камил хәзрәт. – Алга таба (минем архивта «Казан басмасы» ның төрле

басмалары бар) без нәширләрнең әлеге стандарттан китүен күзәтә алабыз. Бу хакта Мәрҗани үзенең «Фәваид Әл-Мөһиммә» китабында яза, аннары 1909 елның 7 гыйнварында Казанда җитешсезлекләрне тикшерү һәм «Казан басмасы»н кабат бастыру өчен махсус 300 кеше җыела, алар арасында Әхмәдһади Максуди, Шәйхелислам Хәмиди, Муса Бигиев һ.б. күренекле мөселман галимнәре дә була. Җыелыш нәтиҗәләре буенча Муса Бигиевнең иске татар язуындагы «Тәсхих ресми хат» дип аталган китабы дөнья күрә. Галимнәр беренче утырыш барышында уртак фикергә килә алмый һәм бер атнадан соң кабат җыела. Алар, комиссиягә берләшеп, «Казан басмасы»нда төзәтергә кирәк булган 57 урынны ачыклый. Галимнәр Әр-Расм Әл-Усмани мосхафына иярү мәҗбүри дигән фикергә килә». Аннары Камил хәзрәт «Казан басмасы»н бастыру датасына тукталды: «Без Казанда Азия типографиясенә нигез салынган елны төгәл беләбез. Әмма мин, Коръән басмаларын әзерләү буенча тәҗрибәмне исәпкә алып, хәтта заманча мөмкинлекләр һәм технологияләр булганда да, шуны әйтә алам: ике елдан да кимрәк вакыт эчендә Коръәнне бастырып әзерләү мөмкин түгел. Күптән түгел Дубайда Коръән басылды. Алар аны 7 ел әзерләгәннәр. Ризаэддин Фәхреддин һәм Мөхәммәт Морат Рәмзи 1801 елда Коръән басылуы турында язалар. Әмма монда сүз «Һәфтияк Шәриф», ягъни Коръәннең җидедән бер өлеше, сайланма сүрәләр җыентыгы турында бара. Фән ягыннан караганда да, мантыйк ягыннан караганда да, кыска вакыт эчендә тулы бер Коръән басмасын әзерләү мөмкин түгел», – диде ул. Мөфтинең сүзләре «Каталогъ книгъ, отпечатанныхъ въ типографіи Императорскаго Казанскаго университета съ 1800 до 1896 годъ» дигән чыганакны тәкъдим итү барышында расланды, анда 1801 елда – «Һәфтияк Шәриф» һәм 1803 елда тулы «Казан басмасы» бастырылу турында мәгълүматлар чагылдырылган.

## Нәзарәтнең Пленум утырышы узды

Раҗәб аеның 30 нчы көнендә (3 нче мартта), Казанда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Пленум утырышы узды. Көн тәртибендәге төп мәсьәләләрнең берсе 2021 елга йомгак ясаудан гыйбарәт булды. Пленумда Нәзарәт эшчәнлегенең төп юнәлешләре җитәкчеләре эш күрсәткечләре буенча хисап тотты һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча үзләренең тәкъдимнәрен җиткерде. Утырыш Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин рәислегендә һәм казыйлар, имам-мөхтәсибләр, мәдрәсә мөдирләре, Татарстан голәмәләре, Нәзарәтнең структур бүлекчәләре һәм гамәлгә куелган оешма җитәкчеләре катнашында үтте. Пленум кысаларында хәзрәтләр мөселман уку йортларының торышы һәм аларның киләчәге, кадрлар әзерләү, иҗтимагый-сәяси вәзгыять һ. б. мәсьәләләр буенча фикер алыштылар һәм үз тәкъдимнәрен әйттеләр. Алдагы ике көндә Татарстан имам-мөхтәсибләре һәм казыйлар өчен укулар узды.

## 2021 елда Нәзарәтнең Голәмәләр шурасы 4 яңа хәләл финанс продуктын раслады

Раҗәб аеның 30 нчы көнендә (3 нче мартта), Татарстан мөфтиятенең Пленум утырышы барышында 2021 ел эшчәнлеге турында хисап белән Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев чыгыш ясады. Ул мөселман галимнәре тарафыннан башкарылган эшчәнлекнең нәтиҗәләре хакында сөйләде. Рөстәм хәзрәт хәбәр иткәнчә, 2021 елда Голәмәләр шурасы эшчәнлегенең иң мөһим эш нәтиҗәсе булып яңа чыккан ислам банк продуктларын өйрәнү һәм раслау торды. Нәтиҗәдә, Нәзарәт голәмәләре тарафыннан Рәсәй базарында 4 финанс хезмәте күрсәтү хупланды: күчемсез милек сатып алу өчен «Ак Барс банк»та өлешләп түләү; «Ак барс капитал»да хәләл инвестицияләү инструмен-

ты; «Сахих инвест»та кыйммәтле кәгазьләрнең шәригать таләпләренә туры килү-килмәвен билгели торган мобиль кушымта; «Мирас» финанс йортында (ул «Мирбизнесбанк» компаниясе гамәлгә куйган оешма) – автотранспорт, төзелеш һәм көнкүреш техникасы сатып алу өчен мурабаха принцибы буенча өлешләп түләү. Финанс продуктларын раслаудан тыш, голәмәләр дини мәсьәләләр буенча халыкара сөйләшүләр алып бару, Татарстан өммәтенең эчке мәсьәләләре буенча карарлар әзерләү, мөгаллимлек эшчәнлеге һәм Шәригать таләпләре нигезендә коммерция килешүләренең үрнәкләрен ясау белән шөгыльләнде. Шулай ук шура халыкара дәрәҗәдә – Евразия Голәмәләр шурасы һәм Төркия Голәмәләр шурасы утырышлары барышында тарихи һәм заманча татар дин гыйлеме мәктәбен лаеклы рәвештә тәкъдим итте. Татарстан мөфтияте белгечләре намаз вакытларын билгеләү, никах һәм талак мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен экспертлар сыйфатында җәлеп ителде.

## «Хозур» нәшрият йорты Имам Газалинең «Әдәпләр» китабын татар теленә тәрҗемәдә нәшер итте

Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йорты татар телендә Имам Әбү Хәмид Әл-Газалиның «Әдәпләр» китабын татар теленә тәрҗемә итеп бастырды. Әлеге китап нәфес һәм югары әхлакый сыйфатларны тәрбияләүдә, кешенең холкын һәм үз-үзен тотышын камилләштерүдә бик файдалы нәсыйхәтләр чыганагы булып хезмәт итәчәк. Китапта китерелгән әдәпләрне өйрәнү һәм гамәлдә куллану кешенең әхлагын, үз-үзе, якыннары һәм, иң мөһиме, Аллаһы Тәгалә белән мөнәсәбәтләрен яхшыртырга ярдәм итәр. Моңа кадәр әлеге басма «Хозур» нәшрият йортында гарәп теленнән рус теленә тәрҗемә ителеп дөнья күргән иде.

## Нәзарәт хатын-кызлар өчен Коръән уку очрашулары башлады

Шәгъбән аеның 6 нчы көнендә (9 нчы мартта), Нәзарәт Казанның Галиев мәчетендә барлык мөслимәләр өчен Коръән уку дәрес-очрашуларын башлап җибәрде. Әлеге чара Рамазан-шәриф аена әзерләнү максатыннан, атна саен Коръән укый белүчеләр өчен уздырыла. Төп максат – Коръән укуда камилләшү, хаталарны төзәтү, куркуны җиңү. Очрашулар гарәп хәрефләрен һәм тәҗвид кагыйдәләрен белүчеләр, әмма әйтелешне (мәхраҗ) төзәтергә теләүчеләр өчен махсус оештырыла. Шәкертләр остаз Лилия Ильясова белән бергәлектә практик күнегүләр ярдәмендә кагыйдәләрне кабатлаячак, катлаулы урыннарны өйрәнәчәк, ятлаган аять-сүрәләрнең укылышын тикшерәчәк.

## Мөфти Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Илчесе урынбасары белән очрашты

Шәгъбән аеның 7 нче көнендә (10 нчы мартта), мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан мөфтиятендә Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Рәсәйдәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе урынбасары – илче киңәшчесе Хамәд Рашед Али Бин Алван Әл-Хәбси җитәкчелегендәге делегацияне кабул итте. Очрашу барышында Камил хәзрәт татар халкында һәм Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине тарихы, татар дин галимнәренең мөселман дөньясында тоткан урыны, Татарстанда дин кардәшләребезнең яшәеше турында бай мәгълүматлар бирде.

Мөфти, Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан Нәзарәт тарафыннан быел гыйнвар аенда Коръәннең кульъязма мосхафы языла башлавын хәбәр итте, яңа мосхафны әзерләү барышы белән таныштырды. Әлеге юбилей уңаеннан Нәзарәтнең нәшриятчылык өлкәсендәге планнары белән бүлеште. Оч-

рашуда шулай ук Рәсәйдәге «Хозур ТВ» беренче мөселман телевидениесе эшчәнлеге, тапшырулар әзерләү, медиапроектлар һ.б. буенча фикер алыштылар.

## Мөфти Иран Ислам Республикасы Илчесе белән очрашты

Шәгъбан аеның 7 нче көнендә (10 нчы мартта), мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның Галиев мәчетендә Иран Ислам Республикасының Рәсәйдәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Казем Җәләлине кабул итте. Илченең Нәзарәткә килүе беренче түгел – ул мөфти белән «Рәсәй – ислам дөньясы: KazanSummit 2021» XII Халыкара икътисади саммиты кысаларында үткән елның җәендә очрашкан иде. Мартта узган очрашуда катнашучылар хезмәттәшлек турында фикер алышты. Татарстандагы дини вәзгыять, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр, танылган татар галимнәре, дини мирас, Иран һәм Татарстан җәмәгатьчелеге өчен якын булган башка мәсьәләләр хакында сөйләште. Иранда һиҗрәтнең 1 гасырына караган кульязма Коръән мосхафлары саклануын исәпкә алып, мөфти илчедән аларның күчермәләрен алу мөмкинлеген сорады. Казем Җәләли Татарстан мөфтиенең үтенечен тыңлап, кулдан килгәннең барысын да эшләргә һәм рәсми җавап бирергә вәгъдә бирде. Әлеге бай мирас Нәзарәт һәм мөфти тарафыннан кульязма мосхафларны өйрәнүдә кыйммәтле чыганак буларак файдаланылачак.

## 2022 ел башыннан Нәзарәт 250дән артык кешегә гомрә кылуны оештырды

Татарстанның «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми хаҗ-операторы 2022 елның 1 нче гыйнварыннан алып 250дән артык мөселман дин кардәшебез өчен гомрә кылуны оештырды. Алар өчен гамәл-гыйбадәтләрне Хәнәфи

мәзһәбе буенча башкару оештырылды, шулай ук татар гореф-гадәтләренә нигезләнеп, авыз ачу мәҗлесләре, корбан ашлары үткәрелде.

Изге Мәккә һәм Мәдинә җирләренә «Спутник V» вакцинасын ясатып чыгарга рөхсәт алу 2021 ел ахырында Татарстан Президентының Согуд Гарәбстанына эшлекле сәфәре вакытында алып барылган сөйләшүләр нәтиҗәсендә ирешелде.

## Нәзарәтнең «Ислам. Беренче адымнар» проектының тугызынчы сезоны башланды

Шәгъбан аеның 9 нчы көнендә (12 нче мартта) Татарстан мөфтиятенең халык арасында зур популярлык казанган проекты – «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе үз эшен кабат башлап җибәрде. Әлеге проект кыска вакыт эчендә Ислам нигезләрен үзләштереп, намаз укырга өйрәнүне максат иткән чара. Курсларда «Кереш дәрес» (терминология, Ислам динендә рөхсәт ителгән һәм тыелган гамәлләр, тәһарәт), «Намаз дәресе» (намаз уку тәртибе, намазда укыла торган сүрәләр һәм догалар), «Исламның төп баганалары» (ураза, зәкят, хаҗ), «Гакыйдә дәресе» (иманның төп баганалары) кебек дәресләр укытыла. Дәресләрне мөфтият белгечләре һәм хәзрәтләр бирә.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты мөфтият тарафыннан 2018 елда дәгъват эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла башлады. Сигез сезон дәвамында әлеге курсларда 750 кеше белем алды һәм намазга басты.

## Мөфти, 2022 елда Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр башкаласы буларак, Казанның инаугурациясендә катнашты

15 нче мартта Мәскәүдә, Рәсәй Тышкы эшләр министрлыгының Кабул итүләр йортында 2022 елда Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшь-

ләр башкаласы буларак Казан шәһәре инаугурациясе узды. Чарада Рәсәй Федерациясе Тышкы эшләр министры Сергей Лавров, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка рәсми затлар катнашты. Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләренең Яшьләр башкаласы – шәһәргә бер елга бирелә торган статус, аның дәвамында җиңүче шәһәр яшьләрнең икътисади, социаль һәм сәяси активлыгын үстерү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне күрсәтү мөмкинлеге ала. 2021 ел ахырында Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр форумы Идарәсе утырышында Казан шәһәренә «Яшьләр башкаласы – 2022» статусын бирү турында карар кабул ителгән иде.

# Тарих

# Ислам диненең таралуы

## Ислам дине бүгенге дөньяда

2022 ел Татарстан һәм Рәсәй тарихына олы вакыйга буларак кереп калачак. Моннан 1100 ел элек, 922 елның 21 маенда, Рәсәй Федерациясендә яшәүче татарларның болгар бабалары, Ислам динен рәсми рәвештә кабул итеп, югары үскән мөселман цивилизациясенең бер өлешенә әверелде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында ук гарәпләр белән күрше халыкларга тарала башлаган Ислам динен бүгенге көндә дөньяның 120 дәүләтендә яшәп ятучы 2 миллиардка якын кеше тота. Дөнья халкының чиреге, 25% ка якыны – мөселманнар дигән сүз бу! 28 илдә (Согуд Гарәбстаны, Мисыр, Марокко, Иран, Ирак, Күвәйт, Пакыстан һ.б.) Ислам дәүләт дине буларак кабул ителгән, 35 илнең халкы (Төркия, Урта Азия дәүләтләре, Казахстан, Әзербайҗан һ.б.) башлыча мөселманнардан гыйбарәт.

Ислам динен кабул иткән урта гасыр дәүләтләре тиз арада югары үскән фән һәм мәдәният үзәкләренә әвереләләр. Фәлсәфә, дин белеме, тыйб (медицина), математика, астрономия кебек дөньяви фәннәр өлкәсендә эшләгән Җәләлетдин Руми, Гомәр Хәйәм, Әл-Фәраби, Ибне Сина, Таҗетдин Болгари, Әл-Хәрәзми, Әл-Бируни, Мәхмүд Кашгарый кебек гарәп, фарсы, болгар галимнәренең фундаменталь хезмәтләре хәзерге фәннәрнең чишмә башын, нигезен тәшкил итә. Мәшһүр галимнәрнең исемнәре бүген дә халык телендә.

## Мөхәммәд пәйгамбәр һәм дөньяда Ислам диненең тарала башлавы

Исламның туган җире – VII гасырда борынгы ыруглык җәмгыятенең таркалуы һәм яңа феодал тәртипләр урнаша башлау чорына кергән

бүгенге Согуд Гарәбстаны. Төрле иҗтимагый катламнар, сәяси фиркалар арасында килеп чыккан кискен каршылыклар белән үрелеп бара торган күчү чоры халыкны үз артыннан ияртеп барырга сәләтле шәхесләрне тудыра.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – әнә шундый шәхесләрнең иң күренеклесе. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирештерелгән Коръәни Кәрим Гарәбстан җирендә таралып утырган күпсанлы, еш кына бер-берсе белән сугышып ятучы кабиләләрне берләштерү көченә ия булган бердәнбер идеологиягә әверелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дәгъваты нәтиҗәсендә кыска гына вакыт эчендә Гарәбстан халкы мәҗүсилектән Исламга күчеп бетә.

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән вакытта уңышлы гына башланып киткән дәгъват эшчәнлеге, аның вафатыннан соң Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыга. Йөз ел дәвамында көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, көнчыгышта Пакыстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта исә Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны утраулары белән чикләнгән искиткеч зур территорияләр, шул җирләрдә яши торган халыклар Багдад хакимияте астына эләгәләр. Уңышларның нигезе – Коръән идеологиясенең гуманитар асылы, аның гаделлек һәм әхлак нигезләренә корылган тарту көче, дип раслый галимнәр.

## Көнчыгыш Европада Ислам диненең таралуы. Ибне Рөстә

VII гасыр урталарында ук Исламның Көнчыгыш Европага, хәзерге Рәсәй җирләренә үтеп керүе башлана. Төньяк Кавказ (бүгенге Дагыстан) территориясендә Багдад хәлифәлегенең төп көндәше – халкы яртылаш диярлек болгарлардан торган Хәзәр каһанлыгы. Гарәп-Хәзәр сугышлары

йөз елга якын дәвам итә. 737 елда гаскәр башлыгы һәм булачак хәлифә Мәрван бине Мөхәммәдкә Хәзәр каһаны белән солых килешүе төзергә туры килә. Шартнамә буенча Хәзәр каһаны, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән, болгарларның да бер өлеше, җиңүчеләр динен кабул итәләр.

Билгеле булганча, болгарларның Дон елгасы, Азов диңгезе буйларыннан Урта Иделгә күченеп утырулары VIII гасырда башлана. Аларның бер өлеше инде Ислам динендә булгандыр дип уйларга кирәк, чөнки бу төбәкләрдә соңгы елларда болгарлардан калган мөселман зиратлары ачылды.

Танылган фарсы географы һәм тарихчысы Ибне Рөстә тарафыннан 903-912 елларда язылган «Кадерле кыйммәтләр» исемле энциклопедик хезмәттә мондый юллар бар: «Болгарларның күпчелеге Ислам динен тота, авылларында мәчетләр һәм имамнары-мөәзиннәре булган башлангыч мәктәпләр бар... Аларның киемнәре мөселманнарныкына охшаган, зиратлары да мөселманнарныкы кебек». Бу мәгълүматлар, һичшиксез, IX гасыр чынбарлыгын чагылдыра.

Тагын бер фактны исегезгә төшерәбез: болгар хакиме (әмире) Алмышның 902-908 елларда сугылган көмеш тәңкәләрендә аның мөселманча исеме язылган – Җәгъфәр бине Габдулла. Димәк, ул инде X гасыр башларында ук Ислам диненә күчкән булган.

## Болгар әмиренең Багдад хәлифәсенә язган хаты. Болгарга сәяхәт

921 елның язында Багдадка Габдулла бине Башту җитәкчелегендәге илчелек килеп төшә. Ул ерак Болгардан Җәгъфәр бине Габдулла тарафыннан җибәрелгән була. Илче тарафыннан Габбасилар хәлифәсе Әл-Мөкътәдиргә тапшырылган хатында Җәгъфәр бине Габдулла аннан «Ислам диненең кануннарын аңлатучы, аның өчен мәчет төзеп бирүче, аның

(хәлифәнең) Ислам диненә өндәвен халыкка җиткерү өчен аңа, Болгар патшасына, мөнбәр торгызучы кешеләр җибәрүен сораган, һәм ул, Болгар патшасы, дошман патшалардан саклансын өчен хәлифәдән кальга (крепость) төзеп бирүен үтенгән. Хәлифә исә, ул нәрсә сораса, шуңа ризалык бирә».

921 елның 21 нче июнендә Багдадтан Идел Болгарына Сусан Әр-Расси һәм аның сәркатибе Әхмәт бине Фадлан җитәкчелегендә зур кәрван-илчелек чыгып китә. Юл Хамадан, Рей, Нишапур, Мәрв һәм Бохара аша Хәрәземгә кадәр дәвам итә. Аннан соң кәрван зур кыенлык белән ярымчүлле Устюрт яссылыгын кичеп үтә һәм Җаек елгасына килеп чыга. Ибне Фадлан болай дип искә ала:

«Без болгарлар патшасыннан бер көн һәм бер төн ара ераклыгында булганда безне каршылау өчен ул үзенең хакимиятенә буйсынган дүрт патшаны, үзенең ир туганнарын һәм улларын җибәргән. Алар безне каршыладылар... Һәм без болгарлар патшасыннан ике фәрсах ара ераклыгында булганда, ул безне үзе каршылады, безне күргәч, атыннан төште, бөек һәм кодрәтле Аллаһыга табынып, рәхмәтләрен белдереп, йөзтүбән егылды. Аның җиң эчендә дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безгә сипте. Ул безнең өчен чатырлар кордырды һәм безне аларда урнаштырды. Безнең аның янына килеп җитүебез – өч йөз унынчы ел мөхәррам аеның уникенче төне үткәч, якшәмбе көнне булды» (хәзерге календарь буенча 922 елның 17 маена туры килә).

## Болгар тарихында 922 ел: Ислам динен рәсмиләштерү

Багдадтан килгән илчеләр якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә юрталарында калалар, илнең башка төбәкләреннән бәкләр, олы бәйрәмгә чакырулы кунаклар килеп җиткәнче ял итәләр. Пәнҗешәмбе көнне барысы да Багдад хәлифәсенең хатын уку һәм

бүләкләр тапшыру тантанасына җыелалар. Ул тантаналар турында илчелек сәркатибе Әхмәт бине Фадлан болай дип искә ала:

«Халык җыелгач, без үзебез белән алган байракларны җәеп җибәрдек, Болгар патшасына җибәрелгән ияр белән атны иярләдек, Болгар патшасын кара киемнәргә киендердек һәм башына чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул торып басты, аның шунда булган күренекле кешеләре дә торып бастылар. Мин укый башладым һәм «Сиңа тынычлык булсын! Сиңа мөрәҗәгать итеп, Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бүтән бөек көч юк» дигән сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Ул һәм мәйданга җыелган кешеләр барысы да бергәләп җавап бирделәр. Һәм без хатны укып бетергәч, алар «Аллаһү әкбәр!» сүзен кычкырып әйттеләр. Җир яңгырап торды.

Мин шунда вәзир Хәмид бине Әл-Габбасның һәм Нәзир Әл-Харәминең хатларын укый башладым. Хат укуны тәмамлагач, Болгар патшасының иярченнәре аңа бик күп дирһәмнәр чәчтеләр. Аннан соң мин хуш исле нәрсәләрдән, аның өчен һәм аның хатыны өчен булган киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым... Аннан соң мин аның хатынына бүләкләр тапшырдым. Хатын-кызлар аңа да дирһәмнәр чәчтеләр».

Кич белән Багдадтан килгән мәртәбәле кунаклар хөрмәтенә тантаналы аш үткәрелә. Шулай итеп, Багдад хәлифәсе илчелеге программасының мөһим өлеше – Болгар дәүләтендә рәсми дин буларак Исламны канунлаштыру тәмамлана. Болгар иле урта гасыр ислам цивилизациясенең иң төньякта урнашкан өлкәсе булып таныла.

## Биләр һәм аның Җәмигъ мәчете

Болгар әмире Җәгъфәр бине Габдулланың Багдад хәлифәсенә язылган һәм хәлифә тарафыннан ярдәм итәргә вәгъдә бирелгән тагын бер бик

мөһим мәсьәләне хәл итәсе кала. Ул да булса, Болгар илен яһүдиләрдән, ягъни хәзәр патшасыннан саклау өчен хәрби ныгытма һәм мәчет төзү белән бәйле эшләр. Билгеле булганча, бу вакытта болгарлар Хәзәр каһанлыгының вассаллары булып торалар. Җәгъфәрнең улы Итилдә тоткынлыкта газап чигә, сөекле кызын җария итеп хәрәмдәге[1] хатыннар янына алып китмәкчеләр…

Хәлифә тарафыннан вәгъдә ителгән акча Багдад илчеләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында килеп җитмәгәч, Җәгъфәр хәрби ныгытманы «үз көмешләренә һәм алтыннарына төзергә» карар кыла һәм Җаушир[2] дип аталган елга янына кузгалып китә. Бирегә, үзләренә буйсынган халыкның бер өлешен, ир затларын алып, кабилә башлыклары да килеп җитәләр.

Галимнәрнең раславынча, Җаушир елгасы буенда болгар төзүчеләре һәм Багдад илчелеге белән килгән шәһәр төзү осталары, Биләр каласына нигез салалар. Эшне хәрби ныгытмалар һәм булачак шәһәр үзәгендә мәчет төзүдән башлыйлар. Әлеге мәчет хәрабәләрен археологлар 1970 елларда ук казып чыгардылар. Ул Идел Болгары дәүләтендә галимнәр тарафыннан өйрәнелгән иң борынгы мәчет.

Биләр берүк вакыт аралыгында барлыкка килгән эчке һәм тышкы шәһәрләрдән тора. Шул тирәдә үк кирпечтән салынган мунча һәм югары катлау кешеләре күмелгән зират урнашкан. Үзенең планировкасы белән ул урта гасырлар Багдадына охшаган. Күрәсең, Биләргә нигез салуда катнашкан Багдад белгечләре интуитив рәвештә булса да үзләренең шәһәр образын күз алдында тотып эш иткәннәр.

*Фаяз Хуҗин,*
*археолог, тарих фәннәре докторы*

1 Хәрәм – гарем.

2 Хәзер бу елганы Кече Чирмешән дип йөртәләр.

# Мирас

# Сәфәрдә ураза, сусау, чәй, су мәсьәләләрендә

Уфадан чыккан көнемдә ифтар итмәдем. Башта бу сәфәрдә ифтар итмәм, уразаның ләззәтен аңлаганлыктан, вакытны ганимәт [икәнен] белеп, уразаны үтәрмен, [дигән] фикердә булсам да, бу көнне авыр үткәрдем. Һава бик кайнар, юлда аз-маз хәрәкәт һәм борчу булганлыктан, хәлсезләндем, хәтта соңгы сәгатьләрне байтак зәгыйфь, авыр хәлдә кояш баю вакытын көтеп каршы алдым. Ифтардан соң һич булмаган микъдарда биш стакан чәй эчтем. Эчсәм дә, чынлап сусау басылмады, салкын суга кызыгып калдым. Чыннан да, чын сусауны басу өчен иң файдалы табигый ширбәт – су. Чәй һәм башка эчемлекләр – ясалма һәм азгынлык эчемлекләре. Хәтта безнең чәйне бал һәм шикәр белән эчү, дөрестән дә, сусау өчен түгел, бәлки, ләззәтләнү өчен. Аеруча бал авыз эсселеге белән сусауны арттыруы мөмкин. Шунлыктан куәтле бал белән эчкәндә күп эчелә. Нәфес теләве белән бал ләззәте өчен балалар кебек вакыт әрәм ителә. Чын сусау вакытында табигать өчен иң файдалы – салкын су. Аллаһының биргән һәм боерган ширбәте – табигатьнең сораган һәм яхшы кабул иткән нәрсәсе. Безнең саф судан бизү, чәйгә өйрәнү – тәрбия белмәгән аналарның тәэсире, үзебезнең дә кирәк белән кирәкмәсне яхшы аера белмәвебездән.

Чәй файдалы эчемлек булса, кирәгенчә булуы шарт. Кирәк вакытлары аштан соңрак аш сеңдерүне җиңеләйтү өчен бер яки ике стакан кадәр, уртача, артык сыек һәм куе булмыйча һәм бик кайнар эчмичә, акрынлык белән эчү тиеш, тәүлектә дүрт-биш стаканнан артык булмаска тиеш. Сусауны басар өчен эчү табигый хәл түгел. Чәйдә сусауны басу хасияте бар, булса да, безнең эчү рәвешенчә эчүдә түгел. Бәлки, суытып, бер-ике чынаяк эчү белән басу кирәктер ки, бераз тәм бирелгән су булып бассын. Бездә гадәт булган кайнарлары, биш-алты чынаяк, бал-шикәр, җиләк кайнат-

малары белән эчүләр – сыйлану өчен эчелгән юл. Чәй шундый әйберләр белән эчелсә, кирәгеннән артык эчелә дә, файдасына [караганда] зарары күбрәк була. Чәйнең табигатендә уяту булганлыктан, әгъзаны сискәндерә, тора-бара адәмне нерв авырулы итә, йокыны качыра. Булган кадәрле йокы чын, яхшы һәм файдалы булмый, йокылы-уяулы бер хәл генә булып кала. Йөрәкне зәгыйфьләндерә, артык чәйгә бирелгән кешеләрдә кинәттән үлү ихтималы арта, кирәгеннән артык канны кайната, газның кирәгеннән артык мигә күтәрелүенә сәбәп булып, башны әйләндерә, хушсызлык-хәлсезлек сәбәбе булу ихтималларын куәтләндерә. Моның өстенә, чәй ашны югалта, карынны тиз ачтыра.

Чәйнең бу хәлләре китапларда күренде, кайбер адәмнәрдә тәҗрибә ителде, үземдә дә кайберләрен тәҗрибә иттем. Ләкин күп еллар өйрәнелгән, гадәт булган, әфьюнгә гадәтләнгән адәм кебек, гадәт ителгән гадәтне алмаштыру авыр, электән һәр бабтагы җитешсез тәрбиям кебек, бу бабта да тәрбиям ким булган. Яман тәэсирләрен күрсәм дә, бөтенләй саклана алмас булганмын, Аллаһ хәерле кылсын! Инде 64-65 яшькә ирешкәч, гадәт үзгәртү, тормыш алмаштыру – авыр эш. Чәйдән аерыла алмаган кеше сөт белән, бәлки, күбрәк салып, шикәр белән эчү тиешле, һәр икесе чәйнең зарарларын азайта, яхшырта.

Су эчү – бик файдалы ширбәт, дидем. Әлбәттә, саф, яхшы су булу тиешле. Аз гына шөбһәле булганда яки төрле авырулар мәйданда булып торган вакытларда кайнатмый эчмәскә кирәк. Кайнау сәбәпле суга катышкан кайбер зарарлы нәрсәләр, агулы 16 хайваннар (микроблар) һәлак булып, файдалы маддәләре генә кала. Кайнаган суны суытып эчү – бик файдалы ширбәт. Кайнар чәйгә гадәтләнгән адәмнәр өчен кайнар су яки аз гына чәй тамызып эчү белән канәгать итәргә тырышу кирәк. Картайганда, йокылар зәгыйфьләнгәндә бу мәсьәләгә бигрәк игътибар итәргә тиешле. Йокы өчен чәй дә, каһвә кебек уятучы булганлыктан, зарарлы. Йокы исә табигатьне һәм сихәтне саклау өчен, иң мөһим Аллаһы тәртибе

һәм чарасы – кешеләрнең табигатьләрендә билгеләнгән гомуми канун. Сөбханәл-мөдәббирел-хәким («Эшнең ахырын Белеп эшләүче, Хикмәт иясе һәр кимчелекләрдән пакь» – А.Г.)!

Чәйнең тәэсире урынның уңайсызлыгы белән төн йокысы бик аз булды. Бер сәгать кадәр булыр-булмас йокы белән үткәреп, сәгать өчтә кузгалып, иртәнге намазны түрдә үтәп, бераз вакыттан соң йокылы-уяулы ике сәгать кадәр ял итү мөмкин булды. Шул хәл белән иртәнге сәгать алтыда Бирски шәһәренә килеп җиттек, урыныбыз аз гына киңәйде. Кайбер бүлмәләр бушаса да, үз җенесләреннән башкага бирердәй булмаганлыктан, ялынмадык, барсына канәгать ихтыяр ителде.

Элек сәфәрләрдә артык муллык һәм рәхәтлек булган, табигать начар өйрәнгән, хәзерге еллардагы рәвешкә бөтенләй каршы яшәлгән. Шуның өчен бу инкыйлаблар иң олуг зарарын һәм яман тәэсирен байларга бирде. Үзләренең ниятләре дә шулай булды. «Буржуй» дип аларга бәла һәм җәфа бабларында олы аерма һәм зур өлеш чыгардылар. Табигый тәртип буенча да шулай булып туды һәм килде. Бу яктан караганда, бер яхшы гыйбрәт булды.

Бу кадәр язгач, хезмәт иптәшебез казый Ризаэддин әфәнденең бер киңәш бирүе һәм ихтыяры хәтеремә килде ки, язуда битнең ярымына гына язуны артык күрә, соңыннан төзәтү өчен калганнарны язу өчен уңайлы була. Бу язуда аны тәҗрибә иттем, онытылып калган сүзләрне язарга урын калмаган икән. Кәгазь кыйммәтлеге булса да, эшнең әһәмияте зур булганга, игътибар ителергә тиешле кагыйдә.

*Галимҗан Барудиның «Хатирә дәфтәре» китабыннан*

# Авыл мөгаллиме

*«Ул кайчагында ястүдән соң бүлмәсеннән чыгып, мәктәпнең залы буйлап йөрenә. Бу вакытта аның фикере вә уйлары әллә кайларга оча, аның күз алдында әллә нихәтле авыллар, әллә нихәтле шундый кыйшайган мәктәпләр вә ул мәктәпләр эчендә дә, моның үзе кебек, җөббәләрен – җәйге пальтоларын, иңсәләренә салган көе парталар арасында йөренеп торган мөгаллимнәр килә. Алар һәммәсе дә тирән фикергә чумган, халыкны ничек ачарга, халыкны аяк өскә бастырырга, халыкны нурландырырга уйлыйлар, алдагы көнне төшенәләр: гали вә мөкатдәс – бөек һәм изге максатка юнәлгәннәр».*

Язучы Шәриф Камалның «Авыл мөгаллиме» хикәясендә шундый өзек бар. Бу хикәя беренче мәртәбә 1910 елда Оренбургта, «Вакыт» газетасының 689 нчы санында басылып чыга. Хикәя заманында бик күп фикерләр язылган, күп матбугат битләрендә күтәрелгән уку-укыту мәсьәләсен чагылдыра.

Язучы Шәриф Камал гомеренең шактый елларын мөгаллимлек, уку-укыту эшләренә багышлаган. «12 яшьтә чагымда мин үзебезнең авылымның (Пенза губернасы Инсар өязе, Пешлә авылы) «иң зур культура көчләре» тигезлегенә күтәрелеп җитә язганмын күрәсең: тагын да югарырак баскычка күтәрелү өчен, зуррак алымлы жиргә баруым кирәклек сизелгән. 1896 елның ноябрь аенда мин шул ук губернаның Саранский өязендәге Ләбәҗә дигән авылга укырга бардым. Ә мондагы «гыйлем» байлыгы минем өчен байтак вакытларга җитәрлек иде әле», – дип яза Ш.Камал истәлекләрендә.

«Мине кемнәр, нәрсәгә өйрәттеләр» дигән мәкаләсе болай тәмамлана: «Бер вакыт Газиз абзый Һиндстан, Мисыр җире, Гарәбстан мәмләкәтләре турында сөйләгәнен ихлас күңелдән тыңлаганнан соң:

– Син кайдан беләсең боларны, Газиз абзый? – дип мин аңа сорау бирдем. Ул серле рәвештә бераз эндәшми торгач:

– Хәзрәткә Кырым йортыннан җәридә килә. Анда һәммә нәрсә язылган. Без аны икәү укыйбыз, – диде.

Мин күзләремне зур итеп ачкан килеш шаккаттым. Кырым йорты кайда ул, җәридә нәрсә соң ул, дип сорарга батырлыгым җитмәде…

Газиз абзыйның «җәридә»гә нигезләнеп сөйләгән ялган катыш ярты-йорты мәгълүматлары мине ерак җирләргә тартты. Минем тәрбияләнү юлларымның бер кисәге шуның белән тәмам булды».

Чыннан да, белем алырга булган омтылышы Шәриф Камалны Истамбулдагы укытучылар әзерли торган Дарүлмөгалиммингә алып килә. 1901-1903 елларда ул биредә дәресләр ала. Соңыннан ул Мисырга – Каһирәгә китә һәм анда бер елдан артык тора. «Дусты Фәйзулла Мөхәммәд белән алар шунда яшәгән татар укытучысы Шәһхе Гыйнаят янына киләләр. Гарәп газетасы редакторы Гали Йосыф, Йосыф Брагый, Мөхәммәд Габдоһе белән аралашалар», – дип яза ул еллар турында Газзи Кашшаф.

1905 елда Рәсәйгә кайткач, Шәриф Камал Петербургта татар мәдрәсәләрендә мөгаллим, «Нур» исемле беренче татар газетасы редакциясенә корректорлык хезмәтенә урнаша һәм шушы газета битләрендә үзенең тәүге әдәби тәҗрибәләрен – мәгърифәтчелек рухында язылган шигырьләрен һәм публицистик мәкаләләрен бастыра.

1907-1910 елларда Шәриф Камал туган авылы Татар Пешләсендә (Мордовиядә) мөгәллимлек итә. Абыйлары Гыйматдин һәм Габдулла белән берлектә алар авылда яңа мәктәп төзетәләр. Мәктәптә, төп укыту программасына өстәп, рус теле укыту, кызларга белем бирү кебек яңалыклар кертәләр. Авылдашлары мөгаллим Шәриф абыйлары хакында зур хөрмәт белән истәлекләр саклый.

1917-1925 елларда Оренбургта яшәгәндә Шәриф Камал шулай ук бик актив рәвештә яңа белем бирү оешмалары эшендә катнаша. 1921 елның

көзендә Оренбургта тәрбиясез калган балалар йортларында эшли, аннан соң Ильич исемендәге мәктәп мөдире, Татар халык мәгарифе институтында – әдәбият укытучысы, тагын да соңрак укыту бүлеге мөдире була. Казанга күчеп килгәч тә ул Татар мәгариф комитетында эшли башлый.

Әмма 1930 еллардан ул бары язучылык белән генә шөгыльләнә, ләкин анда укытучылыкка тартылу теләге саклана. Соңгы елларында ул яшь язучыларга ярдәм күрсәтүче, юнәлеш бирүче, тәҗрибә уртаклашучы, киңәшләр бирүче остаз-укытучы булуын һәрдаим раслап килә. Язучы Гариф Ахуновның түбәндәге сүзләре моңа дәлил булып тора: «... иҗатыбыз формалашкан елларда, эстетик зәвыкларыбыз уянып, дөньяга карашыбыз ныгыган чорда, безнең бердәнбер классигыбыз Шәриф Камал иде». Гомер буе кызыксынып, катнашып, шөгыльләнеп килгән укытучылык эше Шәриф Камалның иҗатында да тормышында да зур урын алып торган һәм бүген дә ул үзенең «Шәкерт», «Авыл мөгаллиме» һәм башка хикәяләре, гомумән, әсәрләре аша үзенең тормыш дәресен дәвам итә кебек.

*Гөлназ Җиһангирова,*
*Татар әдәбияты тарихы музее һәм*
*Ш. Камал мемориаль фатирының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

# Фән

# Әбү Хәнифә – бар заманның мөҗтәһиде

*Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә гыйлемне иң элек пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аннан соң Пәйгамбәребезнең сәхабәләренә тапшырган. Сәхабәләрдән соң әлеге гыйлемнәр аларга иярүчеләргә – табигыйннәргә күчкән. Табигыйннәрдән Әбү Хәнифә рахимәһуллаһига, ә аннан аның укучыларына күчкән. Теләгән кеше моны кабул итә, теләмәгән, каршы килә ала. Хакыйкать хакыйкать булып кала, моңа карап кына ул үзгәрми[1].*

## Куфадагы мәдәниятенең күптөрлелеге

Гомәр радыяллаһу ганһе идарә иткән дәвердә Ислам дөньясының географиясе шактый киңәя. Бик күп яңа шәһәрләр төзелә. Шулай итеп, Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң унҗиде ел үткәч, Басра һәм Куфа кебек зур шәһәрләр үсеп чыга. Гомәр радыяллаһу ганһе бигрәк тә Куфаның төзелешенә нык игътибар бирә. Аның әмеренә буйсынып, гарәп телендә иркен аралаша алган кабиләләр шәһәрнең әйләнә-тирәсенә урнашалар. Гомәр радыяллаһу ганһе Габдулла бине Мәсгудны бу шәһәрнең халкына үз белемнәрен тапшырыр өчен Куфага җибәрә. Куфа шәһәрендә гыйлемнең таралуына Сәгъд бине Әби Вәккас, Хозәйфә, Гаммәр бине Йәсир, Сәлман Әл-Фариси, Әбү Муса Әл-Әшгарый кебек күренекле сәхабәләр дә үз өлешен кертә. Куфа мөселманнарның мәгариф үзәгенә әйләнә. Куфага килгәч, Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу галимнәрнең күплегенә куанып болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә Ибне Мәсгуд белән булсын. Ул бу шәһәрне гыйлем

---

1 Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали Әл-Хатыйб Әл-Багдади – «Тариху Мәдинәти әс-сәлам», Бәйрут, 2001. XV, 460 б.

нуры белән тутырды. Аның укучылары маяк кебек шәһәрне яктырталар»[1].

Ибне Мәсгуд радыяллаһу кебек Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу дә гыйлемгә аз игътибар бирмәгән. Ул халыкка динебезнең нигезләрен өйрәткән. Куфа шәһәре Ислам дәүләтенең башкаласы буларак билгеләнгәч һәм галим сәхабәләр Куфа шәһәренә килеп төпләнгәч, галимнәр, мөхәддисләр, Коръән хафизлар һәм гарәп теле белгечләренең саны буенча Куфага тиңнәр булмаган.[2]

Мөхәммәд бине Рабигъ Әл-Җизи һәм Әс-Суютый Мисыр территориясендә яшәгән галимнәр санын исәпләп, бары тик 300 кешене генә билгеләгәннәр. Әл-Иҗли исә Куфа шәһәрендә генә дә 1500 галим яшәгәнлеген һәм аларның җитмеше Бәдер сугышында катнашканын искә алган.[3]

Сәхабәләрнең тырышлыклары һәм хезмәтләре бәрабәренә Куфа шәһәре тулы бер университетка әйләнгән. Әнәс бине Сирин ул вакыттагы Куфаны тасвирлап, болай дип әйткән: «Куфага килгәч, мин дүрт мең кешенең хәдисләр өйрәнү белән мәшгуль булуын һәм дүрт йөз кешенең фикһ үзләштерүен күрдем»[4]. Мөгаен шуңа да, Өмәвиләр идарә иткән дәвердә, нәкъ менә мәгарифнең чәчәк атуына бәйле, Куфа шәһәре барлык җәбер-золым күргән мөселманнар өчен сыеныр урыннарына әйләнгәндер.

## Гыйлем алу юлында

Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Куфада, галим-сәхабәләр тырышлыгы белән бу шәһәр мәдәният һәм мәгариф үзәгенә әверелгәч, һиҗри буенча 80 нче (70) елда дөньяга килгән. Шулай да, ул вакытка инде аның

1 Әл-Кәүсәри – «Фикһүл-әхлил-Гыйрак вә хәдисәһүм», I, 15 б.

2 Әл-Кәүсәри – «Фикһүл-әхлил-Гыйрак вә хәдисәһүм», I, 15-16 б.

3 Шунда ук.

4 Шунда ук. – 20 б. Әл-Кәүсәри – «Мәкаләт», 132 б.

туган шәһәре үзенең әүвәлге йөзен, чисталыгын югалтырга өлгергән. Иҗтимагый-мәдәни яктан Гыйрак Куфа шәһәренә бик җитди йогынты ясаган. Шуңа да Куфа шәһәрендә шигыйлар, хариҗиләр, могътәзилә һәм башка адашкан агымнар таралган. Шуңа да карамастан, сәхабәләрнең укучылары һәм аларга иярүчеләрнең, бигрәк тә, Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе укучыларының тырышлыгы сәбәпле, Әһле Сөннәт агымы Гыйрак җирлегендә төп рольне уйнаган. Шул рәвешчә, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Ислам дөньясын фетнә колачлаган дәвердә дөньяга килгән.

Иң элек Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи сәүдә эше белән шөгыльләнгән. Вакыт-вакыт дини җыелышларда һәм түгәрәкләрдә катнашкан. Ләкин алар аның таләпләрен бик аз канәгатьләндергән. Кирәк булганда төрле бәхәсләрдә бик актив катнашкан. Әгәр инде бу фәнни җыелышлар барышында үзара фикер каршылыклары туса, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһига адашкан агымнарның тарафдарлары каршында Әһле Сөннәт карашларын якларга туры килгән. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның әлеге төр бәхәсләрдә уңыш казануы шул дәвернең акыл ияләре тарафыннан да хуплау тапкан. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи кебек атаклы кешенең фәнне читкә куеп, сәүдә белән шөгыльләнүенә алар үз канәгатьсезлекләрен белдергәннәр. Барысы да бертавыштан аны галим булырга, фән белән шөгыльләнергә өндәгән. Шул сәбәпле, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның гыйлем юлына басуында Имам Әш-Шәгъбинең исемен дә атап үтәргә кирәк. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Имам Әш-Шәгъбинең үзенә йогынтысы хакында болай дип искә алган: «Бервакыт, базарга барырга чыкканда, Имам Әш-Шәгъби яныннан үтеп бара идем. Ул мине туктатып, болай дип әйтте:

– Әй, Әбү Хәнифә, көн саен син кем янына барасың?

– Мин базарга барам, – дип җавап бирдем.

– Мин бөтенләй дә ул хакта түгел. Кайсы галимнәрнең дәресләренә йөрисең?

– Даими рәвештә мин беркемнең дә дәресләренә йөрмим, бары тик вакыт-вакыт кына.

– Фәнгә бәйле сорауларны тикшер. Галимнәрнең җыелышларына йөрүгә салкын карама, чөнки мин синдә чагыштыргысыз дәрәҗәдә кызыксыну һәм омтылыш сизәм.

Әш-Шәгъбинең бу сүзләре миңа бик нык тәэсир итте. Шуннан соң мин базарны ташладым һәм фән белән шөгыльләнә башладым»[1].

Шуңа карамастан, һәрдаим дини җыелышларга йөрүче булып китсә дә, гәрчә үзе сату эшләре белән шөгыльләнмәсә дә, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи сәүдә эшчәнлеген тулысынча ташламаган. Бу төр эшләрне башкарыр өчен үзенә иптәшләр яллаган. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи вакыт-вакыт алар янына килеп, эшләрен Ислам дине рөхсәт иткәнчә алып баруларын тикшергән.

## Кәлам түгәрәкләре

Гыйлем алу белән шөгыльләнә башлагач, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи һәрбер фәнне ныклап аерым үзләштерергә тотынган. Иң элек ул «нигезләрнең нигезе» булган «нәхү» фәнен үзләштергән, аннары инде бер-бер артлы, барлык фәннәрне өйрәнүдә яхшы дәрәҗәләргә ирешкәнче, башка фәннәрне өйрәнгән.

Куфа мәчетләрендә уку-укыту эшчәнлеге бу вакытта өч юнәлештә алып барылган. Беренче юнәлеш кәлам фәнен өйрәнүне үз эченә алган. Кәлам фәне гакыйдә һәм аңа бәйле сорауларны өйрәнүдән гыйбарәт булган. Икенче юнәлешне дини җыелышлар тәшкил иткән. Аларда хәдисләргә бәйле сораулар каралган. Дини җыелышларның өченче төре фикһ фәнен өйрәнүдән гыйбарәт булган. Анда Коръәни Кәримнең аятьләренә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә

[1] Әл-Мовәффәк бине Әхмәд Әл-Мәкки, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарүл-китабел-гарәби» нәшрияты, Бәйрут, 1981, I, 54 б.

таянып хөкемнәр (карарлар) чыгарылган һәм фәтвалар кабул ителгән.[1]

Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи фән белән шөгыльләнгән ул елларда гакыйдә сорауларына бәйле кызу бәхәсләр һәм низаглар булып торган. Мөселманнар үзара төрле карашларга таянганнар, башка дин вәкилләре белән фикер каршылыклары туган. Шушы хәлләрдән чыгып, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи кәлам фәне дәресләренә йөрүне кулайрак күргән. Шул рәвешле, ул бу юнәлештә билгеле бер дәрәҗәгә ирешкән. Басра шәһәрендә кәлам фәненә бәйле үткәрелгән җитди бәхәсләр аның игътибарын җәлеп иткән. Шулай ук монда төрле дини агымнарның тарафдарларын очратырга мөмкин булган. Ул Басра шәһәрендә якынча егерме тапкыр булган. Ул елларда Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи кәлам фәнен иң мөһим фәннәрнең берсе дип уйлаган. Вакыт үтү белән аның карашлары үзгәргән. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи болай дип фикер йөрткән: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре һәм табигыйннәре безгә билгеле булган барлык сорауларда мәгълүматлы, тирән белемле булганнар. Гыйлемгә бәйле бар нәрсәдә алар көчлерәк һәм аларның хокуклары да күбрәк булган. Шуңа да карамастан, алар кәламгә бәйле бәхәсләргә катнашмаган, киресенчә, аннан читләшкәннәр һәм башкаларга да моны тыйганнар. Күбесенчә алар шәригать һәм фикһка бәйле сораулар хакында фикер алышкан. Дини җыелышлар да нәкъ менә шуның өчен үткәрелгән. Алар шул сорауларны өйрәнү буенча шөгыльләнгәннәр һәм барлык мөселманнарны да шәригать нигезләрен өйрәнүгә чакырганнар. Фәтвалар чыгарылган, мәсьәләләр хәл ителгән»[2]. Шулай да гакыйдәгә бәйле бәхәсләрдә алар теге яки бу якны өстен күрмәгәннәр. Бу күренешләрне шул рәвешле күз алдына китереп, Әбү Хәнифә рахимуллаһиның кәлам фәненә мәхәббәте тора-бара суынган.

[1] Мөхәммәд Әбү Зәһра – «Әбү Хәнифә: Хәятуһу вә әсруһу әрауһу вә фикһуһу», «Дәруль-фикриль-гарәби», Каһирә, 1997, 21 б.

[2] Мөхәммәд Әбү Зәһра – «Әбү Хәнифә: Хәятуһу вә әсруһу әрауһу вә фикһуһу», «Дәруль-фикриль-гарәби», Каһирә, 1997, 23 б.

## Фикһка бәйле җыелышлар

Вакытлар узу белән Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи күбрәк фикһ фәненә тартыла башлаган. Кәлам түгәрәкләрен калдырып, шәригать мәсьәләләре күтәрелгән җыелышларны ул өстенрәк күргән. Фикһ фәнен сайлавына түбәндәге вакыйга зур этәргеч ясаган. Бу вакыйганы Имам Әгъзам рахимәһуллаһиның үз сүзләреннән Зөфәр бине Әл-Хөзәел риваять иткән: «Фикһ буенча дәресләр алып барган Хаммад бине Әби Сөләйман белән бервакытта мин мәчеттә кәлам фәне буенча дәресләр алып бардым. Бервакыт миңа бер хатын-кыз сорау белән мөрәҗәгать итте: «Бер кешенең хатыны бар. Сөннәткә туры китереп ул аның белән аерылырга тели. Ул аңа ничә тапкыр талак әйтергә тиеш?» Мин аның соравына җавапны әйтә алмадым һәм аңа Хаммад янына барырга, аннан сорарга киңәш иттем. Аннан җавап алгач, минем яныма килеп сөйләрсең, дидем. Бу хатын ул сорауны Хаммадка да биргән һәм ул аңа бу рәвешле җавап кайтарган: «Хатыны пакь халәтендә (хәез вакыты булмаганда) ул аңа бер тапкыр талак әйтергә, аның белән җенси мөнәсәбәтләргә кермәскә тиеш. Шуннан соң хатынының ике хәез вакыты үткәнен көтәргә тиеш. Аннан соң хатыны госел алгач, ул башка кешегә кияүгә чыга ала». Теге хатын миңа Хаммадның сүзләрен тапшырды. Шушы хәлдән соң мин үз-үземә: «Минем кәлам фәненә ихтыяҗым юк», – дип әйттем. Аннары сандалларымны алдым да, Хаммадның түгәрәгенә кушылдым. Мин аны бик игътибар белән тыңладым, ул тикшергән сорауларны хәтеремдә калдырырга тырыштым. Аның укучылары арасында мин иң яхшысы идем, шуңа да ул башкаларга болай дип әйтә иде: «Дәрес барышында Әбү Хәнифәдән башка берәү дә минем яныма утырмасын»[1].

*Ихсан Шеноджакның «Абу Ханифа – великий муджтахид» китабыннан тәрҗемә*

[1] Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали Әл-Хатыйб Әл-Багдади – «Тариху Мәдинәти әс-сәлам», Бәйрут, 2001. XV, 456 б.

# Ураза

# Рамазан ае

Рамазан ае – барыбызга да кадерле, хөрмәтле ай. Ул безнең иманыбызны сыный торган ай. Аллаһы Тәгаләгә инанып яшәгән һәр бәндә бу айда ураза тота, гыйбадәтләрен арттыра, мөмкин кадәр күбрәк изгелек эшләргә тырыша.

Шушы мөбарәк Рамазан аенда Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил галәйһиссәлам аша Коръәни Кәримне иңдерә башлаган. Ә Коръәни Кәрим – бәндәләрне һидаятькә күндерә торган, хәләл белән харамны аера торган, ак белән караны, хаклык белән хаксызлыкны аера торган изге китап ул.

«Әгәр дә сез исән-сау булып, Рамазан аен күрсәгез, ураза тотыгыз», – дип Аллаһы Тәгалә Коръән аша мөселманнарга уразаның фарыз икәнлеген белдерә.

## Ураза нәрсә ул?

Уразаны гарәпчә «саум» диләр. Безнеңчә ул тыелып тору дигәнне аңлата.

Нәрсәдән тыелу? Кайберәүләр аны ашау-эчүдән тыелу дип кенә уйлый. Ләкин ураза – ашамый-эчми тору гына түгел. Ураза тоткан кеше барлык бозык эшләрдән, яман сүзләрдән, гайбәттән, кеше арасын бозудан, ялган сөйләүдән, кеше рәнҗетүдән тыелырга тиеш була. «Әгәр берәү ниятләп, уразага керешеп, ашамый-эчми торып та, кеше рәнҗетә торган, мәрхәмәтсезлек, шәфкатьсезлек күрсәтә торган булса, ул кешенең уразасы кабул булуы шикле», – дигән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Ураза – ул тәрбия, күңел тәрбиясе. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең иманыбызны, ихласлыгыбызны ашау-эчүдән тукталып торуыбыз

белән сыный. Башка кешеләр харам ризыклардан, исерткечләрдән тыела алмаган вакытта, без хәләл, рөхсәт ителгән ризыкларны да читкә куеп, ашамый-эчми ай буенча ураза тотабыз. Аллаһы Тәгалә барчабызның да тоткан уразаларыбызны кабул кылсын!

Ураза – ул тәрбиянең иң югары дәрәҗәсе. Элекке елларда әби-бабайларыбыз, бик авыр тормышта булып та, җәйнең иң озын вакытларында, эссе кояш астында көннәр буенча басуда урак урсалар да, ураза тотканнар, эсселеккә түзгәннәр. Ничек кенә сусап, суга тилмерсәләр дә: «Аллаһы Тәгалә кушканны үтибез, Ул бездән риза булса иде», – дип бер тамчы су да йотмаганнар. Менә шушы була инде үзеңне тәрбияләү, шушы була инде имтихан.

Хәзерге вакытта, әлхәмдүлилләһи Раббил галәмин, без ризыкка мохтаҗ түгел. Аллаһы Тәгалә булган ризыктан аермасын, шуңа шөкерана кылып, риза булып яшәргә насыйп итсен.

Шуның өчен Аллаһы Тәгалә Рамазан аен зур имтихан ае итеп яраткан. «Берәү сәламәт вакытында Рамазан аен күрсә, ураза тотсын!» – дигән боерык һәрберебезгә дә кагыла.

## Уразаның кешегә файдасы

Беренчедән, ураза – гыйбадәт. Аллаһы Тәгалә кушкан гамәлләрне түбәнчелек белән үтәп, үзеңне Аның колы икәнлегеңне күрсәтү. Әгәр ул тиешенчә үтәлә икән, Ахирәттә күп савап булачак. Дөнья белән генә эш бетми бит әле, Ахирәт көне, хисап бирә торган көн дә бар. Аллаһы каршысына барып басып, дөньяда яшәгән вакытта кылган эшләребез, гамәлләребез өчен җавап тотасыбыз бар. Ураза тоту – Ахирәткә, үзебезнең киләчәктәге, мәңгелек тормышыбызга изгелек әзерләү дигән сүз.

Икенчедән, ураза тотуның сәламәтлеккә дә файдасы бар. Билгеле булганча, табиблар кайбер авыруларны ач тору белән дәваларга куша. Кешенең барлык гәүдә әгъзалары ялга мохтаҗ. Гомумән, һәрбер

эшләгән кеше елга бер мәртәбә ял итә. Ә безнең ашказаныбызның һич ял иткәне юк. Һәркөнне туктаусыз ашап, аны тутырып торабыз, шуңа күрә ашказанының куәте кими, эшчәнлеге бозыла. Әгәр без көне буе ураза тотсак, ашказаны бераз ял итәргә өлгерәчәк.

Матди яктан да уразаның файдасы бар. Ризык аз күләмдә әзерләнә торган була. Ураза тоту бит ул, көне буе ашамыйча торып, төне буе ашарга дигән сүз түгел. Артык күп ризык куллануның рөхсәте юк. Азык-төлеккә сакчыл караш булырга тиеш. Әгәр без аны сарыф итүгә юл куйсак, кирәгеннән артыгын әзерләсәк, калганын чыгарып түксәк, гөнаһка батачакбыз, Аллаһы сакласын. Ислам динендә андый нәрсәләр кабул ителми.

Ураза адәм баласын тәртипкә, ризыкның кадерен белергә, аңа сакчыл карарга да өйрәтә.

Ураза шулай ук кешеләргә ачлыкның, сусызлыкның нәрсә икәнлеген аңларга өйрәтә. Бүгенге көндә дөнья күләмендә ачлыктан, сусызлыктан интегүчеләр бик күп.

Рамазан ае – шәфкать ае, мохтаҗларга рәхимлелекне арттыра торган ай. Йосыф галәйһиссәлам, үз кулында бөтен илнең байлыгы булса да, туйганчы ашамаган. «Ник туйганчы ашамыйсың син?» – дип сорау биргәч: «Үзем тук булып, ач кешеләрнең хәлен истән чыгарырмын дип куркам», – дип җавап кайтара торган булган.

Әлбәттә, авыр эшләрдә, завод-фабрикаларда, төзелешләрдә эшләгән кешеләргә ураза тоту җиңел түгел. Шулай да адәм баласының күңелендә көчле иман, теләк булса, ураза тотарга көче җитәчәк. Ә инде иманы, теләге көчле булмаса, ихтыяр көчен туплый алмаса, көне буе бернәрсә эшләмичә, йоклап үткәрсә дә, ул кешегә ураза тоту авыр була. Аллаһы Тәгалә безгә көчебез җитмәслек, үти алмаслык гамәл йөкләмәгән. Коръәни Кәримдә: «Адәм баласына бары тик үзе күтәрә алырлык дәрәҗәдәге йөкне генә йөклибез», – диелә. Һәм шулай ук авырлыкларга түзәргә кирәклекне дә искәртеп: «Авырлыклар, кыенлыклар аша гына җиңеллек килә», – дип

Коръәни Кәримдә Раббыбыз безгә аңлата.

Ураза тоткан кешенең акылы нәфесен буйсындыра башлый. Югыйсә, адәм баласының нәфесе, табигате ләззәткә һәм дөньяга бик бирелүчән итеп яратылган. Кешеләрнең кайберләре үзләренең нәфесләренә бирелеп, буйсынып, аңа табыну дәрәҗәсенә килеп җитәләр. Нәфес тәмле ашарга, яхшы киенергә, җенси ләззәтләрдә коенырга кызыктыра. Мал-мөлкәт җыеп, шуларны тупларга, саран булырга өнди. Әлбәттә, дөнья тереклеге өчен алар да кирәк. Әгәр бу теләкләр булмаса, җирдә яшәү дә булмас иде. Ләкин адәм баласы бу теләкләргә ияреп, чиктән чыгып китмәскә тиеш.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Адәм баласының бер тау хәтле малы булса, янә шуның хәтле малны теләр, ике тау кадәр булса, өченчесен теләр», – дигән.

Кеше үзенең рухи һәм ихтыяр көчен арттырып, нәфесен акылына буйсындырырга, акылын нәфескә хуҗа итәргә тиеш. Әгәр киресенчә, нәфесе акылдан өскә чыкса, ул вакытта кеше гәүдә колы булып кала. Адәм баласы хайван кебек ашап, нәсел дәвам итәр өчен генә дөньяга китерелмәгән бит. Бәлки, рухын пакьләп, җир йөзендә изге гамәл белән яшәр өчен, Ахирәткә изгелек әзерләү өчен китерелгән. Моның өчен адәм баласы үз-үзен дәвамлы рәвештә тәрбияләргә тиеш була. Менә бу ураза тоту нәфесебезне тәрбияләү ысулы булып тора да инде. Шулай итеп, ураза гыйбадәте кешедә сабырлык, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияли.

*Илдус хәзрәт Фәизнең «Ураза тәртипләре» китабыннан*

## Сәхәр һәм ифтар

Сәхәр – ураза тотасы көнне таң атканчыга кадәр ашап-эчеп алу. Таң атканчы йокыдан торып сәхәр ашау мөстәхәб булып санала.

Изге Коръәндә әйтелгән: **«Таңның ак җебе [төннең] кара җебеннән аерылганчыга кадәр ашагыз, эчегез, моннан соң кичкә кадәр ураза тотыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:187

Сәхәрне кичтән түгел, ә нәкъ менә таң атуның беренче билгеләре күренә башлар алдыннан ашасаң яхшы була, чөнки бу очракта аның савабы күбрәк. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә болай дип әйткән: «Сәхәрдә ашагыз һәм, шул рәвешле, ураза тотар өчен үзегезне ныгытыгыз. Көндез йоклап алыгыз – бу сезгә төнлә белән тәһәҗҗөд намазына торырга ярдәм итәр»[1]. «Таң атканчы ашагыз, чөнки монда бәрәкәт бар»[2].

**Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:**

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

«Нәвәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләлмәгъриби хаалисан лилләәһи тәгааләә».

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».

Исламның бөек галимнәре болай дигәннәр: «Кем Рамазан аенда, ашарга рөхсәт ителгән сәгатьләрдә бераз ач калса, шул бөтен ел буена, киләсе Рамазанга кадәр шәйтанның яманлыгыннан сакланган хәлдә була».

1 Имам Ибне Мәҗе, «Сыям», 22.

2 Имам Бохари, «Саум», 20; имам Әл-Мөслим, «Сыям», 45.

Үз көнен гыйбадәттә, ураза тотып үткәргән мөэмин кешегә ифтар берни белән чагыштырып булмаслык шатлык, Ахирәттә әҗер-савап китерә. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Ураза тоткан мөселман өчен ике төрле шатлык бар: берсе – ифтар вакытында, икенчесе – Аллаһының хозурына килеп баскан вакытта»[1].

«Ураза тотучыны ашаткан кеше алачак савап ураза тотучының савабына тиң була, әмма аның савабын да һич кенә дә киметми»[2].

«Берегез ифтар кылса, хөрмә белән авыз ачсын, чөнки анда бәрәкәт бар. Инде хөрмә тапмасагыз, су белән авыз ачыгыз, чөнки ул чиста була»[3].

**Ифтар вакытында авыз ачканда укыла торган дога:**

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِي
يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

«Аллааһүммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәрү мәә каддәмтү вә мәә әххартү».

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй, гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

## Уразаны бозмый торган хәлләр

Онытканлык белән ашау-эчү (җенси якынлык кылу). Әгәр кеше үзенең ураза тотканлыгын исенә төшерү белән ашау-эчүне туктатып, авызына капкан ризыкны чайкап чыгарса, уразасы дәвам итә. Әгәр ура-

1 Имам Әл-Бохари, «Саум», 20; имам Әл-Мөслим, «Сыям», 163.

2 Имам Әт-Тирмизи, «Саум», 81.

3 Имам Әт-Тирмизи, «Зәкят», 26; имам Әбү Давыд «Саум», 21.

за тотканын исенә төшергәннән соң капкан ризыгын йотып җибәрергә өлгерсә, уразасы бозыла. Түбәндәге хәлләр уразаны бозмый:

1. Колакка су элəгү.
2. Күзгә дару тамызу.
3. Ураза тоткан вакытта су коену.
4. Үзең махсус косарга теләмәгәндә косып җибәрү.
5. Йоклаганда үзлегеннән мәни чыгу (поллюция).
6. Кан бирү.
7. Ялгыш кына тамакка тузан яки төтен элəгү.
8. Төкерекне йоту.

## Ураза вакытында эшләнүе мәкруһ булган гамәлләр

1. Нәрсәнең дә булса тәмен татып карау (йотмыйча гына).
2. Авызга тулган төкерекне йотып җибәрү.
3. Кешене хәлсезләтерлек дәрәҗәдә күп тапкыр кан бирү.
4. Интектергеч эш.

## Ураза вакытында эшләнүе мәкруһ булмаган эшләр

Шуларны эшләү тыелмый:

1. Ислемай иснәү яки куллану.
2. Мисвәк яки теш щеткасы кулланып теш чистарту.
3. Авызны чайкау.
4. Борын эчен чайкау.
5. Юыну.

## Уразаны боза торган, әмма каза уразасын гына таләп итә торган хәлләр

1. Ашарга яраксыз нәрсәләрне йоту (кәгазь, туфрак, мамык кебек).

2. Борынга дару тамызу.

3. Суны очраклы рәвештә йоту, мәсәлән, авызны яки борынны чайкаганда.

4. Авызда тупланган төкерекне йотканда, аңа катнашкан чит нәрсәләрне дә йоту.

5. Уразаны бозарга мәҗбүр булганда.

6. Йоклаган кешенең тамагына башка берәү су агызганда.

7. Үз-үзеңне мәҗбүр итеп коскан чакта авызны тутырып косу.

8. Ялгышып, вакытыннан алда авыз ачу (ахшам намазының вакыты керде дип уйлап).

9. Сәхәр вакыты чыкканнан соң ялгышлык белән ризык ашау (әле таң атмады дип уйлап).

## Уразаны боза торган һәм каза уразасы белән кәффарәтне үтәүне таләп итә торган хәлләр

Әгәр Рамазан аенда ураза тоткан кеше шул эшләрнең берәрсен белә торып һәм гозерсез эшли калса:

– ашаса, эчсә яки дару капса (таблетка яки сыеклык);

– женси якынлык кылса;

– тәмәке тартса,

аңа бозылган уразасын каза итеп, көнен көнгә тутырып тотарга кирәк була һәм ул кәффарәт үтәргә тиеш. Кәффарәт – Рамазан ае уразасын белә торып бозган өчен бу дөньяда бирелгән җәза. Рамазан ае уразасыннан тыш башка уразаларны бозган өчен кәффарәт үтәлми.

Кәффарәт рәттән 60 көн ураза тотудан тора. Әгәр кәффарәт өзелсә, яңабаштан 60 көнлек ураза тотарга кирәк. Кәффарәт уразасы тоткан хатыннар хәез көннәрендә аны туктатып торалар һәм бу көннәр тәмамлангач, яңадан дәвам иттерәләр.

Әгәр кеше җитди сәбәп белән 60 көнлек уразаны тота алмый икән, 60 фәкыйрь мөселманның тамагын туйдырырга (иртәнге һәм кичке аш ашатырга) тиешләр (тәкъвалы мөселманнарны тапсаң яхшырак була). Динсез кешеләргә кәффарәт бирелми. Ризык җитәрлек күләмдә һәм сыйфатлы булырга тиеш (мәсәлән, бодай икмәге). Бер фәкыйрьгә 120 тапкыр иртәнге аш яисә кичке ашны ашатырга мөмкин. Яисә 60 кешегә иртәнге аш, 60 кешегә кичке ашны ашатсаң ярый.

Бирелергә тиешле ризыкның бәясен акчалата бирергә дә була. Бер фәкыйрьгә 60 көн буе яисә 60 кешегә бер көндә бирсәң була. Әгәр бөтен сумманы бер көндә бер кешегә генә бирсәң, бер көнлек кәффарәт кенә булып санала.

Әгәр кеше бер Рамазан аенда берничә тапкыр уразасын белә торып бозса (яки берничә Рамазан аенда уразасын белә торып бозса), бөтен очраклар өчен бер кәффарәт бирсә җитә.

## Фидия

Ураза тотарлык хәле булмаган озак авырган кешеләр һәм бик олы яшьтәге кешеләр уразаның төшереп калдырылган һәр көне өчен фидия түли.

Фидиянең күләме нәкъ фитыр садакасы шикелле хисаплана. Фидияне Рамазан аеның башында да, уртасында һәм ахырында да бирергә була.

Фидияне үзең теләгәнчә бер генә фәкыйрь кешегә бирергә яисә берничә кешегә таратырга да мөмкин.

Әгәр мөселман кешесенең фидия өләшергә көченнән килми икән, ул вакытта Аллаһыдан гафу итүен сорарга тиеш.

Әгәр озак авырган кеше инде тазарса, яисә карт кешегә уразасын тотарлык көч-хәл керсә, алар калдырган көннәре өчен уразаны каза итеп тотарга бурычлы. Әлеге очракта бирелгән фидияләре садака булып санала.

## Фитыр садакасы

Бәйрәм көне җиткәндә бурычлары булмаган һәм нисабка ия булган мөселман кешесе өчен фитыр садакасын бирү вәҗиб булып санала. Фитыр садакасы бирер өчен мал-мөлкәткә тулы ел буе хуҗа булырга яки арта барган мал-мөлкәт булырга тиеш дигән шарт куелмый.

Фитыр садакасын Рамазан аенда өләшәләр, моның өчен иң хәерле вакыт – Рамазан гаете көнне бәйрәм намазына кадәр. Хәлле мөселман өчен фитыр садакасын үзе өчен дә, балигъ булган балалары өчен дә бирү вәҗиб хөкемендә. Гадәттә, фитыр садакасы итеп түбәндәге азык-төлек төрләренең берәрсе билгеле бер күләмдә бирелә:

1. Бодай – 1,6 кг.
2. Солы – 3,2 кг.
3. Йөзем – 3,2 кг.
4. Хөрмә – 3,2 кг.

Фитыр садакасын азык-төлек белән дә, шуның бәясе кадәр итеп акчалата да бирергә була. Мохтаҗ кешегә күбрәк файда китерә торган нәрсәне садака итеп бирсәң хәерлерәк. Фитыр садакасы бүлеп өләшенми, күләме зур булмавы сәбәпле, аны бары тик бер кешегә бирәләр. Бер фәкыйрьгә бердән артык фитыр садакасы бирергә була. Фитыр садакасын биргәндә аның бирүең турында ният ителә һәм ишетелерлек итеп әйтү шарт түгел. Нисаб микъдарында мал-мөлкәте яки акчасы булган һәм Рамазан аенда ураза тотмаган кеше шулай ук фитыр садакасы бирергә тиеш була.

Бәйрәм көнендә фитыр садакасы таратып, бай мөселманнар фәкыйрьләрне сөендерә. Фитыр садакасын бирү, мөэминнең тоткан

уразасы кабул ителүгә сәбәп була, аны газаплы үлемнән һәм кабер газабыннан коткара.

*«Ислам дине нигезләре» китабыннан*

***

Татарстан мөфтияте Казыйлар шурасы 2022 елга нисаб, фитыр һәм фидия садакалары күләмнәрен түбәндәгечә билгеләде: зәкят түләү өчен нисаб күләме – 620 000 сум (алтын буенча). Фитыр садакасы түләү өчен нисаб күләме – 58 000 сум (көмеш буенча), фитыр садакасының минималь күләме – 150 сум, ә зәкят чыгару мөмкинлеге булганнарга 800 сум итеп түләргә тәкъдим ителә. Моннан тыш, сәламәтлек торышына бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлегенә ия булмаган һәм аны башка вакытта да каза кылып үти алмаучылар өчен тотылмый калган һәрбер көн өчен 300 сум күләмендә фидия билгеләнде.

# Тәрбия

# Әдәпләр

Безне иң камил рәвештә яраткан, күркәм тәрбия биргән һәм, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне җибәреп, безгә карата Үзенең рәхмәтен белдергән Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар булсын!

Иң югары әхлак үрнәге булып һәм кылырга мөмкин булган иң күркәм һәм бәя биреп бетергесез гамәл булып дини тормышыбызда әдәпләрне үтәү, галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә буйсыну һәм пәйгамбәрләр холкына хас изге гамәлләр кылу тора.

Коръәни Кәрим һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте аша Аллаһы Тәгалә безгә әдәпләрне өйрәткән. Аллаһы Тәгаләгә мактау булсын! Сәхабәләр, табигыйннәр һәм башка изге гамәл кылучы затлар үрнәге мисалында без иң күркәм әхлакның нинди булырга тиешлеген күрә алабыз. Әлеге Коръән, Сөннәт һәм башка күркәм әхлак мисаллары бәяләп бетергесез зур кыйммәткә ия, һәм алар бик күп. Без шуларның кайберләрен, бик аз өлешен генә исәпкә алырбыз.

## 1. Мөэминнең Аллаһы Тәгалә каршындагы әдәпләре

– Башны һәрвакыт алга таба иелгән килеш тотарга
– Фикерләреңне бергә тупларга
– Дәшмәскә яки аз сөйләшергә
– Кирәк булмаган хәрәкәтләр ясамаска, тыныч булырга
– Әмерләрне үтәргә тырышырга
– Тыелганнардан читләшергә
– Артык каршы килмәскә
– Күркәм әхлакка ия булырга
– Һәрвакыт зикердә булырга, Аллаһы Тәгаләне истән чыгармаска

– Йөрәкне начар уйлардан пакьләргә

– Әгъзаларны сакларга

– Җан тынычлыгын сакларга

– Аллаһы Тәгаләне зурларга

– Үпкә сакламаска

– Яраткан нәрсәне сер итеп сакларга

– Һәрчак ихлас булырга

– Һәрвакыт хакыйкать яклы булырга

– Кешеләргә таянмаска

– Гамәлләр кылуда ихлас булырга

– Ширек кылмаска һәм икейөзлелектән сакланырга

– Гадел (дөрес) булырга

– Аллаһыга якынайта торган гамәлләр кылырга

– Артык кул хәрәкәтләре ясамаска

– Тыелган гамәлләр кылынганны күргәндә ачуланырга

– Һәрвакыт тәкъва булып калырга

– Оялчан булырга

– Курку белән өмет арасындагы халәттә булырга, ягъни Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткәннәргә ышанырга

– Аллаһы Тәгаләнең аның өчен иң яхшысын насыйп итәчәген тәгаен белеп, һәрнәрсәдә Аңа тәвәккәл кылырга

– Бер намазны мәчеттә кылганнан соң, киләсе намазның вакыты керүен көтеп алырга

– Фарыз намазны калдырудан куркып сискәнергә

– «Бәлки мин берәр гөнаһта даимчелек кылам» дип куркып, һәрчак тәүбәдә булырга

– Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләре аркылы хәбәр иткән һәм биш сизү-тоемлау әгъзалары ярдәмендә тоеп булмый торган нәрсәләрнең хаклыгына иман китерергә

– Аллаһы Тәгаләне искә алганда сискәнеп куярга

– Нәсыйхәт һәм киңәшләргә колак салырга

– Мохтаҗ вакытта Аллаһыга тәвәккәл кылырга

– Саран булмаска һәм мөмкинлек булганда садака бирергә

## 2. Галим кешенең әдәпләре

– Гыйлем алуны дәвам итәргә

– Алган гыйлеменә туры килгәнчә гамәл кылырга

– Тәкъва булырга

– Тәкәбберлек күрсәтмәскә

– Шәкертләргә карата ягымлы һәм ачык йөзле булырга

– Тырыш укучыларның хәленә керергә

– Аңлаткан вакытта дәресне авыр кабул итүче шәкертләргә гадиләштереп аңлатырга

– «Белмим» дигән сүздән курыкмаска

– Сорауларга җавап биргәндә һәм дәрес аңлатканда иң җиңел ысулларны сайларга

– Каршы чыгуларны исәпкә алырга, гәрчә алар капма-каршы фикердә булучы тарафыннан әйтелсә дә, аның дәлилләрен танырга

## 3. Шәкертнең остазына карата әдәпләре

– Беренче чиратта, остазга һәрвакыт сәлам бирергә

– Остаз янында азрак сөйләшергә

– Остаз утырган җиреннән торганда, торып басарга

– «Фәлән галим бөтенләй башкача әйтә», – кебек сүзләрне беркайчан да әйтмәскә

– Янында утырган сабакташка сораулар бирмәскә

– Остаз белән сөйләшкән вакытта көлмәскә

– Остазның фикерләренә каршы килгән фикерләргә ишарә итмәскә

– Остаз утырган җиреннән торып басканда, аның киеменә тотынмаска

– Дәрестән соң өйгә кайтканда остазга сораулар бирмәскә

– Дәрес вакытында остаз арыса, дәресне дәвам иттерүне сорамаска

## 4. Коръән өйрәтүченең әдәпләре

– Тәкъва һәм җитди кыяфәт белән утырырга

– Шәкертләрнең укуын тыңларга

– Аңлар өчен, сөйләшмәскә

– Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итәргә

– Охшаш (ясалышы ягыннан якын) хәрефләрнең әйтелешенә игътибар итәргә

– Коръән укыган вакытта вакыф (туктау) урыннарын шәкертләргә төгәлрәк әйтеп барырга

– Укуны туктатканда, укуны дәвам иттерүнең тәртипләрен аңлатырга

– Саннарны өйрәтергә

– Тәҗвид һәм авазларның дөрес әйтелешен өйрәтергә

– Хатем чыгу (Коръәнне тулысынча уку) фазыйләтләрен һәм хатем чыкканнан соң үтәлергә тиешле гамәлләрнең тәртибен аңлатырга

– Күптән түгел генә Коръән укый башлаган шәкертләрне аңлап, аларга карата йомшак мөгамәләдә булырга

– Шәкерт дәрескә килмәгәндә, дәрес калдыруының һәрвакыт сәбәбен сорарга

– Әлеге шәкерт дәрескә килгәч, аны укырга өндәргә

– Аз сөйләшергә

– Шәкертләргә намазда укыла торган аять-сүрәләрне яки алар имам булгач укырга кирәк булачак сүрәләрне ятлатырга

*Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Газалиның «Әдәпләр» китабыннан*

# Тәфсир

# Муса һәм Хозыр галәйһиссәлам кыйссасы

Бервакыт Муса галәйһиссәлам Исраиллеләрнең улларына вәгазь укыгач, аннан сораганнар:

– Кешеләр арасында кайсысы иң күп белүче?

– Мин, – дип бер шикләнмичә җавап биргән Муса галәйһиссәлам.

Мондый җавабы өчен Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәрне шелтәләгән:

– Ий Муса! Син үзеңне иң күп белүче кеше дип саныйсың, әмма ике диңгез кушылган урында минем бер колым бар, мин аны сиңа караганда тирәнрәк белемнәр белән зиннәтләдем.

Муса галәйһиссәлам Рәхимле Заттан шушы кол белән күрешергә мөмкинлек бирүен сораган:

– Ий минем Раббым! Миңа Синең әлеге колыңны ничек табарга?

Аллаһы Тәгалә аның үтенечен кире какмаган:

– Үзең белән балык ал һәм аны букчаңа сал. Бер җирдә бу балыкка җан кереп, ул синең күзеңнән югалыр, син әлеге кешене очрата торган урын шул булыр.

Аллаһының әмеренә буйсынып Муса галәйһиссәлам юлга кузгалган. Бертуганының улы Юша бине Нунны үзенә юлдашчы итеп алган.

Шактый озын юл узгач алар зур кыя астына ял итәргә утырганнар һәм, Аллаһы Тәгалә әйткән җиргә барып җиткәннәрен дә аңламыйча, талчыгып йоклап киткәннәр. Әлеге кыя астында «тере су» дип аталган чыганак булган. Сәяхәтчеләр йоклаган арада, шул суның чәчрәгән тамчылары Муса галәйһиссәламдәге балыкны терелткән. Балык аның букчасыннан сикереп чыгып диңгезгә йөзеп киткән. Юша бине Нун бу гаҗәеп вакыйганың шаһите булган, әмма ул бу хакта Муса галәйһиссәламгә сөйләргә оныткан.

Алар юлларын дәвам иткәннәр. Тагын шактый ерак ара узгач, алар ачыкканнар, һәм Муса галәйһиссәлам үзенең яшь юлдашына үзләре белән алып килгән ризыкны китерергә кушкан. Билгеле, теге балыктан башка аларның башка ризыклары булмаган. Шуннан соң Юша бине Нун болай дип әйткән:

– Кыя астында без ялга туктаган урында букчада булган балыкка җан керде һәм ул аннан сикереп чыгып диңгезгә йөзеп китте. Ләкин мин сиңа бу хакта әйтергә онытканмын.

– Димәк, ул безгә кирәкле урын булган! – дип әйткән Муса галәйһиссәлам һәм алар янәдән чишмә янына килгәннәр.

Монда алар үз киеменә төренеп яткан бер кешене күргәннәр. Шулкадәр ерак юлны Муса галәйһиссәлам һәм аның юлдашы шушы зат – Хозыр галәйһиссәлам белән күрешү өчен узганнар икән!

Муса галәйһиссәлам Хозыр галәйһиссәламгә сәлам биргән һәм үзе белән таныштырган. Хозыр галәйһиссәлам аннан болай дип сораган:

– Исраиллеләр улларыннан булган Муса син буласыңмы инде?

Муса галәйһиссәлам аңа болай дип җавап биргән:

– Әйе! Аллаһы Тәгалә сиңа биргән гыйлемнең бер кыйсеме белән мине дә бүләкләсәң иде.

– Әйе. Аллаһы Тәгалә мине сиңа билгеле булмаган белемнәр биреп зиннәтләде. Һичшиксез, син дә миңа билгеле булмаган белемнәргә ия. Ләкин белмәгән гыйлемне миннән алырга синең түземлегең җитмәс.

Муса галәйһиссәлам сабыр гына тыңларга һәм аңа каршы килмәскә вәгъдә биргән:

– ИншәАллаһ, син мине түземлеләрнең берсе буларак белерсең. Мин синең барлык әйткәннәреңне дә тыңлармын.

– Моннан тыш, барысын да сөйләп бетергәнче, син миңа бернинди сораулар бирергә тиеш түгелсең.

Алар шулай килешкәннәр дә, бергәләп диңгез яры буйлап киткәннәр. Су буенда корабны күреп, юлчылар юлларын корабта дәвам итәләр. Кораб ерак араны йөзеп үткәч, Хозыр галәйһиссәлам Муса галәйһиссәламне бик нык гаҗәпкә калдырган: ул балта алып, кораб төбенә тишек ясаган. Муса галәйһиссәлам әлеге гамәлнең яшерен мәгънәсен аңламаган хәлдә, бу хәлне тыныч кына күзәтә алмаган. Ул Хозыр галәйһиссәламнән болай дип сораган: «Кораб башлыгы безгә карата игелек күрсәтте, безне үзләре белән түләүсез алды, шулай булгач корабны тишәргә мөмкинме инде?»

– Мин бит сине минем белән сәяхәт итәргә түземлегең һәм чыдамлыгың җитмәячәге хакында кисәттем, – дип җавап биргән Хозыр галәйһиссәлам. Муса галәйһиссәлам дәшмәскә һәм артык сораулар бирмәскә дигән вәгъдәсе хакында онытуын таныган һәм бу хәл башка кабатланмас дип ышандырган.

Ярга чыгып, юлларын җәяү дәвам иткәч, алар дуслары белән уйнаган малайны очратканнар. Хозыр галәйһиссәлам бу малайны һәлак иткән. Әлеге күренешне күреп, Муса галәйһиссәлам кычкырып җибәргән:

– Син нәрсә эшләдең? Син нигә бер гаепсез баланы һәлак иттең?

Хозыр галәйһиссәлам: «Минем янымда торырга синең түземлегең җитмәс дип әйтмәдеммени мин сиңа? Син бит миннән бернәрсә турында да сорамаска вәгъдә бирдең!» – дип әйткән.

Муса галәйһиссәлам янәдән гафу үтенгән.

Шулай итеп, алар сәяхәт кылуны дәвам иткәннәр һәм бер авылга килеп җиткәннәр. Алар бик нык ачыкканнар, чөнки үзләре белән ашарларына бернинди дә ризыклары булмаган һәм алар авыл халкыннан ашарга сораганнар. Әмма авыл кешеләренең берсе дә аларга ашарларына ризык та, йокларга почмак та бирмәгән. Ач һәм арыган хәлдә алар бу авылдан китәргә мәҗбүр булганнар. Авыл читенә җиткәч, алар ишелеп барган таш диварны күргәннәр. Хозыр галәйһиссәлам дивар янына килеп төзәтә башлагач, дивар янәдән төз һәм тигез рәвешкә кергән. Боларның бары-

сын да күреп, Муса галәйһиссәлам гаҗәпләнеп болай дип әйткән:

– Бу авыл кешеләренең берсе дә безгә бер сынык ипи дә бирмәде, безне үзләренең өйләренә кертмәде, ә син аларга ишелеп барган диварны төзәтеп бирдең. Син моның өчен акча да сорый ала идең бит.

Моңа җавап итеп, Хозыр галәйһиссәлам болай дип әйткән:

– Син янә минем эшкә кысылдың, шуңа күрә безгә аерылышырга вакыт. Әмма шулай да, мин сиңа элек кылган гамәлләремнең чын асылын сөйләп бирермен.

Һәм Хозыр галәйһиссәлам болай дип сөйли башлаган:

«Тишек тишкән корабка килгәндә, ул үзләренә ипи өчен акча эшләгән бик яхшы кешеләрнеке иде. Әмма алар юнәлгән тарафта бик тә гаделсез дәүләт башлыгы идарә итә. Бу вәхши бөтен яхшы корабларны үзенеке итеп үзләштерә торган булган. Корабта тишек ясап, ике явызлыкның кечерәген сайлап, мин аларны хакимнең усаллыгыннан коткардым һәм шуның белән аларга ярдәм иттем.

Балага килгәндә, ул игелекле һәм гадел гаиләдән иде. Киләчәктә бу сабый начар юлдан китеп, хәтта әти-әнисен дә юлдан яздыра алыр иде. Шуңа күрә, үсеп башкисәргә әверелгәнче без аны һәлак иттек. Аңа алмашка Аллаһы Тәгалә бу кешеләргә итагатьле бала бүләк итәчәк (Бер риваятьтә Аллаһы Тәгалә бу игелекле бәндәләргә киләчәктә бер пәйгамбәрнең әнисе дәрәҗәсенә лаек булырлык кыз бүләк иткән, дип хәбәр ителәә).

Авыл читендәге диварга килгәндә, ул ике ятим баланың җир биләмәсендә урнашкан булган. Бу дивар астында алар өчен яшерелгән хәзинә сакланган. Аларның әтиләре изге кеше булган һәм шушы дивар астына үз балаларына хәзинә яшергән, ә аның сакланышын Аллаһыга ышанып тапшырган. Әгәр шушы дивар бу ятимнәр үсеп җиткәнче җимерелсә, авыл халкы шул хәзинәне табып алып, аларны талап бетергән булырлар иде. Аллаһы Тәгалә ятим балаларның балигъльк яшенә ирешүләрен һәм бу хәзинәне табуларын теләгән. Болар барысы да Аллаһының рәхмәте

буларак эшләнгән. Мин эшләгән барлык гамәлләремне үз теләгем белән эшләмәдем: бу минем бурычым иде, миңа бу вазифам Рәхимле Раббыбыз тарафыннан бирелде. Минем гамәлләремнең хакыйкый асылы нәкъ менә шунда».

Хозыр галәйһиссәламнең әлеге сүзләре шулай ук Коръәндә дә раслана:

وَمَا نُرْسِلُ الْمُرْسَلِينَ إِلَّا مُبَشِّرِينَ وَمُنذِرِينَ ۚ وَيُجَادِلُ الَّذِينَ كَفَرُوا بِالْبَاطِلِ لِيُدْحِضُوا بِهِ الْحَقَّ ۖ وَاتَّخَذُوا آيَاتِي وَمَا أُنذِرُوا هُزُوًا ﴿٥٦﴾

> **«Алар [кыя янына килеп җиткәч] колларыбыздан [Хозыр [галәйһиссәлам] исемле] бер колны таптылар, Без аңа хозурыбыздан бер рәхмәт биргән, Үзебездән бер гыйлем өйрәткән идек [Безгә генә хас һәм Безнең өйрәтүебездән башка беленүе мөмкин булмаган «ләдүнни гыйлем» аша ул гаибкә караган кайбер нәрсәләрне белә иде]».**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:65

Бу аять белән «Әл-Кәһф» сүрәсендә Муса һәм Хозыр галәйһимәссәлам тарихын бәян итү башланып китә һәм ул 82 нче аятькә кадәр тәфсилләп тасвирлана.

Бу вакыйгаларда Муса галәйһиссәлам өчен тагын бер мөһим мәгънә яшеренгән була. Хозыр галәйһиссәлам белән аерылышырга туры килсә дә, аның белән танышу нәтиҗәсендә, Муса галәйһиссәлам бөтен гомере буена уйлап йөргән мәсьәләләрнең мәгънәсенә төшенә башлавын аңлый:

1) Ни өчен аның әнисе, Фиргавен кешеләре баланы үтерерләр дип курыкса да, аны сандыкка салып Нил елгасына агызган, шулай булса да Муса галәйһиссәлам һәлак булмаган?

2) Кыерсытылган Исраил улын коткарам дип, Муса галәйһиссәлам кыптыйны һәлак иткән. Аллаһы Тәгалә аңа ни өчен шундый насыйп

биргән? Бу хәлгә аның бик тә кәефе кырылган.

3) Ни өчен Муса галәйһиссәлам Шугайб галәйһиссәлам кызларының сарыкларын сугарган һәм моның өчен алардан акча алмаган?

Муса галәйһиссәлам бу сорауларга җаваплар тапсын өчен Раббыбыз аның юлына Хозыр галәйһиссәламне җибәрә дә инде. Зирәк акыл иясе белән бергә кичергән вакыйгалар аңа Аллаһы Тәгаләнең Рәхимле Зат булуына тагын бер кат инанырга ярдәм иткән. Хозыр галәйһиссәлам кораб идәнен тишкәндә аңа болай дип әйткән:

– Ий Муса! Әниең сине сандыкка салып суга агызып җибәрде, ләкин син батмадың. Аллаһы Тәгалә сине саклады, димәк, ул бу кешеләрнең дә гомерләрен саклаячак.

Ниһаять, Хозыр галәйһиссәлам Муса галәйһиссәламнең Шугайб галәйһиссәлам кызларының сарыкларына су эчертүен һәм аның өчен бернинди түләү алмавын искә төшергән. Бер авыл читендә урнашкан диварны төзәткәндә дә Хозыр галәйһиссәлам нәкъ шулай ук бер тиен дә хак алмаган: «Мондый эшләрне акчага эшләмиләр», – дип аңлаткан ул.

Хозыр галәйһиссәлам Аллаһы биргән белемнәрнең бер өлеше белән шул рәвешчә уртаклашкан. Фикер йөртүчеләр әлеге хикәятләрдән үзләре өчен олы файда алып, чын хакыйкатьне аңларлар, дип ышанам. Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән безгә килгән һәр бәла-казада нинди дә булса мәгънә бар. Аллаһы Тәгалә биргән тәкъдиребездә безгә Үзенең яшерен хикмәтләренә төшенергә ярдәм итсә иде, ә тормышыбызда Аның тарафыннан тәгаенләнгән вакыйгалар безнең өчен яхшы нәсыйхәтләр булсыннар. Аллаһы Тәгалә барысын да яхшы Белүче.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Нәсыйхәт

# Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет ителә торган нәрсә бүлеге

Факыйһ Әбү Ләйс Әс-Сәмәрканди радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итә. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мин Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әйткән сүзен ишеттем, ул болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә рәхмәтне йөз кисәк кылды, Үзендә туксан тугыз өлешен калдырды, җиргә бер генә өлешен иңдерде. Ул бер кисәктә мәхлүкълар бер-берсенә рәхмәт күрсәтә, хәтта ат та баласына басудан куркып, тоягын күтәрә».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Хәсән радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ул болай дип әйткән: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә йөз өлештән торган рәхмәтне барлыкка китерде. Ул йөздән берсен дөнья әһеленә иңдерде. Ул рәхмәт дөнья әһелләрендә әҗәлләренә кадәр булачак. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бу рәхмәтне Кыямәт көнендә алыр һәм аны туксан тугызга кушып, ягъни йөз рәхмәт итеп, камил рәвештә Үзенең дусларына һәм итагать әһелләренә бирер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһының рәхмәтенә ирешер өчен, мөэминнәр Аллаһыга хәмед-сәналәр, шөкерләр әйтергә һәм Аның ризалыгы өчен изге гамәлләр кылырга тиеш, чөнки Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмет иткән кеше, Аның рәхмәтенә ирешү өчен гамәл һәм тырышлык кыла. Моны раслап Аллаһы Тәгаләнең сүзе килә:

إِنَّ رَحْمَتَ اللَّهِ قَرِيبٌ مِّنَ الْمُحْسِنِينَ ﴿٥٦﴾

**«Һичшиксез, Аллаһының рәхмәте [догаларын һәм бүтән гамәлләрен яхшы кылган] игелекле кешеләргә [бик] якын».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:56

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَمَن كَانَ يَرْجُو لِقَاءَ رَبِّهِ فَلْيَعْمَلْ عَمَلًا صَالِحًا

**«...кем дә кем Раббысы белән очрашуга өмет итә, [Аның ризалыгына ирешерлек] игелек кылсын».**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:110

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَرَحْمَتِي وَسِعَتْ كُلَّ شَيْءٍ ۚ

**«...рәхмәтем исә һәрнәрсәне каплап алган».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:156

Иблис (аңа ләгъньәт булсын) өметләнеп болай дип әйтер: «Мин дә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өлеш тиячәк затмын». Шулай ук яһүди белән насаралар да Аллаһының рәхмәтенә өмет итәрләр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَسَأَكْتُبُهَا لِلَّذِينَ يَتَّقُونَ وَيُؤْتُونَ الزَّكَاةَ

**« ...(Рәхмәтемне) [көферлек һәм гөнаһлардан сакланган] тәкъвалык ияләренә, зәкят бирүчеләргә һәм [Без индергән китаплардагы бөтен] аятьләребезгә инанган кешеләр өчен язабыз».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:156

Бу сүзләрдән соң Иблис Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметен өзгән. Ә яһүди белән насаралар болай дип әйткән: «Без ширектән сакланабыз, зәкятне түлибез һәм Аллаһының аятенә ышанабыз».

Моннан соң Аллаһы Тәгаләнең сүзе инде:

الَّذِينَ يَتَّبِعُونَ الرَّسُولَ النَّبِيَّ الْأُمِّيَّ

**«Ул кешеләр яннарындагы Тәүрат һәм Инҗилдә [сыйфатлары] язылган Расүлгә, [укый-яза белмәгән, ләкин илаһи тәгълимгә өйрәтелгән Расүлем исемле] өмми Нәбигә ияреләр».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:157

Моннан соң яһүдиләр белән насаралар өметләрен өзделәр. Рәхмәт мөэминнәрнең үзләренә генә бирелер.

Һәрбер мөэмин Аллаһы Тәгаләгә иман бирүе һәм аны мөэминнәрдән итүе өчен хәмед-сәна әйтергә тиеш. Шулай ук Раббысыннан гөнаһларын кичерүне сорау вәҗибтер.

Яхъя бине Могаз радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Хакыйкатьтә, ул болай дип әйтә торган булган: «Әй, Аллаһым, дөреслектә, безгә бер рәхмәтне индердең һәм безне бу рәхмәт белән хөрмәтләдең. Ул рәхмәт Исламдыр. Әгәр безгә Үзеңнең йөз Рәхмәтеңне индерсәң, ничек моннан соң Синең ярлыкавыңны өмет итмик?»

Янә аннан болай дип хәбәр ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Әй, Аллаһым, итагать итүчеләр өчен Синең савабың һәм гөнаһ кылучылар өчен Рәхмәтең вәгъдә ителгән булса, мин үзем итагать итүчеләрдән булмасам да, савабыңны өмет итәр идем. Мин гөнаһ кылучылардан, шуңа да Синең рәхмәтеңне өмет итәм».

Янә аннан болай дип хәбәр ителә. Дөреслектә, ул радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Әй, Аллаһым, Син җәннәтне дусларың өчен яраттың. Фәрештәләреңне җәннәттә ихтыяҗсыз яраттың. Үзең җәннәткә мохтаҗ түгелсең, ягъни ул Сиңа кирәкмәс. Әгәр безгә җәннәтне бирмәсәң, җәннәт кем өчен генә булыр?»

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Хакыйкатьтә, һич изгелек кылмаган ир җәннәткә керде. Үзенә үлем килгән вакытта ул әһеленә болай дип әйтте: «Әгәр мин үлсәм, мине утта яндырыгыз, моннан соң яр-

тысын диңгезгә, яртысын корыга ташлагыз». Ул үлгәннән соң нәкъ шулай эшләделәр. Аллаһы Тәгалә диңгезгә һәм коры җиргә әмер итте. Болар ул ирне җыйдылар һәм аннан: «Син эшләгән нәрсәгә сине нәрсә этәрде, ягъни нидән шулай кылдың?» – дип соралды. Ул ир: «Әй, Аллаһым, Синнән курку этәрде», – дип җавап бирде. Аллаһы Тәгалә аны моның өчен ярлыкады».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләреннән булган бер ирдән риваять иткән. Ул кеше болай дип әйткән: «Без көлгән вакытта, безнең янга Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм чыкты. «Ут сезнең артыгызда булганда сез көләсезме? Аллаһы белән ант итәм, сезнең көлүегезне (аның мәгънәсен) күрмим», – дип әйтте һәм моннан соң китте. Бу сүзләр безнең башыбызга суккан кебек тәэссир итте. Күпмедер вакыттан соң безнең янга кайтып болай диде: «Миңа Җәбраил галәйһиссәлам килде һәм: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә әйтә: «Минем Рәхмәтемнән бәндәләремнең өметләрен өздермә». Моннан соң Пәйгамбәребез әлеге аятьне укыды:

نَبِّئْ عِبَادِي أَنِّي أَنَا الْغَفُورُ الرَّحِيمُ ﴿٤٩﴾ وَأَنَّ عَذَابِي هُوَ الْعَذَابُ الْأَلِيمُ ﴿٥٠﴾

**«[Расүлем!] Колларыма хәбәр ит, Мин – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле. Минем газабым исә – тилмерткеч бер газап».**

«Әл-Хиҗр», 15:49-50

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Гамру бине Гас радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бәндәсенең гөнаһысын ярлыкауны олугка санамый, ягъни Аңа бу бик җиңелдер. Сезгә кадәр яшәгән кешеләр

арасында туксан тугыз кешене үтергән бер ир бар иде. Соңыннан ул бер руханигә килеп: «Дөреслектә, мин туксан тугыз кешене үтердем, миңа тәүбә кылу бармы?» – дип сорады. Рухани: «Юк, олуг гөнаһ кылгансың», – диде. Шуннан соң бу кеше руханине дә үтерде. Соңыннан ул икенче руханига килеп: «Дөреслектә, мин йөз кешене үтердем, йә, минем өчен тәүбә бармы?» – дип сорады. Рухани: «Дөреслектә, син исраф кылдың. Белмимен, сиңа тәүбә бардырмы? Шулай да якында ике авыл бар. Аларның берсенә Басра, икенчесенә Кәфәра дип әйтеләә. Басра кешеләре җәннәт әһеленең гамәлләрен кыла һәм анда алардан башка кеше яшәми. Әмма Кәфәра кешеләре җәһәннәм әһеленең гамәлләрен кылучы кавемдер. Ул Кәфәрадә башка кешеләр яшәми. Син Басрага килеп, аларның гамәлен кылсаң, тәүбәңдә шикләнмә», – диде. Бу ир Басраны эзләп китте. Ике авыл арасында булган вакытта аңа үлем иреште. Газап фәрештәләре белән рәхмәт фәрештәләре һәркайсы үз тарафына алу өчен бәхәсләштеләр. Бу эш хакында фәрештәләр Аллаһы Тәгаләдән сорады. Аларга: «Бу кешедән алып ике авылга кадәр булган араны үлчәгез, ике авылның кайсына якынрак булса, ул кеше шул авылдан булыр», – дип әйтелде. Ике авыл арасын үлчәделәр һәм аны Басра авылына бармак башы кадәр якынрак итеп таптылар. Ул кешене Басра әһеленнән дип яздылар».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ул радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Дөньяда һичкем Аллаһы Тәгаләдән йөзен алмады һәм аны Кыямәт көнендә башкадан йөзен алдыртыр. Исламда өлеш иясе, гүя аның өчен өлеш булмаган кебек калмас. Берәү бер кавемне сөя икән, Кыямәт көнендә алар белән бергә булыр. Дүртенчесе: Аллаһы Тәгалә дөньяда колдан яшергән нәрсәне Ахирәттә дә яшерер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ул радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Ән-Ниса» сүрәсендәге дүрт аять мөселманнар өчен дөньяда булган бөтен

нәрсәдән дә изгерәктер:

Беренче аять:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَغْفِرُ أَن يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَن يَشَاءُ ۚ وَمَن يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا بَعِيدًا ﴿١١٦﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы Үзенә иш кушылуын гафу итмәс. Моңардан башканы исә [нинди генә зур гөнаһ булмасын, тәүбә шарты үтәлгән очракта] Үзе теләгән кешегә гафу итәр. Кем дә кем Аллаһыга [нәрсәне дә булса] иш кушса, ул [хактан] бик нык тайпылу белән адашты».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:116

Икенче аять:

وَلَوْ أَنَّهُمْ إِذ ظَّلَمُوا أَنفُسَهُمْ جَاءُوكَ فَاسْتَغْفَرُوا اللَّهَ وَاسْتَغْفَرَ لَهُمُ الرَّسُولُ لَوَجَدُوا اللَّهَ تَوَّابًا رَّحِيمًا ﴿٦٤﴾

**«Әгәр алар [гөнаһлар кылып] үз-үзләренә золым иткәч, [синең хозурыңда тәүбә итәр өчен, исән чагыңда яки вафатыңнан соң] сиңа килсәләр һәм Аллаһыдан [гафу һәм] мәгъфирәт сорасалар, Расүл дә салләллаһу галәйһи вә сәлләм алар өчен ярлыкау сораса, Аллаһыны [бик күп итеп] Тәүбәләрне кабул итүче һәм [бик кызганучан һәм] Рәхимле буларак табарлар иде».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:64

Өченче аять:

إِن تَجْتَنِبُوا كَبَائِرَ مَا تُنْهَوْنَ عَنْهُ نُكَفِّرْ عَنكُمْ سَيِّئَاتِكُمْ وَنُدْخِلْكُم مُّدْخَلًا كَرِيمًا ﴿٣١﴾

**«[Аллаһы һәм Аның расүле тарафыннан] Тыелган [начар] нәрсәләрнең иң авырларыннан саклансагыз, Без дә сездән начар эшләрегезне [һәм кече гөнаһларыгызны] капларбыз һәм сезне [җәннәт дигән] бик шәрәфле бер урынга кертербез».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:31

Дүртенче аять:

وَمَن يَعْمَلْ سُوءًا أَوْ يَظْلِمْ نَفْسَهُ ثُمَّ يَسْتَغْفِرِ اللَّهَ يَجِدِ اللَّهَ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿١١٠﴾

**«Кем дә кем [башка берәүгә карата] начарлык эшләп яки [үзе белән бәйле бер-бер гөнаһ кылып] үз-үзенә золым итеп, соңыннан Аллаһыдан ярлыкау сораса, Аллаһыны [гөнаһларны] Гафу итүче, [тәүбә итүчеләргә карата бик] Рәхимле дип табар».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:110

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Минем шәфәгатем зур гөнаһ ияләренәдер, ягъни өммәтемнән булган зур гөнаһ ияләренәдер. Әгәр берәү моны ялган дип белсә, шәфәгатемә ирешмәс. Әгәр берәү зур гөнаһ әһеле булмаса, аның өчен шәфәгатем булмас, ягъни ул шәфәгатькә мохтаҗ булмас».

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, ул салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем шәфәгатем өммәтемнең зур гөнаһ ияләренәдер. Берәү ул шәфәгатьне ялганга тотса, шәфәгатем аңа ирешмәс», – дип әйткән.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Карт кешегә бу кәрамәтне[1] тану, Аллаһыга шөкер кылу, Аллаһыдан һәм гамәлләрне язучы

[1] Могҗиза.

фәрештәләрдән оялу, гөнаһ эшләрдән тыелу, Аллаһы Тәгаләнең тәгатенә каршы булу, ягъни көтеп алу вәҗибтер, чөнки игенне урыр вакыт җитсә, ул көтелмәс. Яшь кеше дә шулай ук, аңа Аллаһыдан курку, гөнаһ эшләрдән саклану, итагатьне каршы алу вәҗибтер, чөнки ул кеше үлем вакытының кайчан җитәсен белми. Берәү яшь вакыттан ук Аллаһы Тәгаләгә итагать итсә, Аллаһы Тәгалә аны Кыямәт көнендә Гареш астында күләгәләндерер. Бу хәбәрдә килде».

Әбү Хәсән Касим бине Мөхәммәд иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итә. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә Үзенең Гареш күләгәсе белән җиде кешегә күләгә бирер. Ул көнне күләгә булмас, бары тик Гарешнең күләгәсе генә булыр. Беренчесе: гадел имам, ягъни патша. Янә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылып үскән егет. Янә мәчеттән чыгып, ул мәчеткә кайтканчыга кадәр күңеле мәчеткә бәйләнгән ир. Янә Аллаһы Тәгалә хакына дуслашкан ике ир: алар Аллаһы Тәгалә хакына җыелырлар һәм Аллаһы Тәгалә хакына аерылырлар. Янә аулакта Аллаһы Тәгаләне күз яше белән искә алучы ир. Янә садака бирүче ир. Ул садаканы яшерен кылыр, хәтта сул кулы уң кулы ни кылганын белмәс. Янә күркәм һәм матур хатын үзенә чакырып, «мин Аллаһы Тәгаләдән куркам», дип әйтүче ир». Аллаһы Тәгалә белүчедер.

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*

# Туган тел – Аллаһыдан әманәт

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи вә мән тәбигаһүм би ихсәнин илә йәүмиддин. Безне юктан бар кылып, камил акыллы, сәламәт тәнле кеше сурәтендә дөньяга китерүче; йомыш һәм хаҗәтләребезне аңлата алуыбыз өчен безне телле итүче һәм җирдәге барлык нәрсәләрне безгә буйсындыручы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә мактаулар булсын. Раббыбызның боерыкларын безгә ишеттереп, безне мәңгелек һәм чиксез кыйммәтләргә юнәлтеп, кыйблабызны күрсәтүче Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аңа ияреп, ислам байрагын бабаларыбызга тапшыручы сәхабәләренә һәм аларга иярүче барча мөэмин-мөэминәләргә салават һәм сәламнәребез ирешсә иде!

Бүгенге көндә туган телләрне өйрәнү һәм аларны саклау кирәклеге турында күп сөйләшүләр һәм бәхәсләр алып барыла. Үз телләрен белмичә башка милләт телләрендә сөйләшүчеләр моны кирәкмәс шөгыль итеп санасалар да, аз санлы халыклар телләрендә сөйләшүчеләр саны да әле әз түгел.

Галәмнәрнең Раббысы телләрнең күптөрлелеге һәм, гомумән, телнең кеше тормышындагы вазифасы турында Коръәни Кәрим нәрсә ди соң, галәмнәргә Расүл итеп җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу мәсьәләгә карашы нинди иде икән?

Иң элек телләрнең килеп чыгышы турында сөйләп китик. Коръәни Кәримнең түбәндәге аятьләрендә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ ۖ قَالَ

إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ ﴿٣٠﴾ وَعَلَّمَ آدَمَ الْأَسْمَاءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى الْمَلَائِكَةِ فَقَالَ أَنبِئُونِي بِأَسْمَاءِ هَٰؤُلَاءِ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ ﴿٣١﴾

**«Менә Раббың фәрештәләргә: «Һичшиксез, Мин җирдә хәлифә [итеп Адәм галәйһиссәламне яратачакмын!» – дип әйткәч, алар [каршы төшү максаты белән түгел, ә хикмәтен белер өчен]: «Әллә җирдә бозыклык кылучыны һәм кан коючыны яратачаксыңмы? Без бит һәрвакыт Сиңа мактау белән тәсбих әйтәбез, [Затыңның бөтен кимчелекләрдән пакь булуын танып] олылыйбыз», – диделәр. Ул: «Һичшиксез, Мин сез белмәгәннәрне беләм!» – диде. Ул [фәрештәләргә Адәм галәйһиссәламнең өстенлеген күрсәтер өчен, мәхлүкатлар ия] исемнәрнең [һәм ни сәбәпле яратылганнарын] барчасын аңа [атабыз Адәм галәйһиссәламгә өйрәтте, шуннан аларны фәрештәләргә күрсәтеп: «Әгәр сез хаклы булсагыз, менә бу нәрсәләрнең исемнәрен Миңа әйтегез!» – диде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:30-31

Аятьләрдән күренгәнчә, кешене фәрештәләрдән һәм җирдәге барлык хайваннардан аерып тора һәм өстен итә торган бердәнбер нәрсә – ул Аллаһы Тәгаләнең атабыз Адәм галәйһиссәламгә өйрәткән барча нәрсәләрнең исемен белү гыйлеме. Күпләр моны кешенең сөйләшә белүенә кайтарып калдырса да, бу болай гына түгел, чөнки хайван һәм кошларның да үз телләре бар, фәрештәләрнең дә телләре юк түгел. Димәк ки, Адәмгә өйрәтелгән бу гыйлем – үзгә бер гыйлем, һәм ул – безне чолгап алган җисем һәм күренешләрнең атамаларын яттан белү гыйлеме генә түгел, ә бәлки шул җисем һәм күренешләрнең табигатенә төшенеп, шуларга исем һәм билгеләмә бирә алу сәләте, ягъни телләр барлыкка китереп, аларны яңа сүзләр белән баету сәләте.

Нәкъ менә шушы, җир йөзендә бүтән бер мәхлүкъта да булмаган илаһи гыйлеме ярдәмендә кеше, тормышындагы әйбер һәм күренешләргә исем һәм атамалар биреп, телен барлыкка китерде. Адәмнең балалары һәм оныклары тормыш тәҗрибәләрен арттырып, аталарының телен тагы да баетты һәм төрлеләндерде. Тора-бара адәм балалары үрчеп күбәйде, көчлерәкләре аерылып, мөстәкыйль яши башлады, зәгыйфьрәкләре юкка чыкты. Шулай итеп төрле телле халыклар һәм кабиләләр барлыкка килде. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَمِنْ آيَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّلْعَالِمِينَ ﴿٢٢﴾

**«Күкләрне һәм җирне яратуы да, телләрегезнең һәм төсләрегезнең төрлелеге дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда [Аллаһы Тәгаләнең бөек сыйфатларын яхшы] белгәннәр өчен билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:22

Әмма атабыз Адәм Раббысының сүзен тыңламаганы өчен җәннәттән сөрелгәне кебек, адәм балаларының күбесе дә аталарының васыятенә тугры булып кала алмады. Гасырларның үтүе, заманаларның үзгәрүе белән күбесе дөньяга бирелеп, Раббыларына кайтачакларын онытты – туры юлдан тайпылды. Шуңа күрә җир йөзендә таралып яшәүче адәм балаларына Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә үз араларыннан гел илчеләр һәм пәйгамбәрләр җибәреп торды. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَمَا أَرْسَلْنَا مِن رَّسُولٍ إِلَّا بِلِسَانِ قَوْمِهِ لِيُبَيِّنَ لَهُمْ ۖ فَيُضِلُّ اللَّهُ مَن يَشَاءُ وَيَهْدِي مَن يَشَاءُ ۚ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ ﴿٤﴾

**«[Өммәтләргә хөкемнәребезне] Аңлатыр [һәм алар да бүтәннәргә җиткерә алсыннар] өчен, Без һәр пәйгамбәрне үз кавеменең теле белән [сөйләшә торган итеп] җибәрдек. Аллаһы [адашуны сайлаганын белгәне өчен, адашуда кала бирүен] теләгән кешене юлдан яздырыр, [һидаятьне сайлаячагын белеп, туры юлга ирештерергә] теләгәнен һидаятькә ирештерер. Ул – [Бөек] Җиңелмәс, Хикмәт иясе».**

«Ибраһим», 14:4

Аятьтән аңлашылганча, кешеләрне Раббылары белән таныштыручылар – пәйгамбәр белән илчеләр булса, моның төп һәм бердәнбер ысулы – илче һәм пәйгамбәрләрнең могҗиза күрсәтүләре түгел, ә аларның кавемнәре белән үз телләрендә сөйләшә алулары булды. Уйлап карасак, бу бик тирән мәгънәле бер сүз! Хәлбуки, галәмнәрнең Раббысы берәр кавемне туры юлга күндерергә теләсә, аларга көчле берәр кавемнең билгеле берәр кешесен илче итеп җибәрер иде дә, могҗиза күрсәтеп, аларны үз әмеренә буйсындырыр иде. Әмма бу беркайчан да болай булмады. Һичбер кавемгә чит телле чит кеше илче итеп җибәрелмәде. Барлык пәйгамбәр һәм илчеләр кавемнәре эчендә яхшы танылган, үз телләрен һәм гореф-гадәтләрен яхшы белүче кешеләр иде. Коръәндә моның дәлилләре күп. Әйтик, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында болай дип әйтелә:

مْ لَمْ يَعْرِفُوا رَسُولَهُمْ فَهُمْ لَهُ مُنكِرُونَ ﴿٦٩﴾

**«Яки алар расүлләрен танымадылар һәм шул сәбәпле аны инкяр иттеләрме әллә? [Юк! Бик яхшы таныдылар, ләкин инкярларының сәбәбе тик көнчелекләре һәм үҗәтлекләре булды]».**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:69

قُل لَّوْ شَاءَ اللَّهُ مَا تَلَوْتُهُ عَلَيْكُمْ وَلَا أَدْرَاكُم بِهِ ۖ فَقَدْ لَبِثْتُ فِيكُمْ عُمُرًا مِّن قَبْلِهِ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿١٦﴾

**«Ий, Расүлем! Мөшрикләргә] Әйт: «Әгәр Аллаһы [Коръәни Кәримне сезгә бу хәлдә укымавымны] теләгән булса, аны сезгә укымас идем, Аллаһы Үзе дә аны [минем аркылы] сезгә белдермәс иде. Мин аннан алда да [кырык ел] сезнең арада [беркемнән гыйлем өйрәнмичә һәм сезгә мондый нәрсәләр укымыйча] гомер үткәрдем. Сез [һаман да Коръәннең Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгәнен] аңлап җиткермисезме?»**

«Юныс», 10:16

وَلَوْ جَعَلْنَاهُ قُرْآنًا أَعْجَمِيًّا لَّقَالُوا لَوْلَا فُصِّلَتْ آيَاتُهُ ۖ أَأَعْجَمِيٌّ وَعَرَبِيٌّ ۗ قُلْ هُوَ لِلَّذِينَ آمَنُوا هُدًى وَشِفَاءٌ ۖ وَالَّذِينَ لَا يُؤْمِنُونَ فِي آذَانِهِمْ وَقْرٌ وَهُوَ عَلَيْهِمْ عَمًى ۚ أُولَٰئِكَ يُنَادَوْنَ مِن مَّكَانٍ بَعِيدٍ ﴿٤٤﴾

**«[Расүлем! Әйт] «Әгәр Без аны гаҗәмчә бер Коръән итсәк, [ул чакта] һичшиксез: «Аның аятьләре [без аңлый торган бер телдә] аңлатылса иде! Гарәп булган хәлдә гаҗәмчәме?» – дип әйтерләр иде. Әйт: «Ул – [Коръәни Кәрим] иман китергән кешеләр өчен бер һидаять һәм бер шифа».**

«Фуссыйләт / Аңлатылды», 41:44

Халкын Фиргавен золымыннан коткару өчен илче итеп җибәрелгән Муса галәйһиссәлам дә патша сараенда һәм халкы арасында танылган бер кеше иде. Әмма китергән могҗиза һәм дәлилләренең бу эштә бер файда китермәячәген аңлап, теле көрмәкләнгән Муса галәйһиссәлам Аллаһыдан үзе белән бергә оста телле кардәше Һарун галәйһиссәламне җибәрүен со-

рый. Ул галәмнәрнең Раббысына шулай дип ялвара:

قَالَ رَبِّ إِنِّي قَتَلْتُ مِنْهُمْ نَفْسًا فَأَخَافُ أَن يَقْتُلُونِ ﴿٣٣﴾ وَأَخِي هَارُونُ هُوَ أَفْصَحُ مِنِّي لِسَانًا فَأَرْسِلْهُ مَعِيَ رِدْءًا يُصَدِّقُنِي ۖ إِنِّي أَخَافُ أَن يُكَذِّبُونِ ﴿٣٤﴾

> **«[Вәхи алган Муса [галәйһиссәлам], пәйгамбәрлек вазифасын иң яхшы шәкелдә ирештерә алыр өчен Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап] Әйтте: «Ий, Раббым! Мин алардан бер кешене [ялгыш] үтергән идем, шул сәбәпле аларның мине үтерүләреннән куркамын. [Телем сакау булган өчен, сүзләремне яхшы итеп аңламаска мөмкиннәр] Абыем Һарун тел ягыннан миннән өстенрәк, янымда мине раслаган бер ярдәмче итеп аны да җибәр. Мин аларның мине ялганчы дип санауларыннан куркамын».**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:33-34

Барлык бу аятьләр кешенең, һәм бигрәк тә мөэмин кешенең, үз телен яхшы белүнең әһәмиятлелеген ассызыклый, үз халыклары телләрендә сөйләшә белүчеләрне илче һәм пәйгамбәрләр дәрәҗәсенә куя. Ни өчен? Чөнки алда искә алынган аятьләрдә әйтелгәнчә, – дөньядагы һәр тел – ул галәмнәрнең Раббысы адәм балаларына өйрәткән илаһи бер гыйлеме – илаһи бер әманәте ул, һәм галәмнәрнең Раббысы берәр халыкка мөрәҗәгать итәргә теләсә – аларга аталарының телендә мөрәҗәгать итә. Димәк ки, халыкның аңына үтеп керерлек, халык күңелен яуларлык һәм аларны Раббыларына юнәлтерлек бердәнбер илаһи корал – ул тел, кешенең туган теле! Үз халкына чит телдә мөрәҗәгать итүче йозакны ялгыш ачкыч белән ачарга маташучы кеше сыман ул.

Әлбәттә, төрле милләтләрнең яшәү рәвешләре һәм омтылышлары төрле булган кебек үк, телләр дә төрле дәрәҗәдә үсеш һәм кулланылыш

таба. Коръәни Кәримдә бу хакта болай дип әйтелә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ
إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Ий, кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хәвва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] Без сезне [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм моны яхшы аңлый һәм белә иде. Шуңа күрә көннәрдән бер көнне янындагыларга ул болай дип әйтә:

«Кайчакта миңа яһүдиләрдән хатлар килә. Үзләренә дә хатлар язарга туры килә. Болар безне алдамасыннар өчен, берәрегез яһүд әлифбасын өйрәнсен». Шуннан соң бер егет яһүд әлифбасын өйрәнде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Син сырьян телен дә беләсеңме?» – дип сорады. Ул гарәпләр белән византиялеләр арасында яшәүчеләрнең теле икән. Егет: «Юк», – дип җавап бирде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул егеткә шул телне өйрәнергә кушты һәм егет аны унҗиде көндә өйрәнде».

Күргәнебезчә, тел – ул саклану чарасы да. Дошман серләребезне белмәсен өчен, дошманның мәкереннән саклану, иманыбызны – көфердән, үзебезне һәм гаилә-балаларыбызны дөньяны басып алган

фахишәлек һәм имансызлыктан саклап калыр өчен ата-бабаларыбыздан калган тел – ул Аллаһының әманәте генә түгел, ә Аллаһының безгә биргән нигъмәте дә!

Шуңа күрә телебезне өйрәник. Динебез өйрәткән, Пәйгамбәребез күрсәткән мәңгелек кыйммәтләрнең исемнәрен үз телебездә әйтелешен булса да белик, шуларны бер-беребезгә һәм балаларыбызга өйрәтик. Аллаһының саклавы һәм карамагы астында булырбыз, иншәАллаһ!

*Альберт Кадыйров,*

*Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчете мәхәллә әгъзасы, тәрҗемәче*